Эпосның татар вариантлары саны дистәдән артып китә. Татар версиясе Идел буе һәм Себер территорияләрендә таралган текстлардан гыйбарәт. Моннан тыш, бүгенге көндә дә татарлар яшәгән төбәкләрдә «Алпамыш» сюжетына бәйле очрап тора торган дастан җырлары һәм сюжет фабулалары һәрберсе шулай ук аерым вариант буларак карала ала. Халкыбызның «Алпамыш»ка мөнәсәбәтле иҗатын һичшиксез берләштерә торган билгеләр – сюжет уртаклыгы, текстларның героик характерга, каһарманнарның бердәй исемнәргә ия булуы, уртак каһарманлык рухы.

«Алпамыш» дастанына үз чорында татар эпос белгечләре тарафыннан игътибар күрсәтелгән [Урманчеев: 1984. Б. 72–88; Урманчеев: 2008. Б. 89–90 һ.б.]. Төрле территориядә таралып яшәгән һәм яшәүче татар халкының «Алпамыш» сюжетына корылган һәм алып кешеләр эпосы сыйфатларын чагылдырган фольклор әсәрләре җыелмасы барысы бергә дастанның татар версиясен тәшкил итә дип карала. Моңа кадәр татар «Алпамыш»ы дигәндә Себердә язып алынган сөйләмә вариантлар, Идел буенда таралыш алган әкиятләшкән үрнәкләр, Алыплар турындагы кыска риваятьләр һәм әдәбиләшкән кульязмалар күздә тотыла иде. Соңгы елларда «Алпамыш»ның татар кульязма һәм басма китаплар булып таралган китаби вариантлары, дастаннан аерымланган эпик җырларның бүгенге экспедицияләрдә табылуы, информантларның дастан сюжетын исләренә төшереп сөйли алулары хакындагы язмалар [Мухаметзянова: 2014. С. 64–66; Мөхәммәтҗанова: 2023. Б. 30–37; Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар: 2023. Б. 55–58] «дастанның татар версиясе» дигән төшенчәне тагын да тулыландырды.

Татар халкында «Алпамыш»ның себердә чичәннәр авызыннан язып алынган күләмле текстлары бар. Биредә әле XIX–XX гасыр башында ук Ямәшкә карт, Рамазан Ильясов, Ситдыйк Зәйнетдинов һ.б. кебек мәшһүр чичәннәр булган, алар телдән эпос әйтү сәләте белән дан тотканнар. «Алпамыш» кына түгел, «Мешәк алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш-мәргән», «Кара Күкел», «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы-Күрпәч» һәм «Идегәй» нең берничә дистә варианты да нәкъ менә Себер территориясендә яшәүче информантлардан язып алынганлыгын беләбез. Чичән башкарунда билгеле «Алпамыш»ның да иң зур күпчелеген һәм иң күләмлеләрен себер территориясе информантлары биргән. «Татар халык иҗаты» академик басмасының 1984 елда дөнья күргән «Дастаннар» [Татар халык иҗаты. Дастаннар: 1984. Б. 49–53], 2019 елда рус телендә чыккан «Дастаны» томнарына [Татарское народное творчество: 2019. С. 66–70] 1971 елда Ф.В. Әхмәтова тарафыннан Төмән өлкәсенең Тубыл районы Күкрәнде (Чебурга) авылында (хәзер Тубыл районының Кутарбит авыл җирлеге составына керә) 1904 елгы информант Шәрифҗамал Хәлитовадан Ф. Әхмәтова язып алган вариант кертелгән. Шул ук текст 2004 елда төзеп бастырылган «Татар эпосы» җыентыгында урын алган «Алпамыш»ның дүрт варианты [Татар эпосы. Дастаннар: 2004. Б. 482–486, 487–492, 493–515, 516–523] арасында берсен тәшкил итә. [Татар эпосы. Дастаннар: 2004. Б. 482–486]. Тезмә белән чәчмә текстлар аралашып бара торган бу вариант урта гасырлар татар эпосы традициясе авазы буларак аеруча кадерле. Татар чичәннәре аша килеп җиткән дастандагы юллар тарихи үткәнгә алып китә, борынгыда ук татарларның таралыш ареалы киңлегенә ишарәли, элек-электән шәһәрле халык булуын ассызыклый:

Моның торган җире Көростан шәһәр булган. Төрекмән диләр.
Төрекмән дигән дә, әй,
Шәһәрләр килсә, әй,
Күз яздырмастай
Мәргәннәр булса, әй,
Болытны йөкләп тә
очарсың ук, әй,
Каңгыл казым, әй,
Кунгыл кашыма [Татар эпосы. Дастаннар: 2004. Б. 482].

Себердә яшәүче татарлар тарафыннан Алыпмәмшән, Алтмамшан, Алпамша, Алпамыш, Атмамшан, Атмәмшән алып һ.б.ш. исемнәр белән сөйләнелә торган яисә элеккерәк чорларда сөйләнелгән хикәятләр күләмле архаик «Алпамыш» эпосының сюжеты һәм мотивлары белән тирән аваздаш. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында Ту-

был районының Күкрәнде (Чебурга) авылында Р. Ильясов (1956 елгы) һәм З. Ильясовалардан (1956 елгы) 1971 елда Ф. Әхмәтова язып алган варианты теркәлгән [Алыпмәмшән (Алпамыш): 1971]. Текстта «Алпамыш» дастанының күпчелек версияләрендә китерелгән һәм шулай ук төрки халыкларның башка героик дастаннарына гомумән хас мотивлар сакланган. Мәсәлән, Алыпмәмшәннең читкә чыгып китүе; аның читтә мажараларга таруы, зинданга ябылуы; читтә йөргән Алыпмәмшән кайтып кергәннән соң сукыр әнисенең күкрәгенә сөт төшү; шул сөт белән күзен сөртүгә аның күрә башлавы һ.б.

1972 елда Төмән өлкәсе Вагай районы Юрмы авылында Флора Әхмәтова 1886 елгы информант Аймәдетдин Ниязовтан язып алган вариант шулай ук кызыклы [Алыпмәмшән (Алпамыш): 1972]. Биредә Карлыгачсылу Алыпмәмшәннең сеңелесе дә, хатыны да түгел, ә апасы буларак бирелгән; Алыпны зинданнан коткару мотивы бу вариантта юк, әмма ул контексттан аңлашыла; батыр каты йокыга тала, йокысыннан аны улы уята һ.б.

Себердә информант сөйләгәннән язып алынган «Алпамыш» вариантларының барысын да кайчандыр булган эпик вакыйгаларга тартым итеп сөйләү берләштерә. Сюжетта әкияткә якынлык үзен сиздерә, шул ук вакытта эпик киңлек, героиклык, чәчмә сөйләмнең тезмәләр белән аралашканлыгы аларның тамыры традицион «тере» эпостан килүне ачык күрсәтә. Соңгы елларда (2000–2025) ТӘһСИ уздырган экспедиция нәтиҗәләренә нигезләнеп, шуны әйтү мөһим: биредә татарлар тупланып яшәгән урыннардан Саз ягы, Тара, Бараба авыллары татарларында әле дә алып, Мәргән һәм батырларга багышланган күпсанлы хикәятләр һәм дастаннан өзекләр әле дә саклана. Аларда оча торган чаңгылар киеп ерак араларны тиз генә үтә алучылар, ерактан төз атучылар, дошман алыпларын җиңүчеләр, ау вакытында урманда төрле мифик җан ияләре белән очрашып, алар белән көрәшүчеләр һ.б. турында сөйләнелә.

2000 елда Татарстан Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Төмән өлкәсенә оештырган фольклор экспедициясе вакытында «Алпамыш» дастаны сюжетына турыдан-туры катнашы булган кыска хикәятләр язып алынды. «Алыпмәмшән хикәяте», «Алыпмәмшән кыйссасы» дип исемләнгән бу үрнәкләрдә Алпамыш (Алыпмәмшән, Алпамыш, Алпанша һ.б.) исемле геройның мажаралары турында сөйләнә. Себер территориясендә яшәүче татарлар арасында дастан җырлары шактый актив яши. Мәсәлән, Вагай районына 2002 елгы экспедициядә язып алынган эпик җыр – «Алпамыш дастаны» белән турыдан-туры бәйләнешле иҗат. Дастан җырларын әйткәндә, гадәттә, информант аның кайсы әсәргә бәйле булуын да атый. Бу очракта да җыр-

га карата информант тарафыннан түбәндәге аңлатма бирелде: «*Алыплар булган бит. Батыр кешеләр. Зур гәүдәле. Алыпмәмшәннәр. Алар турында сөйлиләр иде элек. Зинданда яткан дип. Аннан хатыны эзли чыгып киткән, коткарган. Шул турыда бу*»:

Буй гынаңа, әй,
Карап исәм, әй,
Әткәм Айтүбәгә
Охшатам ук, әй.
Торгын, егет, әй,
Торгын, егет, әй!
Әгәр тормасаң,
Үлдең, егет, әй!
Йөз генәңә, әй,
Карап исәм, әй,
Әнкәм Көнәрсылуга
Охшатам ук, әй!
Торгын, егет, әй,
Торгын, егет, әй!
Әгәр тормасаң,
Үлдең, егет, әй! [Алыпмәмшән җыры (дастан җыры / «Алпамыш»): 2002].

Батырлык рухы белән сугарылган фольклор үрнәге дастанның 1971 елда Төмән өлкәсе Тубыл районы Күкрәнде авылында Шәрифҗамал Халитовадан Ф. Әхмәтова язып алган вариантында китерелгән җыр текстын, кайбер морфологик-синтаксик аермаларны исәпкә алмаганда, сүзгә-сүз диярлек кабатлавы белән кыйммәт. Бу факт «Алпамыш» дастанының себер җирлегендә соңгы чорларда да исәнлеген янә бер кат дәлилли. Җырда төрки героик эпосының урта гасырлардан ук килә торган каһарманның читкә китүе, аңа ярдәмгә килүче хатын-кыз, батырны танып алу, аның һичшиксез җиңәчәгенә ышаныч кебек мотивлар чалымлана, шулай ук «Алпамыш»ның күләмле версия-вариантлары аша билгеле Айтүбә, Көнәрсылу исемнәре дә телгә алына.

Татар версиясенең «Алыпмәмшән хикәяте», «Алыпмәмшән җыры», «Алпамша» һ.б. исемнәр белән теркәлгән себер вариантларының һәркайсы – урта гасыр героик «Алпамыш» эпосы вариантлары, төрки эпик һәм Көнчыгыш романтизмы кануннарына туры килә торган фольклор истәлекләре. Болар, аеруча соңгы егерме-егерме биш ел эчендә табылган материаллар, чичән-информантлар башкаруында язып алынган булсалар да, поэтик җәһәттән көйле-музыкаль формасы булган һәм күләмле шигъри сөйләмнән гыйбарәт тулы версия-вариантлардан, әлбәттә, күп-

кә кайтыш. Моның сәбәпләрен чичән тарафыннан барлыкка китерелгән силлабик шигъри формалы эпосны көйләп декламацияләү традициясенең татарларда башка төркиләргә караганда иртәрәк сүрелгәнлеге белән аңлатырга мөмкин.

«Алпамыш»ның Идел буендагы вариантларына килсәк, алар бирендә үзләре шактый үзенчәлекле төркемне тәшкил итә. Болар – эчтәлеге буенча баһадир әкияте жанрына якын торган текстлар. «Алпамыш» дастанының кунграт, угыз, кыпчак, алтай версияләрен, шулай ук бу сюжетның Урта Азия эпосында чагылышын җентекләп өйрәнгән В.М. Жирмунский Казан татарлары вариантына карата «халык әкияте» терминын куллана [Жирмунский: 1974. С. 18]. Чыннан да, Татарстан территориясендә (Бондюг районы Камай авылында) Х. Ярми язып алган [Татар халык иҗаты. Әкиятләр: 1977. Б. 268–276] текстта, мәсәлән, борынгы эпик мотивларның булуы әсәрне төрки эпоска якынайтса да, стиле белән ул әкият жанрына күбрәк тартыла. Моннан тыш, Татарстан территориясендә табылган ике вариант һәм Оренбург өлкәсендә язылган тагын бер вариант шулай ук әкият жанрына карый, алар хәтта татар халык иҗаты академик басмасының «Әкиятләр» томына кертелгән. (Томның «Искәрмәләр» бүлегендә «Алпамыш»ның үз чорында билгеле текстлары хакында тулы мәгълүмат күрсәтелгән [Татар халык иҗаты. Әкиятләр: 1977. Б. 396–397]).

Әкиятләшеп, телдән сөйләнгән вариантларыннан тыш, Казан татарларына «Алпамыш»ның кульъязма вариантлары да билгеле. XX гасыр башында Казанда күп тапкырлар шактый күләмле «Кыйссаи Алпамыш» әсәре зур тиражлар белән басылып чыккан [Кыйссаи Алпамыш: 1912]. Димәк, гарәп язулы бу китапларга ихтыяҗ зур булган. Казанда басма китаплар дөнья күргәнгә хәтле һәм әле аннан соң да «Алпамыш» сюжетлы текстларның күчереп язылганлыгы да мәгълүм. Мәсәлән, Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана торган кульъязма [Алпамша хикәяте: 1006 Т] – Татарстанның Минзәлә районында табылган, Габдулла Сайманов төзегән текст. 2004 елда бу вариант «Алпамша хикәяте» исеме белән дөнья күргән [Татар эпосы. Дастаннар: 2004. Б. 493–515]. «Алпамыш»ның Идел буе татарларына хас кульъязма һәм басма текстларының барысына да бер жанрдан икенчесенә күчү хас, алар, XX йөз урталарында язып алынган сөйләмә вариантлары кебек, героик әкияткә әверелүгә таба үзгәреш кичергәннәр, күләме җыйнакланып, трансформацияләнгәннәр.

«Алпамыш» сюжетлы фольклор үрнәкләренең Идел буе татарларында безнең көннәрдәге торышына килсәк, 2019 елда Татарстан Республикасының Азнакай районына фәнни экспедиция вакытында язып алынган кыска эпик җыр игътибарга лаек. Дастан җыры «Мәрҗәнсылуым» дип

атала [Мәрҗәнсылуым (Алпамыш): 2019]. Ирекле авылы информанты Әхмәтшина Савилә Юныс кызы (1937 елгы), дастаннан куплетны башкарып, җырның икенче исемен дә өстәп әйтеп бирде: «Алпамыш җыры» диләр иде инде бу җырны. «Алпамыш»тан тыш «Түләк», «Сәйфелмөлек» дастаннары хакында да азмы-күпме мәгълүматы булган әлеге информант «Алпамыш» белән китап аша таныш булуын да искәртте. Аның Алпамыш турындагы дастанга бәйле телдән әйткән тезмәсе түбәндәгедән гыйбарәт:

Лап-лоп басканда-й аюмы идең-әй?  
Шул зинданнарга килгәнме идең-әй?  
Мәрҗәнсылуым, Мәрҗәнсылуым,  
Ай-һай көннәр-әй,  
Үтте төннәр-әй [Мәрҗәнсылуым (Алпамыш): 2019].

«Дастан үзе ни турында?» дигән сорауга да Ирекле информанты шактый тулы җавабы белән куандырды:

«*Борын заманда Алпамыш булган. Зур гәүдәле пәһлеван икән. Атасы хан, анасы ханбикә булган. Хатынының исеме – Мәрҗәнсылу. Алпамыш читкә киткән сугышка. Анда дошманнарының кулына эләккән. Зинданда ята. Еллар буе ята. Хатыны Мәрҗәнсылу ирен эзләп китә. Күрә иренең зинданда ятуын. Коткара алмый, кайтып китә. Шуннан соң шул җир патшасының кызы Алпамышны коткара, аңа зинданнан чыгарга ярдәм итә. Алпамыш чыга зинданнан, аны Акбүз аты көтеп тора, Алпамыш атына атлана. Кайта үз авылына. Аны танымый торалар. Думбыра чиртеп җыр әйткәннән Мәрҗәнсылу Алпамышны таный. Мәрҗәнсылуның туе икән. Мәрҗәнсылу ирен таныды бит инде. Ук аттырып карый. Алпамыштан да төзрәк ата алмый беркем. Алпамыш җиңә. Мәрҗәнсылу белән кабат никахлана Алпамыш*» [Мәрҗәнсылуым (Алпамыш): 2019].

Зур гәүдәле кавемнең булуына ишарә, геройның килеп чыгышын ханнар, ханбикәләр белән бәйләү, эпос героеның читкә чыгып китүе, аңа ярдәмгә килүче хатын-кыз, эпос героеның алыштыргысыз аты, думбыра чиртеп җыр әйтү, каһарманны таныту – информанттан язып алынган материал төрки эпос өчен характерлы әһәмиятле мотивларны телгә алуы белән кыйммәт. Әлбәттә, сүз бу очракта күләмле эпос-дастанны тулы килеш язып алуга ирешү турында бармый, әмма экспедиция табышы телдән башкарыла торган эпос традицияләренең һәм мотивларының дәвамчанлыгын күрсәтә торган факт, ул – Идел буенда «Алпамыш»ның онытылып бетмәвенә дәлил.

«Алпамыш»ка мөнәсәбәттә фольклор хәтере ныклыгының төп сәбәбе – иҗат фантазияләрен, шулай ук гомуми идеяне тормышка ашыру һәм тапшыру өчен борынгы ышанычлы чара булган әсәрнең үзендә. Барлык-

ка килүенең, яшәешенең, эволюциясенең һәм трансформациясенең тарихи-мәдәни үзенчәлекләре аркасында Алпамыш турындагы сюжетка нигезләнгән татар эпосы – үткән һәм хәзерге заман арасында гына түгел, ә традицион тере эпос белән тулаем сүз сәнгате, татар язма мәдәнияте арасында да бәйләүче буын. Шунысын да ассызыклап күрсәтү мөһим: «Алпамыш» ның халык теленнән язып алынган күп санлы сөйләмә һәм язмада чагылыш тапкан китаби вариантларыннан гыйбарәт татар версиясенең тамырлары тере эпик традицияләргә нигезләнеп барлыкка килгән һәм формалашкан. Дастан текстларына салынган милли кодлар аша этнос аңының эволюцияләүче билгеләрен табарга мөмкин. Моның өчен «Алпамыш»ның һәр вариантын аерым-аерым махсус тикшерүгә җәлеп итәргә кирәк; фәнни тикшеренүдә халыкның мәдәният тарихы, этнографиясе исәпкә алынырга тиеш. Теләсә кайсы милли эпосның үзенчәлекләрен дөрес аңлау өчен иң мөһиме – аның идея-сәнгати эчтәлеген нигезле интерпретацияләү, шулай ук буыннан-буынга тапшыру формасын һәм юлларын аңлату, чөнки сүз бүгенге көндә киң даирәгә генә түгел, ә тар даирә белгечләргә дә аз билгеле фольклор материалы хакында бара.

Татар «Алпамыш»ының элеккерәк чорларда теркәлгән күләмле сюжетлы вариантлары да, соңгы елларда сирәк булса да очрап куя торган фабулалары һәм дастаннан аерымланган эпик җырлар һәммәсе бүгенге көндә «Алпамыш»ның татар версиясе хакында яңа тикшеренүләр алып баруның әһәмиятен ассызыклый, борынгы дастанны өйрәнүнең дәвамлы булуын тәэмин итә, татар милли версиясе хакында яңа фәнни сүз әйтү мөмкинлеген бирә. Дастанның татар версиясе бүгенге көндә фәнни даирәнең игътибарына аеруча лаек. Татарларда асылда Идел буенда һәм Себер киңлекләрендә таралган «Алпамыш» эпос-дастаны хәзерге көндә татарларны башка төркиләргә якынайта, тамырларны барлау, тарихыбызны тергезү, милли үзбилгеләнүдә катнаша дип ышанып әйтә алабыз.

### Әдәбият

1. Алпамыс батыр / Құрастырып, баспаға дайындағандар: К. Матыжанов, Т. Әкимова, А. Оралбек, Ж. Ракыш. Алматы: «Үш Киян», 2024. – 380 б.
2. Алпамша хикәяте // КФУ Н. Лобачевский ис. Фәнни китапханәнең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (ОРРК). Шифр: 1006 Т.
3. Алыпмәмшән җыры (дастан җыры / «Алпамыш»). 2002. Түмән өлкәсе Вагай районы Казанлы авылында 2002 елда язып алынды. Информант – Сәгыйдуллин Хәлим Харисович (1949 елгы) // Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивы.

4. Алыпмәмшән (Алпамыш) // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгенең тасвирланмаган фонды. Папка 1971; 1972.
5. Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. – 727 с.
6. Кыйссаи Алпамыш. Казан: Домбровский тип., Ш. Хөсәенов варислары нәшере, 1912. – 46 б.
7. Мәрҗәнсылуым (Алпамыш) (дастан җыры, дастан фабуласы). Татарстан Республикасының Азнакай районы Ирекле авылында язып алынды. Информант – Әхмәтшина Сәвилә Юныс кызы (1937 елгы) 2019 ел. // Фольклорчы Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивы.
8. Мөхәммәтҗанова Л.Х. Дастан җырлары // Түгәрәк уен. 2023, № 1. Б. 30–37.
9. Мухаметзянова Л.Х. Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ, 2014. – 380 б.
10. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Җырулы йомак. Татар дастаннары / төз. И.Г. Закирова. Казан: ТӘhСИ, 2023. 19нчы чыг. – 256 б.
11. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче китап / Томны төзүчеләр – искәрмәләрне әзерләүчеләр – Гатина Х.Х., Ярми Х.Х. Казан, 1977. – 408 б.
12. Татар халык иҗаты. Дастаннар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы – Әхмәтова Ф.В. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 384 б.
13. Татар эпосы. Дастаннар. Төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлек әзерләүче – Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. – 640 б.
14. Татарское народное творчество. В 15 т. Т. 8. Дастаны / сост тома, автор вступит. статьи и коммент. Ф.В. Ахметова. Казань: Татар. книж. изд – во, 2019. – 471 с.
15. Түрки халықтарының рухани мұрасы әлемдік өркениет аясында: «Алпамыс батыр» жыры атты халықаралық ғылыми-теориялық конференция материалдарының жинағы. Алматы: «Service Press», 2024. – 412 б.
16. Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. книж. Изд-во, 1984. –312 с.
17. Урманчеев Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. 1 т. (А-Г). Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

*Д.Р. Зайнутдинов*

# ВЗГЛЯД ГАЯЗА ИСХАКИ НА СОВЕТСКИЙ КОНСТИТУЦИОНАЛИЗМ

***Аннотация.*** *Личность Гаяза Исхаки довольно сложная, как и сама его судьба. Работы Г. Исхаки, как публицистического, так и литературного жанра, сыграли немалую роль в развитии татарской политико-правовой мысли. Особую ценность среди всех его работ имеет статья, посвященная исследованию советского конституционализма «Основной закон большевиков» 1936 г. Он охарактеризовал данный нормативный акт как идеолого-политический документ, не преследующий цель изменения существующего советского строя. Негативное влияние нового Основного закона, по мнению татарского мыслителя, состояло в том, что он юридизировал все пороки советской системы управления, национальной политики, отношение к правам и свободам граждан, но при этом облачив их в приемлемую для политиков и населения Европы правовую форму.*

***Ключевые слова:*** *Гаяз Исхаки, Конституция СССР 1936 г., конституционализм, права и свободы, национальный вопрос.*

Гаяз Исхаки (Мухамеметгаяз Исхакый) (1878–1954 гг.) никогда не имел юридического образования, но в круг его общения всегда входили довольно крупные юристы, такие как Ф. Туктаров, Ш. Мухамедьяров, С. Максуди и другие. Юридическое мировоззрение знакомых и друзей оставили определенный отпечаток на взглядах Г. Исхаки, что и можно обнаружить в целом ряде его работ.

Г. Исхаки весьма неплохо улавливал общие тенденции развития права как в мире в целом, так и в конкретных государствах в частности. Во-первых, будучи одним из лидеров движения за независимость татарского народа он пристально следил за эволюцией международного права, особенно в части права наций на самоопределение. Во-вторых, его не могла не интересовать динамика формирования правовой системы СССР, развитие законодательства, обоснование проводимых репрессий, модель судопроизводства, деятельность правоохранительных органов и т.д.

На тематику советского права Г. Исхаки написал в 1936 году довольно объемную статью «Основной закон большевиков». Опубликована она была в № 9 и № 10 журнала «Новый национальный путь» [Исхаков: 2011. Б. 252–261]. Статья посвящена анализу проекта «Сталинской конституции». Данную работу условно можно разделить на три части:

– анализ конституционных норм;
– соотношение власти, общества и наций в СССР;

– причины принятия конституции.

Конституция Союза Советских Социалистических Республик, утвержденная постановлением Чрезвычайного VIII Съезда Советов СССР от 5 декабря 1936 г. [Конституция: 1936], уникальный по своему характеру документ, который совершенно не отражал функционирующий государственный режим и правовую реальность. «Принятие новой Конституции СССР означало апофеоз того, кто находился на вершине власти, триумф победителя, который и содержанием Конституции, и самим фактом ее принятия «освятил» свое торжество. Более того, для той же цели «зародил» традицию связывать в «народном сознании» конституцию с именем политического лидера страны: Конституцию СССР 1936 г. сразу стали называть «сталинская» [Авакьян: 2014. С. 223].

В юридической литературе принято считать содержание Сталинской конституции на период 1930-х гг. самым демократическим в мире. Однако демократизма в ней было не больше, чем в любой советской декларации или декретном законодательстве. Справедливо по этому поводу пишет российский конституционалист М.В. Баглай: «Лицемерием и цинизмом были пронизаны положения Конституции, связанные со свободой совести» [Баглай: 2007. С. 62]. Советский конституционализм со второй половины 1930-х гг. стал представлять собой демократическую ширму для прикрытия произвола государственной власти, легитимировав массовый террор, направленный на создание абсолютно послушного тоталитарному режиму общества.

Международная пропаганда советского государственно-правового строя, как отметил Г. Исхаки, стала важной составляющей процесса принятия нового Основного закона СССР. Татарский мыслитель указывал, что пресса в Европе, финансируемая большевиками, длительное время писала, что в СССР будут проведены широкие реформы по демократизации управления, укреплению начал справедливости, свободы и равенства. Именно в рамках этой пропаганды советской властью было профинансировано издание пятнадцати миллионов экземпляров проекта Конституции СССР на одиннадцати языках для их распространения в мире [Исхаков: 2011. Б. 252].

В своей работе Гаяз Исхаки развенчал псевдодемократические реформы в области конституционного строя, о которых говорила советская пропаганда в Европе. Он отмечал, что в новой Конституции СССР сохранилась все та же монопартийность с единственно допустимой коммунистической партией, возможность создания политических организаций иной направленности была под запретом; конституционно поощрялась

антирелигиозная пропаганда; власть в стране олицетворяла не все население, а только рабочий класс и сельские жители.

Исходя из содержания конституционных прав и свобод, Г. Исхаки разгруппировал население СССР по уровню правомочий, выделив:

– полноправных;
– ограниченных в правах;
– лишенных прав.

Исследуя Сталинскую конституцию, Гаяз Исхаки не мог не подвергнуть ее тщательному анализу с позиции обеспечения национальных и религиозных прав.

Очевидно, писал Г. Исхаки, что «контрабандным путем», через экономические постулаты советы смогли провести и закрепить в Основном законе СССР нормы о русификации [Исхаков: 2011. Б. 255]. Поэтому он считал, что с позиции соблюдения национальных прав и федерализма новый Основной закон хуже Конституции СССР 1924 г. [Исхаков: 2011. Б. 255].

На ряде положений Конституции СССР 1936 г. Гаяз Исхаки остановился отдельно.

Заложенные в Основном законе СССР 1936 г. конституционные принципы, по мнению Г. Исхаки, представляли собой лишь новый инструмент ассимиляционной политики большевиков. Судя по всем аспектам, новая советская Конституция призвана была лишить национальных особенностей народы, проживающих в СССР, и уничтожить их религиозные основы и мораль, а также лишить материальных возможностей для самостоятельного поддержания национально-религиозной сферы [Исхаков: 2011. Б. 256].

Так, статья 124 Основного закона СССР гласила, что «в целях обеспечения за гражданами свободы совести церковь в СССР отделена от государства и школа от церкви. Свобода отправления религиозных культов и свобода антирелигиозной пропаганды признается за всеми гражданами». Данные нормы развивали положения статьи 125 устанавливающей, что в соответствии с интересами трудящихся и в целях укрепления социалистического строя гражданам СССР гарантируется законом: свобода слова, свобода печати, свобода собраний и митингов, свобода уличных шествий и демонстраций. Эти права граждан должны были обеспечиваться предоставлением трудящимся и их организациям типографий, запасов бумаги, общественных зданий, улиц, средств связи и других материальных условий, необходимых для их осуществления. Но Гаяз Исхаки подчеркивал, что при учете почти двадцатилетнего периода существования советской власти и фактически отправляемой ею политики в сфере вероисповеда-

ния, новые конституционные положения не имеют реального шанса на воплощение, так как основная законодательная база, прямо направлена на борьбу с религией. По этой причине принцип свобода совести в СССР не обладает тем правовым содержанием, которое закрепила западная юридическая наука. «Сорок миллионов мусульман, проживавших в СССР, были лишены возможности создавать религиозные организации, строить мечети, медресе, издать религиозные книги, в том числе Коран» [Исхаков: 2011. Б. 256], – констатировал татарский мыслитель.

Реально существующая практика государственного администрирования не отражала те основы, которые закладывались в изначальный фундамент советской государственности. Особо ярко это проявлялось в части реализации принципа федерализма, на чем также делал акцент Гаяз Исхаки. Отношения между центральным правительством и местными органами власти и разделение правомочий между ними строились на основе сверхцентрализма. И главную роль в этой централизации сыграл И.В. Сталин, добившийся конституционного закрепления жесткой вертикали власти, при которой республиканские органы полностью стали подчиненными по отношению к всемогущему советскому центру. Такое положение вещей татарский мыслитель описал как «сосредоточение всей государственной власти вокруг личности секретаря секты» [Исхаков: 2011. Б. 255].

Критически Г. Исхаки отнесся и к реформе национально-территориального устройства СССР в рамках политики «национального размежевания», считая, что расширение числа союзных республик фактически является бессмысленным, так как никакой реальной самостоятельности данные республики не имеют. Он обращает внимание на деление республик на «союзные» и «автономные», тем самым фактически вводя категорирование самих народов на «первосортные» и «второсортные» [Исхаков: 2011. Б. 253]. Примечательно, что схожие мысли высказывали некоторые деятели и в самих национальных советских республиках. В данном случае уместно привести слова члена Коллегии Народного комиссариата по делам национальностей РСФСР М.Х. Султан-Галиева (1892–1940 гг.), который в своем выступлении на заседании X Всероссийского съезда советов 26 декабря 1922 г. заявил: «Разделение национальностей советских республик на национальности, которые имеют право вхождения в союзный ЦИК, и на национальности, которые не имеют этого права, разделение на пасынков и на настоящих сыновей – безусловно является ненормальным» [Султан-Галиев: 1998. С. 409–410].

Начавшаяся во второй половине 1924 г. в Центральной Азии политика национально-государственного размежевания [Постановление: 1924.

С. 784], длилась более десяти лет. На протяжении этого времени многократно создавались, объединялись и упразднялись различные национально-территориальные образования. Последними мероприятиями в рамках этой политики стало преобразование в 1936 г. в союзные республики Казахской АССР и Киргизской АССР, а также передача Каракалпакской АССР в состав Узбекской ССР.

Гаяз Исхаки считал, что с юридической стороны «национальное размежевание» было проведено «невероятно безобразным образом», так как для тюркских народов Центральной Азии непродуманные границы создадут в будущим лишь почву для «племенных разногласий» [Исхаков: 2011, Б. 253]. Здесь стоит вспомнить межнациональные конфликты в эпоху кризиса СССР: национальные погромы в Ферганской области Узбекской ССР в мае–июне 1989 г. (между узбеками и турками-месхетинцами); межэтнические столкновения в городе Новый Узень Казахской ССР в июне 1989 г. (между казахами и выходцами с Северного Кавказа); массовые беспорядке в городе Душанбе Таджикской ССР в феврале 1990 г. (между таджиками и армянами); межнациональный конфликт городе Ош и его окрестностях Киргизской ССР в мае–июне 1990 г. (между киргизами и узбеками).

Не только проблема национальных прав была затронута Г. Исхаки при анализе конституционных норм, но и другие положения Основного закона СССР 1936 г., посвященные экономическим основам, избирательным правам и так далее. Например, татарский мыслитель, как и ряд советологов того времени, охарактеризовал советскую экономическую систему как «государственный социализм», основанный на отрицании частной собственности, подавлении частной инициативы, наказуемости индивидуальных способностей к предпринимательству [Исхаков: 2011. Б. 253].

Дал татарский мыслитель и свою оценку советской избирательной системе. В частности он отметить, что ее недостатками были не только фиктивность выборов и невозможность участия в них некоммунистических партий, но и запрет на политические организации и группы, целью которых являлась защита национальной идентичности народа, культуры, языка. Избирательное право по новой конституции СССР, как подытоживал Гаяз Исхаки, представляет собой «хитрую уловку», призванную сделать вид, что народ участвует в выборах, но при этом не допустить широкие народные массы к реальному государственному управлению [Исхаков: 2011. Б. 253].

Теория советского конституционализма складывалась таким образом, что в корне противоречила существующему в обществе правопорядку. Поэтому и Конституция СССР 1936 г., как было ранее отмечено, стала

уникальным документом, наполненным демократическим нормами, но не имеющими возможности для практического применения. На данном аспекте Гаяз Исхаки и делал акцент.

Специфика деятельности советских правоохранительных органов и процедуры привлечения к ответственности, заключалась в классовой дифференциации при назначении наказаний. Г. Исхаки приводил пример, что за совершенное преступление «сын бывшего купца или дочь имама» понесут более тяжкое наказание, чем за то же деяние, если его совершит рабочий или советский чиновник. Нередки были случаи, когда должностные лица советского аппарата управления просто отделывались выговором. Подобная практика учета классового происхождения при назначении наказания лицам, совершившим правонарушение, резонно отличалась от общеевропейской системы привлечении к ответственности. Обратил внимание татарский мыслитель и на то, что если по ряду преступлений европейские суды приговаривали лиц, на срок от одной-двух недель до нескольких лет, то в СССР за аналогичное преступление наказание для классовых врагов могло доходить до смертной казни [Исхаков: 2011. Б. 256].

Наличие таких репрессивных органов как Объединенное государственное политическое управление (в 1934 г. основные оперативные подразделения бывшего ОГПУ СССР вошли в состав Главное управление государственной безопасности НКВД), наделенное квазисудебными полномочиями и активно ими пользующееся, заранее предопределяли неизбежную деформацию конституционного правопорядка. В данном отношении Г. Исхаки писал, что органы на подобие ОГПУ по-прежнему будут господствовать над совестью, жизнью и душой народов СССР, и личность в советском государстве не будет защищена от произвольных наказаний. Поэтому он констатировал, что конституционные нормы о суде в СССР в реальности так и останутся «просто красивыми словами, невозможными для воплощения в жизнь». Права личности будут только «европейской декорацией», пока не будет закреплен институт их судебной защиты, и не дана возможность ее осуществления [Исхаков: 2011. Б. 257].

Таким образом, если проанализировать Конституцию СССР 1936 г. от начала до конца, и ее отдельные элементы, как пишет Г. Исхаки, то обнаружится, что данный Основной закон – это всего лишь «окрашивание старого советского строя и старого коммунизма новыми красками, приемлемыми для менталитета Европы». Только у европейских народов, осмысливших демократию и либерализм, такие слова как «народоправство», «равенство» и «уважение», подлинно воплощаются на практике, и

слова не расходятся с делом. В советском государстве, несмотря на красоту новых конституционных норм, все также продолжается неуважение к правам личности, неуважение к национальной идентичности и культуре [Исхаков: 2011. Б. 257].

Подытоживая свой разбор Конституции СССР 1936 г., Гаяз Исхаки подчеркивает, что Коммунистическая партия неспособна коренным образом изменить конституционный строй, если не изменится мировоззрение ее членов. Осквернение законов равенства, свободы и справедливости происходит исключительно от имени Коммунистической партии, имеющей монополию политической власти, и прямое влияние на деятельность всех государственных учреждений [Исхаков: 2011. Б. 257].

Плавно завершив анализ конституционных положений, Г. Исхаки переходит к проблеме соотношения власти, общества и наций в СССР. Данную проблему он рассматривает через философско-правовую призму, пристально всматриваясь в модель советского конституционализма.

Конституционно провозглашенные советской властью общедемократические права и свободы татарский мыслитель сравнивает с заявлением тюремщика о «широком уважении, полной справедливости, неограниченного равенства для заключенных». Здесь Гаяз Исхаки ставит целый ряд вопросов: какая польза от свободы людям в тюрьме, окруженной высокими стенами с вооруженной охраной? Какой смысл в равенстве заключенных, когда вся их еда, питье и жизнь зависят от тюремных надзирателей? что значит справедливость в словах тюремщика, отправляющего заключенного на каторгу или смертную казнь за их мысли и мечты, когда они не имеют права на защиту? На эти вопросы ответ любого заключенного будет предельно прост: стены тюрьмы не должны ограничивать его свободу, охрана не должна контролировать его тело, душу и совесть, у него должна быть возможность для защиты своих естественных прав. Народы СССР, писал Г. Исхаки, как раз и выступают в роли этих несправедливо обвиненных заключенных, за которыми надзирает большевистский тюремщик. Они бесправные субъекты. Их единственное желание, как полагает Г. Исхаки, – это избавление от тиранической мощи, от большевистского правления, монополизировавшего всю материально-духовную жизнь в стране, и называющего тиранию справедливостью и свободой, а классовые привилегии – равенством. Поэтому с точки зрения народов СССР, принципы нового Основного закона СССР 1936 г. представляют собой «мешанину слов», которые не принесут никаких реальных выгод и изменений [Исхаков: 2011. Б. 258].

Причину принятия новой Конституции Гаяз Исхаки видит не в нужде оформления новых общественных отношений в СССР, а в необходимо-

сти юридизации советского режима в виде сталинизма, его учения, и текстуальной демократизации в глазах Европы.

Весьма интересно мнение Г. Исхаки по поводу реализуемой в СССР выдвинутой И.В. Сталиным формулы о «построение социализма в отдельно взятой стране», ставшей официальной доктриной государства после XIV съезда ВКП(б) в 1925 г., но при этом прямо противоречащей одному из основ идеологии коммунизма – лозунгу об отмирании государства. Эта формула сгладила резко агрессивную внешнеполитическую риторику советских официальных идеологов, как это было в период попыток реализации идеи «мировой революции». Но это вовсе не значило оставление большевиками проекта внешней экспансии. Новой виток экспансии коммунизма, как считал Г. Исхаки, начался с конституционализации советского строя, взявшего за образец европейские конституционные модели. С этого времени идеи коммунизма стремились интегрировать в сознание населения Европы через знакомые им демократические государственно-правовые институты.

Непосредственно саму причину перехода советского режима к реализации формулы «построения социализма в отдельно взятой стране», и принятие новой Конституции, Гаяз Исхаки объяснял двумя обстоятельствами:

– первое состояло в том, что большевики не только довольно быстро заметили пассивное отношение западного рабочего движения к идее «мировой революции», но и собственную неспособность всецело поддерживать это движение;
– второе обстоятельство заключалось в том, что советскому режиму для продолжения своего существования требовался постоянный внешний враг, которого нужно было идейно обосновать, а потому СССР стал восприниматься как нечто отличное от других (капиталистических) стран, как единственное государство, движущееся к достижению заявленной цели «полной победе социализма».

Поэтому попытки навязывания коммунизма агрессивными методами, сменились на метод дипломатического давления и международных союзов. И главную роль в пропаганде демократического облика СССР предстояло сыграть новому Основному закону 1936 г.

Советский режим для продолжения своего противоестественного существования, как писал Г. Исхаки, не нашел другого способа, кроме как искать и опираться на общие интересы различных государств. Вызвано это было разрастающейся в мире новой угрозы со стороны держав, в которых крайний национализм стал фундаментом всей политико-правовой деятельности (Италии и Германии). Государства Европы, стоявшие на демократической основе, которые ранее не признавали советского режима,

были вынуждены объединиться и пойти на компромисс с ним. В свою очередь советская власть решила этим воспользоваться и прекратить открытую внешнеполитическую борьбу против либеральных стран Европы, таких как Франция, Чехословакия, Испания. Таким образом, с одной стороны, большевики полагали, что сформируется благоприятная почва для распространения в них коммунизма, а с другой стороны, намеревались получить техническую и денежную помощь от этих государств для наращивания собственного военно-экономического потенциала [Исхаков: 2011. Б. 259].

Гаяз Исхаки полагал, что именно данными обстоятельствами (распространение коммунизма и материальная выгода) обуславливалась необходимость перехода к реализации формулы «построения социализма в отдельно взятой стране» и ее конституционализация в новом Основном законе СССР 1936 г. Демократизм Сталинской конституции был направлен на установление дипломатических отношений со странами Запада, и прежде всего, с Францией, Чехословакией и Англией. И через демократию, как подчеркивал татарский мыслитель, большевики приступили к саморекламированию. Выделенные в Конституции СССР 1936 г. такие слова как «свобода», «народоправство» и «справедливость» не имели подлинного смысла, а преследовали цель впечатлить среднестатистического европейского читателя. Однако это был сложный политический маневр, чтобы ввести в заблуждение всю европейскую общественность и сгладить враждебное антисоветское мнение в широких народных слоях, и в итоге получить материальную выгоду от богатейших стран Европы. Татарский политик подчеркивал, что это являлась самой важной причиной формального отказа от идеи «мировой революции» и перехода к реализации формулы «построения социализма в отдельно взятой стране» [Исхаков: 2011. Б. 259].

Также значимым обстоятельством, из-за которого советская власть облачила существующий правопорядок в стране в новые конституционные рамки, по мнению Г. Исхаки, стала продолжающаяся борьба нерусских народов за наделение национальных республик реальными правами. Он указывал, что лидеры национальных движений, оставшиеся в советском государстве, в итоге стали воспринимать большевизм как «национальную болезнь великороссов», а потому пришли к выводу, что единственный способ спасти свой народ от тирании коммунизма – это отделение от СССР [Исхаков: 2011. Б. 259].

Ситуацию вокруг национального вопроса в СССР, якобы решенного по заявлениям самой советской власти, как писал Г. Исхаки, внутри страны, так и за ее пределами складывалась иначе [Исхаков: 2011. Б. 260].

Гаяз Исхаки был убежден, что принятие новой Конституции СССР 1936 г., отчасти обусловлено страхом перед растущей в эмиграции силы национальных движений [Исхаков: 2011. Б. 261]. Современные исследователи также отмечают, что «наличие идей переустройства России, разрабатываемых за рубежом Г. Исхаки и другими лидерами тюрко-татарской эмиграции, рассчитанных на достижение определенного политического эффекта среди населения национальных республик СССР, равно как и само существование эмигрантских организаций и объединений, а также присутствие «националистического инакомыслия» внутри страны явились удобным «жупелом» для разворачивания репрессивных процессов против национальных кадров и интеллигенции указанных республик» [Гайнетдинов: 1997. С. 141].

Следил Г. Исхаки и за реакцией русской эмиграции на проект Основного закона 1936 г. В первую очередь татарского мыслителя интересовало ее отношение по вопросу правового положения национальных республик. Позицию русской эмиграции в спектре выбора стратегии борьбы с советским режимом, Г. Исхаки оценивал негативно, делая акцент на ее великодержавном и империалистическом характере. Это было отчетливо заметно в их размышлениях в части предоставленной большевиками нерусским народам национально-территориальной автономии. Русская эмиграция, как отмечал Г. Исхаки, данное право считало «чрезмерным» [Исхаков: 2011. Б. 260].

Подводя итоги, Г. Исхаки обращается к читателю с риторическим вопросом: может ли Основной закон одной страны стать конституционным примером для другого государства, если он исходит из краткосрочных политических расчетов правительства данного режима? Отвечает на него татарский мыслитель однозначно отрицательно – распространенный по всему миру тиражом в пятнадцать миллионов экземпляров проект Конституции 1936 года, не имеет никакой связи с волей населения СССР. Это всего лишь способ для юридического обхода различного рода будущих политических ситуаций. Гаяз Исхаки был твердо убежден, что новый Основной закон не упростит жизнь ни гражданам, ни народам СССР ни в одной их существующих сферах [Исхаков: 2011. Б. 252–261].

Завершая анализ Конституции СССР 1936 года, Гаяз Исхаки обращает внимание читателя на очень важный момент, что после обнародования (12 июня 1936 г.) нового Основного закона шестнадцать ближайших соратников (Г.Е. Зиновьев, Л.Б. Каменев, Г.Е. Евдокимов, И.П. Бакаев, С.В. Мрачковский, В.А. Тер-Ваганян, И.Н. Смирнов, Е.А. Дрейцер, И.И. Рейнгольд, Р.В. Пикель, Э.С. Гольцман, И.-Д.И. Круглянский, В.П. Ольберг, К.Б. Берман-Юрин, А. Эмель, Н.Л. Лурье) В.И. Ленина, сы-

гравшие огромную роль в становлении советской власти и распространении коммунизма, были расстреляны как «взбесившиеся псы» (здесь он использовал выражение Прокурора СССР А.Я. Вышинского) [Вышинский: 1938. С. 358]. Он подчеркивал, что данный процесс («Первый московский процесс»), который вела Военная коллегия Верховного Суда СССР 19–24 августа 1936 г., приговорившая всех подсудимых к высшей мере наказания (расстрелу), выступает хорошим доказательством подлинного понимания большевиками категорий «справедливости», «свободы», «равенства» [Исхаков: 2011. Б. 261].

В дальнейшем развитие советского конституционализма Г. Исхаки частично затрагивал и в других статьях [Зайнуллина: 2002. С. 13]. Например, в статье «Европейские политические настроения («Расширение Германии...»)» 1937 г. он вновь обращал внимание на фиктивность конституционных норм, на формальность закрепленных свобод [Исхаков: 2012. Б. 125].

Восприятие Гаязом Исхаки советского конституционализма резонно отличалось от других взглядов российской эмиграции. Татарский политик смотрел на Конституцию СССР 1936 г. исключительно как на идеолого-политический документ, целью которого было убеждение широких слоев населения Европы в прогрессивности и миролюбии коммунизма, чего по факту не имелось. Он отмечал, что неудача идеи «мировой революции» заставила большевиков «окраситься в приемлемые в Европе цвета», чтобы проникнуть в западный мир. Большевики стремились предстать «не в цвете мирового революционера, а в цвете ангела мира, который защитит Европу, который спасет Европу от следующей великой разрушительной войны» [Исхаков: 2012. Б. 125], – писал татарский мыслитель.

Гаяз Исхаки не считал Основной закон СССР 1936 г. принципиально новым юридическим документом, показывающий миру положительную эволюцию принципов советской правовой системы.

## Литература


1. Авакьян С.А. Конституционное право России. Учебный курс: учеб. пособие. В 2 т. Т. 1. – 5-е изд., перераб. и доп. М.: Норма; ИНФРА-М, 2014. – 864 с.
2. Баглай М.В. Конституционное право Российской Федерации: учеб. для вузов. – 6-е изд., изм. и доп. М.: Норма, 2007. – 784 с.
3. Вышинский А.Я. Судебные речи. – М.: Юрид. изд-во, 1938. – 520 с.
4. Гайнетдинов Р.Б. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века – 30-е годы. Набережные Челны: Камский издательский дом, 1997. – 160 с.

5. Зайнуллина Г.И. Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции: автореф. дис. канд. филол. наук: 10.01.02 / Зайнуллина Гульшат Ильфатовна. – Казань, 2002. – 24 с.
6. Исхаков Г. Аурупа сәяси әхвале («Германиядә бу киңәю...») (Европейские политические настроения («Расширение Германии...»)). Напечатана в газете «Национальное знамя» 6 августа 1937 года // Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 т. 12 т.: публицистика 1937–1938 / томны төз., текст., иск. һәм аңлат. әзерл. Зөфәр Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 120–144.
7. Исхаков Г. Большевик кануны әсасие (Основной закон большевиков). Напечатана в журнале «Новый национальный путь» № 9–10 1936 год // Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 т. 11 т.: публицистика 1934–1936 / томны төз., текст., иск. һәм аңлат. әзерл.; кереш мәкалә авт. З. Мәхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 252–261.
8. Конституция (Основной Закон) Союза Советских Социалистических Республик, утверждена постановлением Чрезвычайного VIII Съезда Советов Союза Советских Социалистических Республик 5 декабря 1936 года // Известия ЦИК Союза ССР и ВЦИК. 1936. № 283. 6 декабря.
9. Постановление Политбюро ЦК РКП(б) «О национальном размежевании республик Средней Азии» от 12 июня 1924 года // ЦК РКП(б)-ВКП(б) и национальный вопрос. Кн. 1. 1918–1933 гг. – М.: РОССПЭН, 2005. С. 784.
10. Султан-Галиев М.Х. Выступление на заседании X Всероссийского съезда советов 26 декабря 1922 года // Султан-Галиев М.Х. Избранные труды. Казань: Издательство «Гасыр». Приложение к журналу «Гасырлар авазы – Эхо веков», 1998. С. 409–410.

*Дамир Таҗи*

# ӘЛМӘТ АВЫЛЫ МӘХӘЛЛӘЛӘРЕНДӘ МӘЧЕТЛӘР ҺӘМ ИМАМНАР

(*Ахыры. Башын карагыз: №1, 2022; №1,2,4, 2023; №3,4, 2024; №1,2, 2025*)

## Түбән Чыршылы (Чәшеле) мәчете

Түбән Чыршылы яки Шәлчеле авылы ревизия язмалары буенча 1746 елдан билгеле. Димәк, бераз артка чигенеп авыл 1724–1730 елларда нигезләнгән дип әйтеп була. Әмма, архивта моңа капма-каршы килгән документ саклана. Самара губернасы Бөгелмә өязенә кергән мөселман мәхәлләләре исемлегендә (1915 елгы) Түбән Чыршылы авылында 1665 елда ук мәхәллә булуы күрсәтелгән. Димәк мәчет тә булган. Авыл мулласы Рахмангол Бәймәтевка 1746 елда 78 яшь булган (икенче ревизия язмасы Ж. Рәхимов хезмәтеннән). «Асар» китабында бу авылдан булган Хәсән бине Гаеднең Бөре өязе Көндәшле авылында Нурмөхәммәт мәдрәсәсендә «Һәдиятес-Сәгълүк» китабын язып тәмамлавы әйтелә. Якынча 1770 еллар булырга мөмкин. Безгә мәгълүм булган икенче дин әһеле, мөхтәсиб һәм мөгаллим, Тайсуган авылынннан Бикчура хан нәселеннән Габдрахман хәзрәт (1691–1764) Туймөхәммәтов әл-Бикчурави улы Гыйсмәтулла (1762–1844). Нәкъ ул килгән елларда, мөгаен, мәчет урамы барлыкка килә, агачтан мәчет төзелә. Мондагы бер мәдрәсәне яки мәчетне Казан сәүдәгәре, мөселманнарның аерым Ратуша мәхкәмәсе җитәкчесе Миңлебай бине Габдеррәшид бине Йосыф салдырган. 1859 елда вафат була. Өстә телгә алынган Гыйсмәтулла авылда мәдрәсә ача. Шунда үзе, улы Габделкаюм, оныгы Габделфәттах (1829–1891) 1858 елдан имам мөдәррис дин гыйлеме укыта. Габделфәттах хәзерге Чирмешән районы Кара Чишмә авылы мулласы Габденнасыйр Солтангали улының кызы Мәгъдәнүс белән никахланганын ишеткәнебез бар. Бу нәселдән бик күп дин әһелләре чыккан. Шул мәдрәсәдә галим якташыбыз Ризаэддин Фәхреддин 1868–1889 елларда укый һәм укыта. Әбисе Фәрхиҗамал остабикә

Гыйсмәтулланың кызы була. Ризаэддин Фәхреддин бабасы Сәйфетдиннең (1778–1861) атасы Сөбханкол хәзрәт турында мәшһүр «Асар» китабында болай яза: «Асыл ватанына кайтканда (укып) Куак елгасындагы Түбән Шәлчәле авылында имам булып, 33 ел гыйлем бирү, дәрес укыту илә шөгыльләнгән. Кичүчат авылында берничә ел тереклек итеп, 1808 елда вафат булган». Сөбханкол хәзрәт тирә-юнь авылларның старшинасы итеп сайлана. Авылда 1860 елда мәчет һәм 2 мәдрәсә булуы билгеле. Монда Шиһабетдин Гобәйдуллин 1848 елдан имам мөгаллим. Самара архивы документларында күрсәтелгәнчә (Ф. 1. Оп. 12. Д. 4484, Д. 5695.) беренче җәмигъ мәчет 1865 елда нигезләнә. Ул янып юкка чыккач, 1906 елның май аенда Самарада яңа проект кабул ителә. Монда 1877 елдан Мөхәммәтхәниф Габделкаюмов (1852) имам, аның бер туганының улы 1903 елдан Габделбарый Габделфәттахов (1875, 1881) имам һәм мөхтәсиб, мәзиннәре Кавый Мөхәммәтҗанов.

Икенче җәмигъ мәчет 1903 елда төзелә, мәдрәсәсе 1904 елдан эшли. Беренче имамы Самат Фәхретдинов булырга тиеш. Монда 1905 елдан Мөхәммәтзакир Әхсәнов (1860) имам, 1908 елдан Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтканифов (1885, Мөхәммәтхәниф улы булырга мөмкин) имам, 1905 елдан Сираҗетдин Сәлахетдинов (1875–1949) мәзин. 1910 елда ике мәктәп, волость идарәсе була. Аксакаллар 1921 елда мәчетләрнең берсе, бәлки яңасы янган диләр. Агач мәдрәсә тузгач (янган дип тә әйтәләр), ташны шомартып бина салына. Р. Абзалова-Сәлманова үзенең китабында («Иманлы төбәк җәүһәрләре», 2008.) болай дип яза: «Егерменче гасыр башында Габделфәттах ишан улы Габделбарый, табигый ташны эшкәртеп-шомартып, ике катлы мәдрәсә, уку бинасы һәм шәкертләр өчен бер катлы тулай торак төзетә башлый. Әмма 1914 елда, Беренче бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, бу эшләр туктала. Мәдрәсәнең дә беренче каты төзелеп бетми. Октябрь революциясеннән соң аны клуб итеп файдаланалар. Ә соңрак анда совет мәктәбе урнаша һәм ул 1962 елга кадәр хезмәт итә... Шул ук елны аны сүтәләр. Ә аның ташларыннан (мәдрәсә ташларыннан) мал-туар абзарына ошашлы бер катлы мәктәп бинасы төзелә. Берничә дистә елдан соң, 2003 елда, элекеге мәдрәсә урынында ике катлы яңа мәктәп бинасы сафка басты».

Тагын берничә мәгълүматка тап булдык. 1877 елда Түбән Чыршылы һәм Әлмәт авыллары кешеләре җирле мәктәпләргә урыс телен өйрәтү дәресләрен кертүне сорап хат язалар. Земствода гозерне кире кагалар. Бөгелмә өязе земстовасындагы вәкил (гласный) Шакир бай Хәкимов татарларга һәрвакыт хәйрия ярдәме күрсәтеп торучы буларак бу мәсьәләне хәл итеп, 1887 елда Түбән Чыршылыда урысча укыла торган татар мәктәбе ачарга рөхсәт алып бирә. Ләкин бу эшкә мөфти Мөхәммәтъяр Солта-

нов каршы төшә. Бүленгән акчалар файдаланмыйча кала. Авылларда күп кенә кадими муллалар урысча укытуны дингә хыянәт дип табып, моңа теш-тырнаклары белән каршы төшә.

Түбән Чыршылы (Чәшеле) волость үзәгендә 1910 елда 408 йорт, 1055 ир-ат, 1023 хатын-кыз, 2579 дисәтинә уңайлы һәм 191 дисәтинә уңайсыз җирләр, 2 мәктәп, 2 су тегермәне, Чыршылы һәм Куак инешләре була (Самара губернасының халык яши торган урыннары исемлеге. Самара, 1910 ел).

Түбән Чәшеле мәдәрәсәсе үз заманында иң алдынгы мәдрәсәләрдән саналган. Монда бик ерак татар авыларыннан да килеп укыганнар. Уку эшләре гел җиңел генә бармаган. «Вестник Оренбургского учебного округа 1915» дигән җыентыкта мондый юллар бар: «Так, в Самарск. губ., Бугульм. уезда, закрыты мусульманские школы в д. Шяльшилы, Менглибай, Чопай. В эти деревни явился урядникь и прочитал заявления от исправника, в которых было сказано, что школы закрываются так как мугаллимы (учителя) не имеют правительственных свидетельствь на право обучения детей грамоте». Мәдрәсә турында Җ. Рәхимев (Сайланма әсәрләр. Авыллар тарихы. 2008.) без белмәгән кызыклы хәбәрләр өсти: «Түбән Чыршылының мәшһүр мәдрәсәсе 1909 елда, Столыпин реакциясе чорында ябыла… Мәдрәсәдән тыш, мәчетләр каршындагы мәктәпләрдә дә балалар гыйлем эстәгәне билгеле. Малайларны Хәниф ахун һәм Барый мулла кебек дин башлыклары укытса, кызларга сабакны аларның остабикәләре биргән. Әмма мәктәпләрдә нигездә дин сабагы укытылган. Тик соңрак мулла Сиражетдин Бикчурин гына җәдит мәктәбе оештырырга омтылыш ясап карый, ләкин фанатик муллаларның кискен каршылыгына очрый. Алай да ул үз дигәненә ирешә: 1911–1912 уку елыннан башлап С. Бикчурин балаларга хисап, география, тарих, туган тел кебек дөньяви фәннәр укыта башлый. Аның укучыларыннан Һилал Мифтахов, Әһлегаян Фәтхетдинев һ.б. соңрак үзләре дә мөгаллим һәм мөгаллимәләр булып китәләр. Бикчуринның кызлары – Шәфика, Нәсимә, Наилә һәм Такияләр дә гомерләрен халык мәгарифе эшенә багышлыйлар». Ябылган мәдрәсә башка статуста ачылган булырга тиеш. Сараҗ мулла үз исәбенә Иске Куактан укытучы китертеп шәкертләрен урысча язарга-сөйләшергә өйрәтә, авылда җәдитчелеккә нигез салган, мәгърифәтче Каюм Насыйри алымы белән укытырга ярата. Сәнәкчеләр фетнәсендә, 1920 елда Куакбаш авылына алып китеп таш келәткә ябалар. Аны үлемнән кызыллар отряды коткара. Ике яклап та бик күп кешеләр утлы коралдан һәлак ителә. Сәнәкчеләр аны җәдитчә укытуда, театр оештыруда («Чикерткә» исемле комедия язган), кызын Бөгелмә педогогика училещесында укытуда гаепләп, «кызыл мулла» дигән кушамат тагалар. «Кызыл» булса да совет власте аңа мәрхәмәт күрсәтми. Мәдрәсәләр ябылгач, җәмәгате Бибисәкинә оста-

бикә белән үз өйләрендә ир һәм кыз балалар укыталар. Йортында тентү ясап Г. Тукай бүләк иткән китапларны, гомере буе җыйган дәреслекләрне, дини язуларын алып китеп юк итәләр. Совет тарафыннан рәхимсез рәнҗетүләрдән соң, ул укытуын, мәзинлеген һәм муллалыгын ташларга мәҗбүр ителә, колхоз эшенә йөри. Соңгы елларында кием тегеп, сәгатьләр төзәтеп, калайдан төрле әйберләр ясап, шуны базарда сатып көн күрә. Шуңа карамастан, Сираҗетдин бине Сәлахетдин бине Габделкаюм бине Гыйсмәтулла тыныч кына, советка күренмичәрәк 1949 елга кадәр авылда шәригать кагыйдәләрен башкара. Атасы Сәлахетдин дә, авылда имамәтчелек кылган диләр.

Менә шул мәдрәсә-мәктәпләрдә 1926 елда тирә-юнь авыллардан җыелып килгән дин әһелләренең зур җыены, очрашу уза. Бу җыен ике-өч көн барган диләр. Кунаклар мәдрәсәләрдә, авылда яшәүчеләрнең йортларында вакытлыча тукталалар. Сираҗетдин (Сараҗ мулла) хәзрәт шул кешеләрне аерым йортларга урнаштырып җыенны оештырып йөри. Бу нинди тантаналы җыен булган соң? Мөселманнарның Диния нәзарәте рәисе, мөфти Р. Фәхреддиннең Хиҗәзда (Согуд Гарәбстаны) Мөселманнарның Бөтендөнья конгрессында совет делегациясенең җитәкчесе буларак шунда катнашып кайтуы икән. Ул шул конгресснең вице-президенты булып сайлана, гарәпчә чыгыш ясый, аны шул илнең короле кабул итә. Дин әһелләренең Чыршылыга күпләп килүләре дә аңлашыла. Мөфтине күреп сөйләшү, аның вәгазьләрен тыңлау зур дәрәҗә санала. Әлбәттә, монда совет хакимиятенә бәйле рәвештә дин эшләренең торышы хакында сөйләнмичә калмагандыр. Мөфтинең Хиҗәзга совет делегациясе башлыгы булып җибәрелүе совет хөкүмәтенең дөнья җәмәгатьчелеге алдында вакытлыча күз буявы гына була. Шуннан соң озак та үтмәс дин әһелләрен авыллардан куу, мәчетләрне вату, канлы еллар килер. Әмма әлегә халык нәрсәгәдер өметләнеп киләчәккә планнар кора.

Икенче мәхәллә имамы Закир Әхсәнов турында Сараҗ хәзрәт кызы Наилә Бикчурина (1911–1996) кызыклы истәлек язма калдыра (1995): «Ул уку китаплары, дәфтәр, кәгазь-каләмнәр, кара савытлары, буяулар алып кайтып сату итте. Шуларны безгә бүләк иткәли иде. Акчасы булмаганнарга йомыркага бирә иде. Аңардан башка беркем дә уку әсбаплары белән сәүдә итмәгән. Балаларны бик ярата иде ул. Бик авыр хәлдә чирләп ятканда, без 7–9 яшьлек кыз балаларны үз янына чакырып алып, чәчләребездән сөйде. Остабикәгә китапларын безгә бирергә кушты. Әтиебез ул китапларны ятим балаларга өләште».

Совет елларында дин әһелләре рәхимсез рәнҗетелә. Габделбарый мулла совет талауларына каршы 1920 елда оештырылган «Кара бөркетләр» дигән сәнәкчеләр фетнәсендә катнаша. Ул атылудан, бик каты кый-

налып, котылып амнистиягә эләгә. Ике яклап та бу фетнәдә коточкыч рәхимсезлекләр кылына. 1929 елда Габделбарый мулланы Ислам динен яклап халык арасында зур чыгышлар ясап йөргүен гаепләп 3 елга концлагерьга хөкем итәләр. Йортыннан куып шунда китап уку ызбасы ачалар. Бу карар инвалидлыгы сәбәпле, Архангельск шәһәренә сөргенгә җибәрүгә алмаштырыла. Документларда аның 1937 елда Иркутск шәһәрендә яшәве, мәчет каравылчысы булып эшләве турында әйтелә. Шул ук елны кулга алынып 7 елга хезмәт белән төзәтү лагерына хөкем ителә. Тагын шул елда өченче тапкыр (Батуми шәһрендә тотылган дип әйтәләр) кулга алып Казанга кайтаралар. Улы Зәкәрия Саратов шәһәрендә тоткыннар йортында тәрәзә рамнары ясау белән шөгыльләнә. Төркия иленә качып китмәкче була. 1929 елда кулга алына, дәлилләр җитмәү сәбәпле эш туктатыла. 1937 елда Үзбәкстандагы Киршине станциясендә, «Заготзерно» конторасында бухгалтер булып эшли. 1937елда кулга алынып Казанга җибәргәннәр. «Хәтер Китабы» мәгълүматлары буенча: «Фәттахов Яхья Барый улы 1912 елда хәзерге Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылында туган. Татар, крәстиән. Гаиләсе: әтисе Барый (1880), әнисе Кәшифә (1885), кыз туганы Сүрия (1901, 1911), ир туганы Зәкәрия (1911), кыз туганы Фатыйма (1917), ир туганы Әгбәр (1923), ир туганы Һашим (1926). Гаилә 1931 елда Шөгер РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм сөргенгә җибәрү өчен расланган. 22.10.2008 елда акланганнар». Без Әлмәт авылына багышланган бүлектә Габделфәттах хәзрәт Габделкаюмовның кияүләре, кызы Хөсникамалның ире – Әлмәт имамы Һади Атласи, икенче кызы Зәйнәпнең ире – шулай ук Әлмәт имамы Рәшит Яруллин, улы Габделбарый Фәттахов һәм оныгы Габделбарый улы Зәкәрияләрне (9 кеше) һ.б. 1938 елда советка каршы баручылар дип гаепләп атып үтерәләр дип язып үткән идек инде. Габделфәттах хәзрәтнең бер туганы олы яшьтәге Мөхәммәтханиф ишанга 200 сум штраф салып, шул штрафны каплау өчен сигез почмаклы йортыннан куып, җимерелгән бер кара мунчага керткәннәр, 1930 елларда кулга алып киткәннәр дип сөйлиләр. Юлда үлгән булса кирәк. Хәтер Китапларына исеме кермәгән. Җәмәгате Маһирә абыстай озак тормый вафат була. Уллары Аллаһидат (1904–1942) белән Салих (1906–1945) Урта Азиягә китә, икесе дә Ватан сугышында һәлак була. Кызлары Мөршидә (1895) Кыргызстанда Ош шәһәрендә, Рәшидә (1889-1989) Ашхабадта, Салиха (1910–1989) Ташкентта җирләнгән. Ишанның хөтбә таягы турында әле дә төрле хәбәрләр сөйлиләр. Хәниф ишан дини вәгазьләрен хөтбә таягын тотып укырга яраткан. Хискә бирелгәндә шул таягы белән идәнгә шапылдатып ала икән. Ишан исеме бик сирәк кенә, иң дәрәҗәле дин әһелләренә генә бирелә. Халык аны үзе шулай олылап атап йөрткәнгә

ошый. Хөтбә таягын комсомол яшьләр урлап китеп юк иткәннәрдер дип ишеткәнем бар. Авылда дингә кагылышы булган бөтен мөселманнарны да вәхшиләрчә рәнҗетәләр, сүгеп һәм кыйнап вакытсыз гүргә кертәләр. Мәзин Кавый хәзрәтнең мал-мөлкәтен талап алалар. Ишанның ярдәмчесе Хәйрулла Иксановны (1867) да дини кануннарны яклаганы өчен 1930 елда кулга алып 3 елга концлагерьга ябалар. Авылның бае, өлкән мөрит (мәгънәсе: берәр мәзхәб башлыгы булган ишанга ант иткән турылыклы иярчен) Гыйльман Вәлиев та дин хакына рәнҗетүләр кичерә. Каралты-кураларын сүтеп йортына кадәр дуңгыз фермасы ачалар. Шунда кемнәрдер 33 дуңгызны агулап үтерә. Байны 5 елга концлагерьга озаталар. 2001 елда акланган. Бу авылда да бик күп кешеләр кулак муллалар исемлегенә кертелә. Дуңгызлар турында Роза Абзалова-Сәлманова ачынып болай язган иде: «... Аллаһ кушканча яшәүче мөселман авылына узган гасырның 30 нчы елларында дуңгыз дигән мал китереп тутырдылар. Авыл өстенә авып торган таулардан, урманнардан искән саф һаваны дуңгыз шакшысы исе, чинау авазлары алмаштыра. Әле дә хәтерлим: авыл эчендә, кая карама, пычрак дуңгызлар аунап ята иде. Затлы кешеләрнең ул-кызлары, менә шулай кинәттән, дуңгыз карауЧы, дуңгыз көтүчеләре булып куйдылар. Чәшелене зур бер афәт булып дуңгыз басты. 60 еллар уртасында аларның саны 2 меңгә якынлашты. Тагын да арткан булыр иде әле. 1967 елның 11 нче маенда, нәкъ төш вакытында Куак очындагы дуңгызчылык фермасында зур янгын чыкты…» Картлар моны үзара сөйләшкәндә Гыйльман мөритнең әйләнеп кайткан каргышы дип сөйли. Колхозлашу елларында, хәтта борынгы зиратларны да мәсхәрәлиләр, каберләр өстеннән юл ясыйлар, шунда теләсә нәрсә ташлыйлар. Соңарып булса да, авылдашлар зиратның бер өлешен тракторлардан өттерүдән саклап калалар, бакыйлыкка күчкән җаннарның каргышыннан котылалар. Түбән Чыршылыда үткән заманнан сакланып калган тарихи ядъкәрләр киләчәк буыннар өчен дә зур истәлек. Болар Р. Фәхреддиннең абыйсы Минһаҗетдин хәзрәт ясаган гарәп язулы кабер ташлары. Игелекле бәндәләр бу язма мирасны кубарылып ферма нигезенә салуга юл куймыйлар. Совет чорында дини эшләрне Таҗетдин Бәдретдинов кебек муллалар алып бара. Дин бервакытта да сүнми. Бигрәк тә өлкән буын арасында.

Безнең көннәрдә яңа мәчет ачылганчы бабайлар җомга намазларын медпункт бинасында укып йөриләр иде. Янәшәсенә тыйнак кына бер манара да бастырып куялар. Хәзер бөтен авылга «Әкрәм Хәбетдин» җәмигъ мәчете манарасыннан моңлы азан тавышы ишетелә. Әкрәм Хәбетдинов белән Нурлыгаян Әхмәдиевлар мәчет төзелешен башлап йөрүчеләр. Монда Тәлгать Ногмановлар имамәтчелек кыла. Бүген имамлык Фәрит Шәрәпов кулында.

## Югары Чагадай мәчете

Бу авыл 1730 елларда нигезләнеп, Мордва-Кармалка волостена, соңрак Мордва-Афонькино волосте Бөгелмә өязе Самара губернасына керә. Бүген Чирмешән районы биләмәсендә тора. Авылның беренче имамнарын ачыклау безгә насыйп булмады. Чагадайда беренче җәмигъ мәчет 1829 елда нигезләнә. Искерүе сәбәпле 1898 елда таш нигездә агачтан яңа мәчет төзелә башлый. Аның проекты шул елның май аенда Самара губерна идарәсенең төзелеш бүлегендә раслана. Бу мәчеттә авылда 1868 елдан имамәтчелек иткән Абдулхалит (Габделхалит) Бәһаутдинов (1848) эшли. Аңардан соң 1911 елдан Әхмәтзыя Абдулхалитов (Габделгалимов, 1881), 1916 елдан Фахразый Низаметдин улы Хөснетдинов имамннар.

Икенче җәмигъ мәчет 1912 елда ачыла. Проекты 1910 елда ук расланган була. Мәктәп тә шул елдан эшли. Аңа кадәр ук беренче җәмигъ мәчете бинасында мәдрәсә эшләп килгән була. Икенче мәчеткә Абдулһади (Габделһади) Зыятдинов (1887) имам итеп билгеләнә. Мәгълүматлар Самара архивыннан алынды (Ф. 1, Оп. 1, Д. 2280).

1910 елда авылда 176 йорт, 573 ир-ат, 599 хатын-кыз, 1479 дисәтинә уңайлы һәм 29 дисәтинә уңайсыз җирләр, җил тегермәне, янәшәдә Исемсез коры чокыр булган (Самара губернасының халык яши торган урыннары исемлеге. Самара, 1910 ел).

Бу авылдан атаклы мөгаллим һәм ахун Хөснулла Бәһаутдинов (1857–1937) чыккан. Туган авылында өч еллап башлангыч дини белем алгач, Түбән Чыршылының мәшһүр Габделфәттах хәзрәт Габделкаюмовның мәдрәсәсендә танылган мәгърифәтче, булачак мөфти Ризаэддин Фәхреддин белән бергә сабакка йөриләр. Хөснулла хәзрәт Самара ягындагы Иске Ярмәк авылында имамәтчелек һәм мөгаллимлек итә. Шул авылда якташыбызның тууына 150 елны тантаналы төстә билгеләп үттеләр.

Совет чорында авылда дингә мөнәсәбәте булган бөтен кешеләрне дә «кулаклар», «милләтчеләр» дип төрмәләргә утырталар, йортларыннан куып авылдан сөрәләр. Халыктан талап алынган мәчетләрнең берсенә совет клубы, икенчесенә совет идарәсе кереп урнаша, соңыннан биналарны искерүе сәбәпле сүтәләр. Муллалар юк ителгән еллардан алып бүгенге көннәргә кадәр элек мәдрәсәләрдә әзме-күпме укыган, дин турында сорап, үзлегеннән өйрәнүчеләр шәригать кануннарын башкарганнар. Мәчетләрне җимергән елларда, авылдагы күп кенә истәлек кыйммәткә ия язуларны Хәниф Мөхәммәтвәли улы Вәлиев (1903–1959) үзендә яшереп саклый, гарәп хәрефләре белән авыл тарихын яза, шәҗәрәләр төзи. Аның кульязма китабын кызы Мәдинә апа 1990 елларда тәрҗемә итеп, авылдашлары бертуганнар Фәрхәд, Фазыйл, Фәһим Фәхруллиннар булышлы-

гында һәм Зәки Кәримов ярдәме белән кайтарып авыл халкына тарата. Бүген Казанда яшәүче Мәдинә апа Әбделганиева (1945) мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, Каюм Насыйри исемендәге бүләк лауреаты һ.б., фәкыйрегезгә киң күңеллелек күрсәтеп үзенең белгәннәре, ишеткәннәре белән уртаклашты. Без аны киләчәк буыннарга барып ирешсен дип язып алдык: «Гыйлем иясе, имам һәм мөгаллим, авылыбызның хөрмәтле мәгърифәтчеләренең берсе Әхмәдзыя мулла, җәмәгате Хөҗәөстә абыстай. Әхмәдзыяның атасы Галимулла Баһаутдин бабай улы. Баһаутдиннең Хөснулла исемле улы танылган ахун булуын сез инде беләсез. Галимулланың Хәниф исемле улы Миңлебай авылында имамәтчелек иткән, Мансур исемлесе – Яңа Ярмәктә имам, Әхмәдзыясы Югары Чегодай имамы дип әйттек. Әхмәдзыяны ни сәбәптәндер, Бөгелмәдән мөселманнар җыеныннан кыш көне кайтканда, Мордва-Афонькино авылы янында, якынча 1919 елда (1920 елгы сәнәкчеләр фетнәсе вакытында үтерелгән дию дөресрәк кебек) атып үтергәннәр. Аның белән бергә чанада утырып кайткан Җиһангир бабай, берничә мәртәбә артыннан атуларына карамастан, бер мукшының өенә кереп үлемнән котыла алган. Имамның җансыз гәүдәсен ат капка төпләренә алып кайтып туктый. Аны бик зурлап җирлиләр. Миңнебай Мөхәммәтшинның аның турында язган мөнәҗәте бүгенге көннәргә кадәр сакланган. Җиһангир белән Әхмәдзыяның этиләре бертуганнар. Шул ук нәселдән Сәхабетдин Дәүләтша улы авылыбызның иң оста азанчысы, мәзине булган. Совет чорында бик каты рәнҗетелә, малларын талап алалар, йортында тентүләр ясала. Ул Ватан өчен сугышта тагын бер кат коммунистлар өчен газаплар чигеп шәһит була. Авылның тагын бер мулласы Һади Зыятдинов Лениногорск районы Урдалы авылыныкы. 1937 елларда Казанда «черек күл»дә атып үтерелгән дигән хәбәрләр дөреслеккә туры киләдер, мөгаен. Балалары сугыштан соң Ташкент якларына күчеп киткәннәр. Авылыбызда сугыш елларында һәм аннан соң Фахразый Рафиков, Закирә остабикәләр дин башында тора. Рәхмәт яусын».

Бөгелмә кантоны буенча 1930 елга кадәр үз вазыйфаларыннан баш тартучылар исемлегендә Югары Чагадайның беренче мәхәлләсеннән имам Фахразый Рафиков (1884), азанчы Гатаулла Гайнуллин (1882), икенче мәхәлләдән имам Һади Зыятдинов (1888), азанчы Дәүләтша Баһаутдинов (1853) исемнәре бар (Татарстан милли архивы: Ф. 7200, Оп. 1, Д. 733). Алар атып үтерелү, сөргенгә куылу һәм талау белән куркытыла. Әмма барыбер ачы язмышларыннан котыла алмыйлар.

1990 еллардан соң дингә ирек бирелгәч Югары Чагадайлылар да авылга мәчет кирәклеген аңлый. Бу хакта сугыш ветераны, унҗиде яштән 1943 елда фронтка киткән, совет армиясеннән әле 1951 елда гына кайтып

кергән, районның танылган шәхесе Касыйм Исмәгыйлев та (1925) борчыла. Касыйм ага яштән үк михнәтләр күреп, «кулак малае» дип кыйналып, авырлыкларга түзеп үскән кеше. Әтисе Исмәгыйль Мортазин диндар мөселман булып гарәпчә һәм урысча укый-яза белгән, үзе белән һәрвакыт Коръән тоткан, үзен рәнҗеткәндә дә изге китапны укып рухи газапларын җиңеләйткән. Авылда «Правда» газетасын укыган бердәнбер гыйлем иясе дә ул. Сталин колхозга мәҗбүриләп кертмәскә әйткән дип газетада язылган дигәне өчен, Чирмешән, Бөгелмә төрмәләрендә җәфа чигә. Колхозга керүе, ике сыерын, ике атын, җигү дирбияләрен колхоз милкенә бирүе дә исәпкә алынмый ун балалы атаның. Соңыннан үзе укыткан шәкертләре аны, олы яштәге кешене көтүче итеп куя.

1991 елның 16 апрелендә бик күп авылдашлар сугыш инвалиды Әшрәфулла Галиуллин йортына Ураза бәйрәменә җыелалар. Намаздан соң аксакалларның берсе Әхмәтзыя Фаварисов авылда мәчет төзергә кирәк дип чыгыш ясый. Аның тәкъдиме бертавыштан кабул ителә. Әшәрәфулла һәм Әхмәтзыя бабайлар шунда ук төзелешкә акча җыюга керешә. Әмма бу зур эшне башкарып чыгу өчен оештыручы кирәк бит. Халык уйга кала. Шунда Минвәли Фәхретдинов: «Аптырап торасы юк, арабызда авылдашыбыз Касыйм Исмәгыйлев бар бит. Күршедәге Иске Үтәмеш авылында озак еллар колхоз рәисе булып эшләде, борынгы мәчетләрен төзекләндерде, төрле хуҗалык корылмалары төзүне башлап йөрде, тәҗрибәсе зур, әйдәгез аңардан сорап карыйк әле», ди. Миннеәхмәт Нәзиров, Әбелгата Шәмгунов, Сәгыйдулла Билалов, авыл мулласы Сәмигулла Хөббәтуллиннар да бу фикерне хуплап чыга. Шул ук җыелышта мәчетнең сызымнарын, проект-смета документларын әзерләү бурычы Касыйм агага йөкләнә һәм ул мәчет нигезен төзеп куярга вәгъдә итә. Язулар тупланып беткәч, җәй айларында мәчет урыны сайлап алына. Бу җирдә коллективлаштыру елларында бәнахакка рәнҗетелгән Юныс Баһаутдинов, Сәйфетдин Садриев, Исмәгыйль Мортазиннарның йортлары торган була. Шул елда мәчет нигезе салына һәм эш шуның белән тукталып та кала. Бу эшне дәвам итәргә беркем дә алынмый. «Касыйм да булдыра алмагач, кая инде аны безгә ерып чыгу» диләр, авылдашлар. Берәүләр мәчет фундаментларын сатып, акчасын халыкка таратырга дип, икенчеләре бәлки агач мәчет төзергә кирәктер дип киңәшләшәләр. Бу хәлгә Касыйм ага да кайгыра. Бер ел узып та китә, эш ничек башланган, шулай кала. Мәчет нигезен карап йөргәндә, аңа авылдашы Фәгыйм Фәхруллин очрый. Ул да моңа бик борчылып: «Касыйм абый, син башлагансың икән, эшне болай калдырма инде, акчалата да, материаллар белән дә булышырбыз» ди. Бу сүзләрдән соң аның рухы күтәрелеп китә. Сугыш елларында нинди генә авырлыклар күрмәде ул. Монда да сынатмас, иншалла.

Аллаһының рәхмәте белән ярдәм итүчеләр дә табыла. Авылдашы Шәрипҗан Әюпов районда бер төзелеш оешмасы җитәкчесе ярдәме белән кирпеч, тимербетон плитәләр, цемент кайтара. Апасының өлкән улы Наил Мортазин (элекеге «Җәлилнефть»идарәсе җитәкчесе) торбалар, керамик кирпечләр белән булыша. Икенче апасы Кәримәнең улы Әбүзәр Мортазин (райпо рәисе) фундамент блоклары, манара өчен металлконструкция бирә. Шулай ук хәзерге «Татнефть» (җитәкчесе Шәфәгать Тәхаутдинов), Чирмешән районы башлыгы Минсәгыйть Шакиров, «Чирмешәннефть» идарәсе җитәкчесе Габдрәшит Җамалетдинов, «Татнефтепром» җитәкчесе Ралиф Зарипов, Чагадай егетләре, урман хуҗалыгы директоры Рәфкать Мотыйгуллин, бүгенге көндә Казанда яшәүчеләр Фәгыйм һәм Фазыл Фәхруллиннар, «Норлатнефть» идарәсе җитәкчесе Марат Хуҗин, «Татнефтебитум» баш инженеры Николай Дещевых, Зәй тимербетон эшләнмәләр заводы директоры Шамил Салахов, «Агрохимсервис»тан Солтан Халиуллин, «Сельхозтехника»дан Сөләйман Мөхәммәтшин, күрше колхоз рәисләре Рөстәм Харисов, Газимҗан Сәлахетдинов, Мәсхүт Хөсәенов һәм башкалар мәчетне сафка бастыруда үз өлешен кертә. Мәчетнең диварларын Елховой авылыннан Фәрһәд Тукаев, Ринат Мөхибуллин, Харис Нуретдинов, Таһир Закиров сала. Түбәне ябу эшләрен Иске Үтәмеш осталары Исхак һәм Азат Мингуловлар башкара. Манара проектын Касыйм ага үзе ясый. Ярымайны Иске Үтәмешнең Халим хәзрәт улы Әхмәтзәки абзый эшли. Ул Чирмешән мәчетенә дә менә дигән ярымай ясады. Касыйм ага бер кышта авылдашларын иптәшкә алып, алты тапкыр Мәскәүгә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре илчелегенә матди ярдәм сорап бара. Үҗәтлеге бушка китми. Илчелектән Габделхәким хәзрәт Чагадайга килеп хәзерге акча белән 300 мең сум сәдака биреп китә. Әлбәттә, бүген бу сүзләрне язарга бик җиңел. Татар авылларында гыйбадәтханәләр зур авырлык белән, аерым фидакаръләрнең батырлыгы бәрәбәренә, Аллаһының сынауларын узып төзү мөмкин була. Кырык градус салкында Касыйм аганың фигуралы такталар алырга дип 400 чакрым ераклыктагы Мари иленә чыгып китүе (вакытында алмасаң тагын ярты ел көтәргә кирәк), юлда машинаның радиаторы ярылуы, ун чакрым саен радиаторга шофер белән су өстәп тору, авылга кире әйләнеп кайтмыйча гел алга бару нинди сокланырлык батырлык ул. Шуннан соң өзлегеп китеп катлаулы операция кичерүләре...

Югары Чагадай мәчете 1995 елның 29 апрелендә олы бәйрәм булып ачыла. Моның кадәр халыкның җыелуы, хәтта сабан туенда да күзәтелми. Казаннан баш казый Габделхак хәзрәт Саматов та килә. Мәчеткә тантаналы төстә мөтәвәлли рәисе, мәчетне төзетүченең хөрмәтенә «Әбелкасыйм» исеме бирелде һәм ул моңа лаек та. Әле, совет хакимлеге

чорында, Иске Үтәмештә ул колхоз рәисе булып эшләгәндә, авылдагы иске мәчетне күреп (районда сакланып калган бердәнбер мәчет) обком секретаре М. Мусин, сезгә бу мәчет комачауламыймы соң дип мәсьәләнең мөгезеннән тотып ала. Янәшәдәгеләр бу сораудан каушап, ни әйтергә белмичә, бер-берсенә карап, аптырап, тынып калалар. «Мәчет тә бетте, Касыйм да бетте» дип уйлыйлар озата баручылар. Бәлки Мусин, мәчетне сүтәргә әмер дә бирер? Обком секретаренең һәр сүзе закон бит. Касыйм ага җитдилек күрсәтеп, мәчетсез авылларда эшләрнең артка калуы, ә менә Үтәмеш мәчетендә сөйләнгән вәгазьләрнең хезмәт итүдә игенчеләргә куәт биреп торуын, алдынгылыкка чыгаруын аңлата. Җавап Мусинга да ошый. – Әгәр файдасы бар икән, моның өчен сезне мактарга гына кирәк, – ди ул. Бар да җиңел сулап куя. Үтәмешкә СССРның авыл хуҗалыгы министры Месяц килгәч тә, эшләгән мәчетне күреп, гыйбадәт кылуны хуплаган икән. Касыйм ага Үтәмеш мәчетен саклап калуда да тырыша, аны төзекләндерергә материаллар табып бирә, мәчет янындагы яр ишелә башлагач, шул тирәдәге берничә йортны башка җиргә күчереп дамба салдыра. Бу вакыйгалар һәм үзе турында «Жизнь прожита не зря» исемле берничә китап язып киләчәк буыннарга истәлек калдыра. Китап Чирмешән төбәге тарихының матур бер сәхифәсе. Касыйм ага 2012 елда мәрхүм булды.

### Лашман мәчете

Лашман авылы унсигезенче гасырдан билгеле. Күпчелек, ул унтугызынчы гасыр башында оеша башлаган дип сөйли һәм матбугатка яза. Башта аны Вәлит авылы дип йөрткәннәр. Петр патша заманнарында Казанда адмиралтейство төзелгәч, бөек империягә яңа сугышлар алып бару өчен кораблар төзергә шул тирәдәге Килмәк дигән урманнан имән бүрәнәләр әзерләгәннәр. Шунда мәҗбүри эшләтелгән крестьяннарны «лашманчылар» дип атаганнар. Адмиралтейство Әстерхан каласына күчкәч, лшаманчыларга янәшәдәге Вәлит авылына урнашырга рөхсәт ителгән. Шулай итеп Вәлит Лашманга әйләнгән. Лашман элек Самара губернасы Бөгелмә өязенә кергән, хәзер ул Чирмешән районында.

Лашманда беренче җәмигъ мәчет 1875 елга кадәр билгеле. Яңа бинасы 1876 елда төзелә. Мәчет каршында мәктәп эшли. Монда 1913 елның гыйнвареннән Мөхәммәтканиф Хәсәнов Мөлеков (1883) һәм шул елның июненнән Әхмәткасыйм Лотфуллин (Исхаков, 1890) имамнар, Җиһангир Исхаков (1866, 1859) 1907 елның нояберennән мәзин. Икенче җәмигъ мәчет 1907 елдан эшли. Имамы Миннефатыйх Вильданов (1883) үз вазыйфасына 1908 елның августында билгеләнә. Мәзиннәре 1910 елның августыннан Мәгъданур Ибраһимов (1882). Өченче җәмигъ мәчет 1912 елда ачыла. Имамы Хәбибулла Хәлиуллин Максудов (1886) 1913

елның сентябреннән үз вазыйфасына керешә. Рәсми төстә билгеләнгән мәзиннәре булмый. Мәгълүматлар Самара архивыннан алынды.

Бу авылда элегерәк, 1851 елдан Иске Баграж Елховойдан Исхак хәзрәт Мөхәммәтҗанов (Мөхәммәтшәрипов?) указлы мулла. Аның улы Гыйләҗетдин хәзрәт Чистай өязендәге Яуширмә авылы имамы. Гыйләҗетдиннең улы Гаяз Исхакый (1878–1954) бөек язучы, татар милли азатлыгы хәрәкәте башлыгы. Исхак мулла вафатыннан соң, Лотфулла исемле улы Лашманда 40 ел имамәтчелек итеп 1914 елда мәрхүм, икенче улы Җиһангир мәзинлек итә. Лотфулланың улы Әхмәткасыйм Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып кайтып, туган авылында урта мәхәлләдә имам һәм мөгаллим булып хезмәт итә. 1931 елда «дини милли кулаклар оешмасында катнашучы» дип гаепләнеп 10 елга концлагерьга җибәрелергә хөкем ителә. Бераздан өенә кайтарып җибәрәләр. Әхмәткасыйм хәзрәт 1937 елда янә кулга алынып, милли баш күтәрүдә һәм бәйсез төрки дәүләт төзүдә гаепләнеп, Әлмәт (бүген шәһәр) имамнары һәм Түбән Чыршылы (Лениногорск районы) имамы Габделфәттах хәзрәт кияүләре язучы һәм тарихчы Һади Атласи, Рәшит Яруллин, бертуган мәгърифәтчеләр Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар, Габделфәттах хәзрәтнең улы Габделбарый, оныгы Зәкәрия Габделбарый улы һ.б. бергә 1938 елда (барысы 9 кеше) Казанда атып үтерелә. 1958 елда акланганнар. Язучы Фатыйх Әмирхан (1886–1926) китапларының берсендә Г. Исхакый әнисе ягыннан Болгарны торгызырга дип 1769 елда шунда зур халык җыены уздырган мәшһүр Морат мулла нәселеннән икән. Фатыйх үзе дә шул нәселдән. Интернет-язмаларда Г. Исхакыйның бабалары борынгы болгар Яушлар нәселенә туган диелгән. Арча князе Яушның 1552 елда Казанны Иван Грозный гаскәрләреннән саклап сугышуы тарихта мәгълүм.

Верхне-Кармальская волостена кергән Лашманда 1910 елда 318 йорт, 938 ир-ат, 894 хатын-кыз, 2454 дисәтинә уңайлы һәм 346 дисәтинә уңайсыз җирләр, 3 җил тегермәне, Сөлчә инеше булган (Самара губернасының халык яши торган урыннары исемлеге. Самара, 1910 ел).

Мәшхәрле 1931 елларда мәзин Җиһангир Исхаков та кулга алынып 5 елга хөкем ителә. Әмма 1932 елда инвалидлыгы сәбәпле вакытыннан алда иреккә чыгарыла. Шәрип мулла Динмөхәммәтов, Кәшиф мулла Мөлековлар да рәнҗетелә. 1989 елда акланганнар. Авыл крестьяннары Гата Ибраһимов (1869), Шәрифулла Вәлиев (1878 елгы, Бөгелмә төрмәсендә кыйнап үтергәннәр), Сәлах Гыйльманов (1876) һәм башкалар дини милли оешмаларга катнашкан дип төрмәләргә озатыла, гаиләләре мәсхәрә ителә.

Лашман мәчетләре «югары оч», «түбән оч», «урта мәхәллә мәчете» дип халык хәтеренә кереп кала. Түбән оч мәчете 1914 елда яна. Шул ук

елны бөтен мәхәллә белән яңа мәчет төзеп куялар. Монда Габдерәүф хәзрәт Мөлеков имамлык итә, аннан соң бу вазыйфа Хәбибулла Хәлиуллинга күчә. Хәбибулла (Хәбүш) хәзрәт авылларда репрессияләр башлангач, Самара шәһәренә китеп котыла. Аның эшен мәзин Ишмөхәммәт бабай дәвам итә. Мәчет 1940 елларда ябыла. Мәчетләрне ябу «халык соравы» буенча башкарыла. Бинасы 60 елларга кадәр төрле максатларда файдаланыла. Урта мәхәллә мәчетенең манарасын 1938 елда кисәләр, бинасын мәктәп итәләр Биредә 1914 елга кадәр «карт мулла» Лотфулла Исхаков, аннан соң улы Әхмәткасыйм халыкка хезмәт итә. Бу мәчет урынында безнең көннәрдә таш мәчет төзелеп, ул инде 20 еллап дин мәгърифәте тарата. Өченчесе, югары оч мәчетендә Кәшиф Мөлеков имам мөгаллим. Бинасы 1960 елларда сүтелә.

Авылда мәчет төзүне Минвәли Закиров (1920) башлап йөрүгә алына. Сугыш ветераны Габдулла Мөхәммәтшин (1925) проектны төзеп, прораб, ярдәмче була. Мәчет төзелешенә бөтен авылдашлар диярлек үз өлешен кертә. Күрше авыллардан, бигрәк тә Кармыш авылыннан булышалар. Лашман мәчете 1991 елның 3 нче мартында ишекләрен ача. Аңа авылның атаклы имамы, мөгаллим һәм җәмәгать эшлеклесе «Касыйм Исхаки» исеме бирелә. Мәчет төзүдә тырышкан авылдашларның исемнәре: Миншакир Гатауллин, колхоз рәисе Фазыл Ибәтуллин, Нурислам Мөхәммәтҗанов, Миндар Шәрифуллин, Габдрахман Мөхәммәтшин, Сөләйман Мөхәммәтшин, Фәргать Гатин, Ильяс Ризванов (ай ясатучы), Мингата Сөнгатуллин, Миншакир Хамидуллин, Хаким Мөхәммәтҗанов, Рәшит Җамалетдинов һ.б. Габдулла хаҗи Мөхәммәтшин сөйләгәннәрдән: «Мине сугышка 1943 елның башында 17 яшемдә алдылар. Ул елларны мәчетләр ябылган, муллалар кайсы сөрелеп, кайсы качып киткән, диннең тамыры корып бетү алдында иде. Ураза тоткан балаларны су каптырып уразаларын бозалар, ата-аналарын каты шелтәлиләр иде. Шулай да дини гореф гадәтләрне мәдрәсәләрдә бераз гыйлем алырга өлгергән картлар башкарды, намаз укучылар да бар иде. Үзем сугыш беткәч тә армиядә озак хезмәт итеп 1950 елда гына авылга кайтып кердем. Динне эзәрлекләү беркадәр тукталган иде. Өч мәхәллә намазлары өч йортта укылды. Сафиулла һәм Галимҗан бабайларда, Җәмаилә әбиләрдә. Гает намазларын зиратларда уку 1990 елларга кадәр гадәти хәл иде. Аллаһыга шөкер, бүгенге мәчетебез зур һәм иркен. Мәчетнең буе 18, иңе 10 метр, биеклеге, аена кадәр 24 метр. Эче урталай пыяла белән бүленгән, өчтән бере сөннәт бүлмәсе. Манарага эчтән менәргә, залында 300дән артык кеше гыйбадәт кыла ала».

«Касыйм Исхаки» мәчетендә эшләгән имамнар Хәйдәрҗан Җиһангиров (1991–1992, Җиһангир мәзин улы), Минвәли Закиров (1992–1998),

Габдулла Мөхәммәтшин (1998–2005), Хәниф Гыйниятуллин, Раил Нәзиров (2005–2006), Рәдиф Сөләйманов, Мингариф Гатин, мәзиннәре Миншакир Гатауллин. Мәчетләренең проектын Иске Кади, Киекле (Бурмәт), Кизләү, Денис (Бикмәт) авылларыннан килеп сорап алганнар.

«Туган җиребез – Лашман» дигән китабында (1998 ел) Гаяр Газыймҗанов дин бүлегендә бай мәгълүмат китерә. Без аны бераз кыскартып, авылның дини тарихын укучыга тирәнрәк аңлату өчен куябыз: «Дин әһелләре турында беренче тарихи мәгълүматлар «Дело с ведомостями Бугульминского уезда и других уездных полицейских управлений Самарской губернии о мечетях числящихся при них духовных лиц за 1863 год» дип аталган архив документында күренә. Анда башта Әмир авылындагы мәчет, шунда гыйбадәткә йөрүчеләр саны (260), муллаларның исем-фамилияләре (Гафиятулла Абдулмазитов 1851), (Абдулмазит Баширов 1835) искә алына; аннан соң чыганактагы юллар түбәндәгечә дәвам итә: «В этой деревне состоит прихожан деревни вновь заведённой Лашманкиной, а в ней богомольный дом. Прихожан 305. Исхак Мухаметшарипов имам хатип с 14 марта 1851 г.». Димәк, әле бу чорда Лашманда гыйбадәт кылу йорты булса да, манара торгызылмаган булган, шуның өчен ул документта «богомольный» дип атала һәм Әмир мәчетенә карый булып санала. Исхак хәзрәт зур мәдрәсәдә төпле белем алып, мулла булырга имтихан тоткан, Түбән Абдул авылы мулласы Мөхәммәтшәриф мулла малае була. Ул яшәгән чорда гыйбадәтханәнең манарасы торгызыла, ләкин әле мәчетнең башы да, манара ян-яклары да кабык белән ябылган, кадакланган була.

Авылның түбән очына килеп урнашкан элеккеге керәшен татарларын дини яктан кысрыклау үткән гасыр азагына кадәр дәвам итә. Алар мәетләрен күмүне аерым каберлектә башкарган, аларны мәчеткә дә кертмәгәннәр, аларга кыз бирмәгәннәр, алардан кыз алмаганнар, ябышып чыккан кызларга никах укытмаганнар. Чишмә башындагы Нигъмәтулла кызы Фатыйма түбән оч егетенә ябышып чыккач, алар никахны Денис авылына барып укыталар. Картлардан оештырып җибәрелгән берничә кешелек делегация, Самарага барып, губернатордан махсус язу алып кайткач кына аларны Ислам җәмгыятенә кабул иткәннәр. Гасыр башында инде алар да тыйнак кына мәчет бинасы салуга ирешкәннәр, ләкин 1913 елда түбән очтан чыккан янгын авыл уртасындагы чишмәгә кадәр булган ярты авылны көйдереп ала, шунда түбән оч мәчете дә янып бетә. 1910 елда волость старшинасы итеп Лашман кешесе Мохиббулланы куйгач, ул Чирмешән бае Чухайдан югары очка мәчет слуда булышуын үтенә. Чухай ярдәм итә. Янган түбән оч мәчетен Керкәле авылы бае 1915 елларга төзеп өлгертә. Бу мәчеттә башта Габдерәүф муллалык итә, 1928 елдан Киеклегә имам

булып күчә. Аның урынына калган Хәбүш балаларны укытканда дөньяви фәннәр дә укыта. Кадими картларга бу ошамый, алар Хәбүшне эшеннән куа. Аннан соң 1930 елның башында, кулга алынып төрмәгә озатылганчы Шәрип Динмөхәммәтов имамәтчелек итә. Ишмөхәммәт мулла һәм мәзин булып кала. Югары оч мәчетендә Фатыйх, Кәшип муллалык итәләр. Исхак мулла оныгы Мәгдәнүр мәзин була. Урта мәчеттә Касыйм Исхаков имам, Җиһангир Исхаков мәзин. 1911 елда урта мәчет янында мәдрәсә төзиләр, анда 50шәр баланы Касыйм һәм Кәшип хәзрәтләр укыта. Совете власте урнашкач мәдрәсәдә совет мәктәбе ачыла.

Урта мәхәллә дин тотучылары 1926 елда искесе урынына яңа зур мәчет өлгертәләр. Манара очына айны Хәмәтзыя Лотфуллин куя. Монда 1934 еллардан соң төрмәдән кайткан Касыйм хәзрәт үз вазыйфасына керешә. 1937 елда Касыйм мулланы Гаяз Исхакый белән хат язышуда, аңардан күрсәтмәләр алуда, Һади Атласи белән элемтәсе булганга һәм башка санап бетергесез гөнаһларда гаеплиләр. Атласи Чыршылы мулласы Габделбарый Фәттахов сеңелесе Хөсникамалга өйләнгән була. Габделбарый һәм Касыйм Елховойның бай сәүдәгәренең ике бертуган кызларына өйләнгән була. Менә шулай итеп, хатыннар аша кардәшлек җепләре аларны Чыршылыда да, Лашманда да еш очраштыра. 1913 елда сөргеннән кайткан Гаяз Исхакый Лашманга туганнарын күрергә килгәч, монда алар Һ. Атласи белән очрашалар.

Авылларда мәчетләр ябылгач гыйбадәт кылу өчен картлар аерым йортларга җыелалар, элеккеге һәр мәхәлләдә мондый йортлар 3–4 була. Мулла булу өчен бу чорда инде мөфтияттән указ кирәкми, ә райбашкарма комитеты рәсми мулла булдыруны рөхсәт итми. Мәсәлән, 1940 елда Төхфәтулла Мөхетдинов законлы юл белән Лашманның икенче мәхәлләсендә мулла булырга тели. Үтенеч гаризасын райбашкарма комитеты кире кага. Авылдашыбыз Габделбарый Мөлеков сугыш башлангач читтән кайтып, колхозда хисапчы булып эшли, моңардан тыш үзенең дини вәгазьләре белән шөһрәт казана, аны хәзрәт дип йөртәләр. Сугыштан соң аны Кизләүдәге дини оешманың җитәкчесе – имам итеп күчерәләр. Авылыбызда Хәматгали Вәлиев, Талибетдин Гәрәев, Хәматзыя Нуруллин, Хәйретдин Гайнетдинов, Габдулла Яруллин, Сәлимҗан Гыйматдинов, Шәмсетдин Шәйхетдинов, Сәхап Җәләлетдиновлар дин эшендә олы хөрмәткә лаек.

*Р.А. Бушков*

# У ПОЮЩЕГО САМОВАРА
(*Окончание. Начало читайте № 2, 2025*)



*Р.А. Бушков с отреставрированным кукморским самоваром конца XIX в.*

Увлекшийся изучением жизни казанских татар один из первых профессоров учрежденного в 1804 г. Императорского Казанского университета Карл Фукс, поселившись в Старо-Татарской слободе, заметил, что едва у казанского татарина заводились «наличных две, три сотни рублей», дабы «отличиться от небогатой братии», он приобретал самовар. «Всякий зажиточный татарин имеет свой самовар», – отметил он про татарских обывателей в своей книге «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» (1844), изданной университетской типографией и признанной первым научным трудом по татарской этнографии.

«Против двери, направо, стоит стол, покрытый пестрою бумажною скатертью; а на стол поставлено маленькое зеркало. Влево, к углу, также находится покрытый стол с чайными фарфоровыми чашками, с мисками и несколькими подносами. Около стен – несколько простых деревянных стульев; самовар всегда стоит у печи», – описывал ученый внутреннюю обстановку в посещенном им татарском мещанском доме. Самовар был гордостью хозяина, содержался всегда в чистоте, чтобы уберечь от пыли и окисления, его заботливо накрывали полотенцем и салфеткой, а некоторые – даже специально сшитым чехлом.

Побывал он и в домах богатых татарских купцов, обнаружив, что они «мало отличаются от домов русских дворян и купцов». Отличие заключалось во «множестве хорошего фарфору», включая «чайный прибор, расписанный яркими пестрыми красками». Самовары у тех и других красо-

вались на почётном месте в гостиной на комодах и на кухне. Причем они имели не по одному, а по два самовара, используя один как повседневный в домашней обстановке, а другой – как праздничный, для гостей, который можно было выносить летом в сад, жарким днем на прохладную речку, а также на пикники и праздники на природе. Как-то знакомые татары пригласили К.Ф. Фукса на свой народный праздник сабантуй, проводившийся в Казани на лугу «к югу от новой Татарской слободы». Здесь учёный попал на настоящее татарское чаепитие из самовара. О своем посещении татарского народного празднества он написал статью, опубликовав её в 1814 г. в первой казанской газете «Казанские известия». В мае 1829 г. Фукс вновь побывал на сабантуе, но на этот раз со своими гостями – направлявшимся в «азиатское путешествие» по Уралу и Сибири для изучения природных богатств по приглашению самого императора Николая I – немецким ученым, основоположником новой отрасли биологического знания – географии растений, Александром Гумбольдтом и сопровождавшими его минералогом Г. Розе, биологом Эренбергом и служителем Зейфертом. Не обошлось без татарского праздничного чая из самовара.



*Самовар и чайник, изготовленные в XVIII в. на Урале на заводе А.Ф. Турчанинова.*

С самоваром Гумбольдт успел познакомиться в Санкт-Петербурге. Здесь готовились к открытию первой публичной Всероссийской выставки российских «изделий мануфактурных, фабричных и заводских» с участием самоварных фабрик и мастеров. Ему, как поклоннику кофе, уже доводилось пользоваться самоваром-кофейником, небольшим приборчиком, с размещенными на основании спиртовкой или выдвижным металлическим ящичком для углей и металлическим миксером для кофе внутри резервуара. В отличие от русского самовара у него отсутствовала труба-жаровня. Знаком был ему и самовар-бульотка, куда наливали кипяток и поддерживали потом его температуру с помощью грелки-спиртовки. А в дорогу вместе с коллегами они взяли самовар-кухню из нескольких отсеков, в которых можно было приготовить еду и сохранить ее в горячем виде. На татарском сабантуе в Казани Гум-

больдта и его сопровождавших больше всего удивило количество самоваров, принесенных людьми с собой на праздник. Такого в Европе не встретишь! Невозможно было удержаться от похвал чаю, приготовленному с их помощью. Его вкус и аромат, а также татарские кушанья к нему запомнились им надолго.

В последний вечер в Казани немецких ученых ждало чаепитие у их коллеги и соплеменника К.Ф.Фукса, уроженца Герборна, питомца Герборнской академии и слушателя Геттингенского университета. Заваренным на европейский манер чаем их угощала в зале хозяйка – жена Фукса – Александра Андреевна, писательница и поэтесса, происходившая из старинного дворянского рода Апехтиных. Она разливала кипяток из начищенного до блеска самовара на металлическом подносе. Пили напиток, как и полагалось, из фарфоровой посуды. Такие чаепития чета Фуксов устраивала для участников заседаний их домашнего литературного салона, ставшего культурным центром для казанских литераторов и интеллектуалов. Александра Андреевна занимала на них место за большим столом за самоваром, по правую руку от нее садился в кресло ее муж К.Ф.Фукс. Из их семейного самовара угощался чаем в сентябре 1833 г. знаменитый поэт А.С.Пушкин. Он посетил Казань наездом, направляясь в Оренбург для сбора материалов по «Истории Пугачёвского бунта». В доме Фуксов на его глазах развернулась картинка, описанная им в романе в стихах «Евгений Онегин»:

Шипел вечерний самовар,
Китайский чайник нагревая,
Под ним клубился легкий пар.

Это произведение признают впоследствии энциклопедией русской жизни, а она уже не представлялась без самовара, о чем и поведал Пушкин. Но даже он не подозревал, что его поэтические высказывания о нём сделают его одним из первых певцов самоварного чаепития в русской литературе. И уже от него принял эстафету восхваления самовара в своем одноименном стихотворении П.А.Вяземский.

Конечно, Пушкин мог бы воздать должное и дорожному самовару, в частности, в предпринятых им стихотворных описаниях поездки своего героя по приволжским городам в «Путешествиях Онегина». Ведь тогдашние путешественники непременно брали с собой в дорогу этот чайный прибор необычной формы, в виде ящичка со срезанными углами и съемными ножками. Его укладывали в специальную шкатулку-погребец вместе с чайником, чайницей с чаем, графином с ромом, стаканами, молочником, полоскательной чашей, ситечком, щипцами для сахара и чайными ложками.

Дорожный самовар сопровождал в четырехмесячном путешествии по Поволжью и Уралу в 1833 г. и самого Пушкина. «Изобретение, без сомнения, полезное», – отзывался о нём связанный с поэтом дружбой граф Владимир Александрович Соллогуб, Осенью 1839 г. он вместе с художником Г.Г. Гагариным совершил поездку в Казань и по путевым впечатлениям написал повесть «Тарантас». Соллогуб не скрывал, что в этой дальней поездке во многом был обязан дорожному самовару. Лишь в гостинице Михайлова в Казани, где он поселился с Г.Г. Гагариным, столичный литератор решил воспользоваться предложенным здесь трактирным самоваром.

Такая услуга была принята тогда во всех на постоялых дворах, гостиницах и трактирах империи, и Казань не являлась исключением. Судя по изданному коллежским асессором И.С. Черновым «Указателю города Казани, или Памятной книжке для жителей Казанской губернии на 1841 г.», в те времена в ней имелись одиннадцать гостиниц для приезжих: Акчурина на Воскресенской улице, Потехина, Мельникова, Жарова на Проломной, Котелова на Проломной и Мокрой, Перлова на Мокрой, Корюкина на Владимирской, Матвеева на Новогоршечной, Месетникова на Егорьевской, Михайлова на Сенной площади. К ним относили также трактиры с харчевней, где можно было «пить и есть из платы». Их в городе насчитывалось 22. Из них выделялись как лучшие Щербакова, Мельникова и Потехина на Проломной улице, Апанаева на Малой Проломной, Гусева и Рюмина на Воскресенской, Боркова и Парунова на Рыбнорядской, Укусникова на Вознесенской, Корюкина, Котелова и Перлова на Мокрой, Коровина, Дехтярева и Рязанова на Егорьевской, Жадина на Сеной площади, Щербакова на Булаке.

Казань располагала также сотней постоялых дворов. Постояльцы таких заведений для «проезжающих» имели право потребовать самовар к себе в «нумера» или же на трактирный стол. В надежде, что среди них может оказаться человек, заинтересовавшийся «Указателем города Казани, или Памятной книжкой для жителей Казанской губернии», его составитель И.С. Чернов преминул дать ему дельный совет. «Подтвердите Вашим служителям, чтобы они содержали самовар в величайшей чистоте и не оставляли в нем воды от чаю до чаю, – если не хотите, чтоб чай отзывался нолудой, – наставлял он, – если подадут Вам самовар с недокипевшею или перекипевшею водою: в перовом случае чай Ваш будет мутен, а в последнем отзываться накипью полуды и иметь мыльный вкус».

Его справочная книга содержала множество других рекомендаций по покупке, хранению и правильному завариванию чая. Они были сделаны им на основе публикаций медицинских изданий, прежде всего вы-

ходящей с 1833 г. в Санкт-Петербурге под эгидой медицинского ведомства еженедельной народно-врачебной газеты «Друг здравия». Конечно, не обошелся казанский издатель без содействия профессоров – медиков университета, в частности врача К.Ф. Фукса. «Лучший способ приготовления чая доселе почитается следующий, – рассказывал И.С. Чернов про его заваривание, – кладут в чайник умеренное количество чая, немного всполаскивают оный, наливают кипятку не более четвёртой части чайника, и, закрыв крышечкой, дают постоять несколько минут, и потом уже доливают чайник; при чем ложечкой снимается пена, иногда показывающаяся на поверхности. Если же вдруг налить полный чайник, то чай из излишнего обилия кипятка вдруг, как говорят, заварится, потеряет много аромата, примет вяжущий вкус и не усладит Вашего вкуса и обоняния. Это истина! Испытайте сами!». Похоже, он сам был настоящим чаёвиком и решил раскрыть некоторые проверенные секреты: «Вот еще до какой тонкости дошли любители хорошего чаю: они уверились опытом, что вкус и запах чая весьма много изменяется в нежности, когда настой будет пропущен чрез металлическое ситечко или помешан металлической ложечкой; и потому-то истинные знатоки, в случае необходимости, употребляют для этого хрустальные, фарфоровые, или даже костяные ложечки. Всякое дело мастера боится!». Чернов предлагал обратить особое внимание при заваривании чая воде. «Вода имеет большое влияние на достоинство приготовляемого чая, – делился он собственным опытом. – Мягкая речная, в которой совершенно распускается мыло и варится горох, есть лучшая; колодезная, или в которой растворено много известковых частиц, как например: Казанская – не годится. В Казани лучшая для чаю вода из ключа, вытекающего из-под горы в Немецкой Швейцарии, Волжская и Кабанная, пока эта последняя не цветет; в это же время должно употреблять растаявший кабанный, или волжский лед».

Немецкая Швейцария входила вместе с соседствующей Русской Швейцарией в единый лесной массив на протянувшемся по левому берегу Казанки нагорье. Отсюда некогда начинались дремучие Арские леса. Холмистое живописное место с крутыми обрывами и глубокими ущелистыми оврагами напомнило первой немецкой профессуре открывшегося в 1804 г. Императорского Казанского университета знакомую им Швейцарию. С легкой руки одного из них – Ксаверия Броннера – необычное название закрепилось за рощей, а потом и местностью, где состоятельные горожане принялись строить дачи и разводить сады.

По их просьбе профессор Людвиг Фогель предпринял поиск в округе источника с целебной и минеральной водой. Он обнаружил его в соседней роще и поставил здесь свой загородный дом. За ним обосновалось

гласно которому Совнарком осуществлял общее управление республикой. Полномочия его определялись следующим образом:

1. Руководство деятельностью наркомтатов, исполкомов местных Советов рабочих, крестьянских и красноармейских депутатов.

2. Рассмотрение республиканского плана развития народного хозяйства, внесение плана на утверждение ЦИК ТАССР и его Президиума.

3. Предварительное обсуждение республиканского и местного бюджета, отчёт об их исполнении.

4. Распределение денежных средств между отдельными территориальными единицами и ведомствами.

5. Подготовка заключения о размерах отчислений на нужды республики от поступлений по государственным налогам и доходам.

6. Контроль деятельности всех находившихся на территории республики предприятий и организаций союзного и российского подчинения (за исключением учреждений действующей армии).

Издаваемые Совнаркомом декреты и постановления были обязательны к исполнению на всей территории Татарской республики. Но и ЦИК, и его президиум также исполняли некоторые управленческие функции. Отсутствие чёткого разграничения полномочий приводило к дублированию в деятельности ЦИКа и Совнаркома [Правовые и исторические аспекты становления и развития Правительства Республики Татарстан: 2021].

В декабре 1926 г. Хаджи Габидуллин выступил на заседании Совнаркома РСФСР с докладом об экономическом положении и хозяйственном строительстве в Татарской республике. Правительство РСФСР приняло по этому докладу развёрнутое решение, предусмотрев строительство на территории Татарии ряда промышленных предприятий и оказание республике необходимой финансовой помощи.

15–21 марта 1927 г. прошёл VII съезд Советов ТАССР. В его резолюции снова говорится о преодолении последствий засухи. Важное значение придаётся развитию птицеводства, пчеловодства и молочного скотоводства. Озвучено, что необходимо изучить причины убыточности Кожтреста и принять меры к их устранению. В резолюции по докладу наркома просвещения М.Х. Тагирова говорится о необходимости ввести всеобщее начальное обучение; строить новые школы; готовить новые педагогические кадры и повышать квалификацию работающих учителей; улучшать работу дошкольных, профессиональных и высших учебных заведений. Шла речь и об ускорении работы по отливке принятого татарского алфавита, а также об издании полного татарского словаря [Центральные органы государственной власти и управления Татарстана (1920–2020 гг.): 2017. С. 66.].

Хаджи Габидуллин переехал на работу в Москву в октябре 1927 г. по решению ЦК партии. В годы своей работы в Казани на разных постах он избирался членом Казанского горсовета и ЦИК Татарской АССР, в 1925–1929 гг. являлся членом ВЦИК, кандидатом в члены Президиума ВЦИК и членом ЦИК СССР, в 1925 г. был делегатом XIV съезда партии. Но этот видный государственный деятель своего времени не избежал участи многих и многих – в 1937 г. 40-летний Габидуллин был расстрелян из-за чудовищно несправедливого обвинения [Габидуллин: лояльность к центру не спасла его от расстрела: 2021].

## Список литературы


1. ГА РТ, Ф. П-30, Оп. 3, Д. 2037.
2. ГА РТ, Ф. П-30, Оп. 3, Д. 2037.
3. ГА РТ, Ф. П-30, Оп. 3, Д. 2037.
4. Два года в аду (К 100-летию образования Татарской АССР). – URL: 100tatarstan.ru/structure/profile/dva-goda-v-adu-29451771 (дата обращения: 18.06.2021).
5. История татар с древнейших времён: в 7 т. / Академия наук РТ, Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ. – Т. VII: Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013.
6. Правовые и исторические аспекты становления и развития Правительства Республики Татарстан. – URL: https://prav.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2415235.pdf (дата обращения: 18.06.2021).
7. Правовые и исторические аспекты становления и развития Правительства Республики Татарстан. – URL: https://prav.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2415235.pdf (дата обращения: 18.06.2021).
8. Хаджи Габидуллин: «В уклонах не замечен. Ошибки признает». – URL: business-gazeta.ru/article/359263 (дата обращения: 18.06.2021).
9. Хаджи Габидуллин: лояльность к центру не спасла его от расстрела. – URL: business-gazeta.ru/article/360707 (дата обращения: 18.06.2021).
10. Центральные органы государственной власти и управления Татарстана(1920–2020 гг.): научно-справочное издание, – Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2017.
11. ЦК РКП(б) – ВКП(б) и национальный вопрос. Кн. 1. 1918–1933 гг. – М.: РОССПЭН, 2005.

*Солтан Шәмси*

# РИМНЕ ТӨЗЕГӘН ЭТРУСКЛАР
(*фәнни-популяр тарихи бәян*)

***Аннотация.*** *Күп гасырлар дәвамында галимнәр Италиядә беренче югары үсешкә ирешкән цивилизация төзегән этруск халкының серен ачарга тырышалар. Ни өчен бу халык даими галимнәрнең игътибар үзәгендә соң? Сәбәбе шунда – матди һәм рухи яктан зур казанышларга ирешкән этрусклар Римнең остазлары булганнар. Анда этруск патшалары хөкем сөргән дәвердә фәкать алар тырышлыгы белән Рим шәһәре төзелгән, матур калага әверелгән. Этрусклар, үз казанышларына таянып, римлыларга кала да, шактый камил структуралы дәүләт тә төзеп биргәннәр.*

*Этруск халкы нинди телдә сөйләшкән? Европа галимнәре инде күптән этруск теленең серенә төшенергә тырышалар. Әмма һинд-европа телләре ярдәмендә этруск телен аңларга тырышу тиешле нәтиҗә бирми. Бу ачкыч яраклы түгел. Ачкычны татар галимнәре тапты. Аның серен бары тик төрки телгә таянып кына ачып була икән. Иң әүвәл этруск телендә шактый калын төрки сүзләр катламы булуы турында Төркиядә яшәгән Адилә Айда (Садри Максуди кызы) үз хезмәтләрендә язып чыкты. Язучы Н. Фәттах та бу мөһим эшкә үз өлешен кертте. Бүгенге көндә татар галимнәре һәм энтузиастлары Ф.Р. Латыйпов, Н.Н. Хөсәенов, Н.И. Сәхапов һәм башкалар этруск теленең борынгылыгын, гадәти төрки телдән күпмедер дәрәҗәдә тайпылган булса да, төрки нигезен кире кагып булмаслык дәлилләр белән исбатлауны дәвам итәләр.*

*Фәнни-популяр әдәбият жанрында язылган хезмәтебез этрускларның килеп чыгышын, тарихын, теленең ниндилеген, мәдәниятен, мифологиясен, дини карашларын яктыртуга багышлана. Анда шулай ук Италия җирлегендә беренче гүзәл цивилизация төзегән бу халыкның, көчәеп киткән Рим басымы йогынтысында ассимиляциягә дучар булып, акрынлап йотыла баруы, туган телен, мөстәкыйльлеген югалтуының сәбәпләре дә ачып салына.*

Ни өчен галимнәр үҗәтләнеп этрусклар белән шөгыльләнә соң? Җир шарында килеп чыгышы, тарихы, теле, мәдәнияте сер булып калган халыклар алар гына түгел бит. Ә игътибар үзәгендә һаман этрусклар. Моның сәбәбе нәрсәдә соң, ни өчен Яңарыш чорыннан башланып киткән бу кызыксыну һаман сүрелмичә дәвам итә?

Эш шунда ки, этрусклар зур матди һәм мәдәни казанышларга ирешеп, көчле шәһәр-дәүләтләр конфедерациясе төзеп, соңрак чорда ярты дөнья-

ны яулап алган Рим империясенең тәүге остазлары булганнар. Римнең бишегендә этрусклар торган. Римлылар бик күп казанышларын Италиянең уртасында унике мөстәкыйль шәһәр-дәүләтләр төзегән ут күршеләре этрусклар цивилизациясеннән үзләштергәннәр. Этрускларны үзләренең остазлары дип таныганнар. Моннан ике мең еллар элек этруск кызына өйләнгән Рим императоры Клавдий (41–54 елларда идарә иткән) хәтта этрусклар тарихына багышланган 20 томлы хезмәт тә язган булган. Кызганычка, император Клавдий язган хезмәт борынгы заманда иң бай китапханәләрдән саналган Александрия шәһәре китапханәсе янганда һәлак булган. Галимнәр шул янгын вакытында антик дөнья авторларының этрусклар турындагы башка хезмәтләре дә юкка чыккан, дип язалар.

Тарихка «мәңгелек шәһәр» дигән исеме белән кереп калган Рим Тибр елгасының сул як ярында урнашкан. Элек бу елганың атамасы Рума булган дигән мәгълүматлар да бар. Кайбер галимнәр «Рума» атамасын этруск сүзе дип саныйлар. Рим шәһәренә нигезне дә этрусклар йоласы буенча салганнар һәм аны этрусклар төзи башлаган. Рим дәүләтенең беренче патшалары да этрускларның Таркна ыруыннан булган. Соңрак бу ыруның исеме римләшкән һәм Тарквинигә әйләнгән. Бу ыру вәкилләре төзегән шәһәр дә Тарквини шәһәре дип аталган. Рим тарихчысы Тит Ливий (б.э.к. 59 – б.э.17 елларында яши) Рим тарихы турында зур хезмәт язып калдырган. Ул анда Римнең беренче патшалары этрусклардан булуын турыдан-туры яза: «Патшалар Римгә нигез салынганнан алып аның азат ителүенә хәтле 244 ел буе идарә итәләр», – ди. Рим халкы ахыр чиктә этрусклар ыруыннан булган патшаларның шәһәрдә хуҗа булып утыруына каршы чыга, баш күтәрә һәм Тарквиниларны Этруриягә куып җибәрүгә ирешә. Икенче урында Тит Ливий: «Барысы да бер фикергә килде – Тарквинилар ыруыннан арыну гына патшалардан котылуга китерәчәк», – дип яза. Кыскасы, вакыт үтү белән көч туплый барган Рим халкы этруск патшаларын тәхеттән төшерә, тик этрускларның бер өлеше шәһәрдә яшәп кала. Соңгы патша Горур Тарквини Этруриягә куып җибәрелгәннән соң шәһәрдә республика хакимияте урнаша. Бу хәл б. э. к. 509 елда була. Шулай патшалар хакимияте бетерелә һәм идарә итү ике преторга – Брут белән Коллатинга тапшырыла. Соңрак преторлар урынына консуллар идарә итә башлый. Алар бер елга гына сайлап куела.

Мәдәни һәм матди яктан шактый түбән дәрәҗәдә торган римлылар этрусклардан нинди казанышлар, һөнәрләр, йолалар кабул иткән соң? Беренче чиратта этрускларның калалар төзү осталыгына игътибар итик. Археологлар җимерелеп, әрәм-шәрәм булып бетмәгән этруск шәһәрләрен казып тикшерү бәхетенә ирешәләр. Бу халык калаларын күп очракта калкулык өсләренә төзегән икән. Гыйбадәтханәләр дә калкулык өсләренә са-

лынган, аннан астарак, баскыч-баскыч булып, торак йортлар урнашкан. Калаларда су торбалары үткәрелгән. Бу гадәт тора-бара этрусклардан римлыларга да күчкән. Юкка гына Рим «җиде калкулык өстенә салынган» дип сөйләнми торгандыр. Анда да тора-бара калкулыклар өстендә гыйбадәтханәләр, храмнар барлыкка килгән.

Әүвәл этрусклар түгәрәк өйләр сала торган булганнар, түбәсен салам белән япканнар. Соңрак йортларны турыпочмаклы итеп тә төзи башлаганнар. Иң зур бүлмәнең уртасында һәрвакыт учак янган. Төтен түшәмдәге тишектән чыккан. Бу төрки халыкларның тирмәсен хәтерләтә. Шунысы игътибарга лаек, соңрак римлыларда барлыкка килгән аксөякләр, югары катлам кешеләре, дәрәҗәле хәрбиләр зур һәм затлы йортларда яшәсәләр дә, йортның иң зур бүлмәсе өстен ачык калдыра торган булганнар. Бу бүлмә «атрий» дип аталган һәм аның уртасында һәрвакыт учак янган. Бу гадәтне дә римлылар этрусклардан алганнар. «Атрий» этруск сүзе булырга тиеш. Аны этрусклар тарихы, теле, мәдәнияте белән күп еллар шөгыльләнгән Адилә Айда (Садри Максуди кызы) түбәндәгечә аңлата: «атриум» (атр-иум), биредә иум – латин теле кушымчасы, атр = ата-йер, ягъни «аталар җире» дигән мәгънәгә ия. Өстәп шуны да әйтик: күрәсең, учак янган җылы бүлмәдә хөрмәтле аталар утыра торган булгандыр.

Этрусклар бик дини халык булган. Алар колонналар белән бизәлгән зур гыйбадәтханәләр төзегәннәр, аның фронтонын төрле сыннар, скульптуралар белән бизәгәннәр. Храмнар төзергә дә римлылар этрусклардан өйрәнгәннәр. Аларның храмнарын нигездә этруск осталары төзегән.

Рим шәһәре урнашкан җиде калкулыкның берсе Капитолий калкулыгы дип атала. Бу калкулык Римнең үзәген тәшкил иткән, анда Римнең мәңгелеген, кодрәтен чагылдыручы мәшһүр Капитолий храмы төзелгән. Ул Римнең соңгы патшасы этруск Горур Тарквини заманында барлыкка килгән. Капитолий храмы үзенең архитектурасы белән этрусклар гыйбадәтханәләрен хәтерләтә икән. Римлыларның горурлыгы булган Капитолий храмы фронтонындагы ике тәгәрмәчле арбага җигелгән канатлы дүрт атлар сыны – квадрига да этруск сынчысы Вулка тарафыннан эшләнгән. Храм римлыларның өч төп алласы – Юпитер, Юнона һәм Минервага багышлап корылган, анда аллаларның сыннары урнаштырылган. Моннан тыш биредә Римнең символын тәшкил итүче бронзадан коелган Капитолий бүресе сыны да куелган. Имчәкләре сөт белән тулып кабарынган ана бүрене ике сабый – Рем белән Ромул имеп утыра. Борынгы риваять ана бүре имезеп үстергән Рем белән Ромул Рим шәһәренә нигез салган дип бәян итә. Әмма бу риваять тарихи дөреслеккә туры килми. Ул соңыннан гына уйлап чыгарылган. Бронза бүре сыны әүвәл Этруриядә коела. Бүре этрусклар һәм аларның төрки күршеләре саба халкының

тотемы – ыру башы саналган. Ул вакытта ана бүре корсак астында сөт имеп утыручы сабыйлар әле ясалмаган була. Соңрак Рим көч туплый, ә этрускларның шәһәр-дәүләтләре конфедерациясе көчсезләнә төшкәч, римлеләр ана бүре сынын Римнең Капитолий храмына алып кайтып урнаштыралар. Бу этрусклар һәм саба халкының Рим белән берләшүен чагылдыручы сәяси акция була. Көчәеп киткән Рим моны идеологик максатларны күздә тотып башкара. Соңрак кына, риваятькә тәңгәл килсен дип, этрусклар бүресе корсак астына ике сабыйны – бронзадан коелган Рем белән Ромулны утыртып куялар. Римнең башлангыч тарихы шулай матур риваятькә төрелә, гәрчә римлыларда бүрене ыру башы (тотем) дип санау булмаса да.

Рим шәһәре барлыкка килгән җиде калкулыкта элек авыллар яшәгән. Борынгы Рим ул заманда әле шәһәр булмаган. Андагы авылларны берләштереп, шәһәр төзү өчен иң элек пычрак сазлык, баткаклыктан арыну максаты торган. Үзәннең ямен алып, шәһәр төзергә комачаулаган бу сазлык римлыларның тәмам үзәгенә үткән. Ул бер үк вакытта бизгәк авыруы чыганагы да булган. Рим халкы аны үз телендә «клоака максима» – «бинһая пычраклык» дип атаган. Ниһаять, этрусклардан чыккан Рим патшасы Тарквини Приск заманында бу мәсьәләне хәл итәргә тотынганнар. Җыелган пычрак суларны агызып җибәрү өчен каналлар системасы төзелгән. Җир астында калдырылган су үткәрү каналларының кайберләре шундый нык булган ки, «аннан печән төялгән арба да үтә алган булыр иде», – дип яза Рим язучысы Өлкән Плиний (б.э. 23–79 елларында яшәгән). Каналлар төзелгәннән соң этрусклар Палатин белән Капитолий калкулыклары арасындагы сазлыкны киптерүгә керешкәннәр. Анда балчык ташып, аны түшәп Форум мәйданы ясаганнар, бирелә халык җыеннары үткәрелгән, хөкем карарлары чыгарылган, базарлар оештырылган. Шулай этруск патшалары җитәкчелегендә калкулык өсләрендә урнашкан авылларга үзара берләшү мөмкинлеге туган, Рим шәһәре барлыкка килгән.

Икенче бер урында Өлкән Плиний рухланып һәм гаҗәпләнеп тагын «бинһая пычраклык»ны телгә ала: «Кайвакытта Тибр (елгасы) суларын кире таба куа һәм андый чакта ике агым каналлар эчендә капма-каршы очраша. Әмма шуңа да карамастан нык итеп төзелгән корылма су басымына бирешми. Аның өстеннән авыр йөк төялгән арбалар да уза, ләкин түшәме түгәрәкләнеп эшләнгән корылма зыян күрми; аның өстенә кайвакыт искереп җимерелгән йортлар да авып төшкәли, тик Тарквини Приск заманыннан бирле җиде йөз ел үтүгә карамастан ул һаман бирешми, гүя мәңгелек итеп корылган», – дип яза. Борынгы Римдә төзелгән әлеге каналлар бүгенге көндә дә Италия башкаласындагы канализа-

ция системасының бер өлеше булып кала бирә икән. Бу хәл этрускларда гидротехниканың, сазлыкларны киптерү технологиясенең бик югары дәрәҗәдә торуы турында сөйли.

Этрускларның Римгә ясаган йогынтысы архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә үзен аеруча нык сиздерә. Этруск патшалары династиясе Тарквиниләр Римдә хөкем сөргәндә бу шәһәр нык диварлар белән уратып алына. Шулай Рим Италия шәһәрләре арасында абруйлы урын ала. Этрусклар тарафыннан Римдә башкарылган күп эшләр соңрак римлеләр тарафыннан «бөек» дип билгеләнә. Тарквиниләр заманында Авентин һәм Палатин калкулыклары арасындагы үзәндә этрусклар тарафыннан төзелгән цирк та «бөек корылма» исеменә лаек була. Ул алтмыш мең кешене сыйдырган.

XVIII гасырда яшәгән итальян архитекторы Джованни Баттиста Піранези этрускларның Урта гасырлар архитектурасында киң урын алган «роман стиле» барлыкка килүгә сәбәпче булуларын билгеләп үтә. Чыннан да, «роман стиле» чиркәүләр, монастырьлар һәм башка биналар төзү өлкәсендә бик зур роль уйнаган. Этрусклар тарихы, мәдәнияте белән таныш булмаган кешеләр бу стиль Рим империясе йогынтысы аша киң таралыш алган дип уйларга мөмкин, әмма аның башлангычы этрусклар төзегән архитектура үрнәкләренә килеп тоташа икән.

Шәһәрләр төзү сәнгатен генә түгел, идарә итү системасын да римлылар этрусклардан алганнар. Әйтик, төрле тантаналар вакытында кулланылган бизәү алымнары, шулай ук Этрурия шәһәрләре патшалары лукумоннар, консуллар, башка рәсми затларның кием-салымнарындагы бизәкләр, кулларындагы төрле хакимият билгеләре – барысы да Римгә Этруриянең иң абруйлы шәһәре Тарквинидән (Таркна) китерелгән, чөнки Рим патшалары шушы шәһәрдән чыккан. Шулай ук римлыларның тантаналар вакытында кырыйлары пурпур (ачык кызыл төс) тукыма белән каймаланган атаклы тогасы, фил сөягеннән ясалган креслолар, дини йолалар, сугыш вакытында, бәйрәмнәрдә кычкырта торган махсус боргылар һәм тагын бик күп нәрсәләр этрусклар шәһәр-дәүләтләрендә, тормыш-көнкүрешендә кулланылган әйберләр булган. Һәм без римлыларныкы дип уйлаган күп нәрсәләр, ачыклый башласаң, этрускларга барып тоташа икән.

«Этрускларның рәсем сәнгате – Италиядә барлыкка килгән иң әүвәлге рәсем сәнгатенә барып тоташа. Ул мәгълүм бер мәгънәдә антик чор рәсем сәнгатен аңларга ярдәм итүче уникаль чыганак. Этрускларның мәһабәт һәм зиннәтле тумули-төрбәләрен бизәгән фрескалар, терракотага ясалган сурәтләр Италиядә биш-алты гасыр буе үскән рәсем сәнгатен өйрәнергә ярдәм итә. Этрускларның мәетләр өчен төзелгән иң бай тумули-төрбәләре чын мәгънәсендә картиналар галереясен хәтерләтә.

Римлыларның б.э.к. II–I гасырларга караган рәсем сәнгате этрускларның бай иҗади тардицияләренә нигезләнеп үскән. Этрускларның бу өлкәдәге йогынтысын бәяләп җиткермәвебез аларның өй һәм гыйбадәтханәләрне ничек бизәвен белмәвебез белән аңлатыла. Без бит бары тик этрускларның тумули-төрбәләрендәге фрескаларны күреп кенә фикер йөртәбез».

Бронзадан сыннар, бюстлар ясауга да римлылар этрусклардан өйрәнгәннәр. Капитолий храмы бүресенең этруск осталары тарафыннан коелганын әйтеп үткән идек.

«Этрускларның һәм соңрак римлыларның да «атрий» дип аталган учак яна торган бүлмәләрендә вафат булган туганнарының балавыз битлекләре саклана торган шкафлары булган. Мәет күмү мәрасимендә бу битлекләрдән файдаланганнар. Моның өчен килеш-килбәте һәм буе мәрхүмгә охшаган берничә кеше шушы битлекләрне кигән <...> Балавыз битлекләрнең бронза сыннар һәм бюстлар койганда файдаланылуы шик уятмый». Соңрак римлылар да, этрусклардан күреп, скульптур портретлар ясаганда балавыз битлекләрдән файдалана башлаганнар.

Этрусклар римлыларга шәһәр төзүдә, архитектурада, сынлы сәнгать һәм сәнгатьнең башка төрләре буенча йогынты ясау белән генә чикләнмиләр, римлылар шулай ук фән өлкәсендә дә бу халыктан үрнәк алалар. Бай римлылар балаларын Этрургия шәһәрләренә «этруск дисциплиналарын» үзләштерергә озата торган булганнар. Дөресен генә әйткәндә, ул заманда фән дигән нәрсә әле төрле ышануларга, дини карашларга, йолаларга бәйле булган. Әйтик, этрускларда киң таралган гаруспикция, ягъни хайваннарның эчке әгъзаларына карап, кешенең язмышы турында күрәзәлек кылу, берәр ситуациядә нинди карар кабул итү һәм башка шундый гамәлләргә кайтып калган. Күрәзәче-гаруспиклар нигездә хайванның бавырын, үпкәләрен тикшерү белән шөгыльләнгәннәр, шуңа карап нәтиҗә чыгарганнар. Адилә Айда «гаруспик» сүзен «һаруспекс» (һару-спекс) дип аңлата һәм сүзнең беренче өлеше төркичә «карын» (эч) сүзенә барып тоташа, дип фаразлый.

Этрускларның гаруспиклары Борынгы Рим тормышында гаять зур роль уйнаган. Әүвәл бу эш белән этрусклар гына шөгыльләнгән, соңрак римлылар да күрәзәлек итә башлаганнар. Гаруспиклар оешмасының (коллегиясе) үзәге Тарквини (Таркна) шәһәрендә урнашкан булган. Төрле мәсьәләләр буенча фикер ишетү өчен гаруспикларга аерым кешеләр генә килмәгән, дәүләт мәсьәләләре буенча да аларга мөрәҗәгать иткәннәр. Гаруспиклар сүзенә ышану гаять көчле булган. Христиан дине барлыкка килгәч, гаруспикларны кысу башланган, аларга храмнар алтарьларында корбан чалу тыелган. Әмма моңа карап кына гаруспиклар һәм аларның

шәкертләре бу эштән баш тартмаганнар. Безнең эраның IV гасырында Рим императоры Константин христиан динен дәүләт дине дип игълан итә. Шуннан соң күрәзәлек белән шөгыльләнүчеләрне үлем җәзасына тарту турында фәрман чыгарыла.

Этрусклар хәрби өлкәдә дә төшеп калган халык булмаган. Бу хакта этрусколог А.М. Кондратов: «Римлылар үзләре сугыш алып бару өлкәсендә бик күп нәрсәгә этрусклардан өйрәнүләрен таныганнар. Кораблар төзү һәм аларны йөртү ысулларына да «коры җирдә яшәүче» римлылар этрусклардан өйрәнгән. Этрусклар ул заманда Урта диңгездәге иң оста диңгезчеләрдән саналган, греклар белән карфагенлыларның көндәше булганнар», – дип яза.

Нинди халык булган соң этрусклар? Алар кайдан килеп чыккан, ничек Италиянең уртасында унике шәһәр-дәүләтләр конфедерациясе төзеп, һәр өлкәдә зур уңышларга ирешкәннәр, югары үсешкә ирешкән үз цивилизацияләрен төзегәннәр?

### Этрускларның килеп чыгышы

Бу халыкның килеп чыгышы турында фәндә төрле фикерләр яши. Шуларның берсен «тарих атасы» исеме алган борынгы грек тарихчысы Геродот язып калдырган. Аның сүзләренчә, этрусклар әүвәл Кече Азиядәге Лидия патшалыгында яшәгәннәр. (Хәзерге Төркия территориясе). Ул чакта алар «лидлар» дип аталганнар, чөнки лидларның беренче бабасы Лид атлы булган. Моннан тыш Лидның Кар һәм Мис исемле туганнары да телгә алына. Кече Азиянең көньяк-көнбатышында борынгы заманнарда Кария һәм Мисия дип аталган дәүләтләр булуын искә төшерсәк, бу дәүләтләргә нигез салучылар Кар белән Мис булмады микән дигән сорау да туа. Әмма әлегә Кар белән Мис легендар исемнәр булып кала. Тарихчы Геродот лидлар, карлар һәм мислар бу җирләргә диңгез утрауларыннан күченгәннәр, дип яза.

Лидларның (ул вакытта алар әле этрусклар дип аталмый) Кече Азиядән күчеп китүләрен Геродот болай аңлата: «Лидиядә Манәй улы Атис патшалык иткәндә унсигез елга сузылган ачлык була, халык ашарга җитмәүдән бик нык интегә. Баштарак лидлар бу хәлгә түзеп яшиләр, тик ачлык дәвам итә.(...) Ачлыктан котылу чарасы һич табылмый. Бу хәлне күреп, Атис патша халыкны ике өлешкә бүлә дә, җирәбә салганнан соң, аның бер өлешен үз янында калдырырга карар кыла, ә икенче өлеше күчеп китәргә тиеш була. Туган җирдән китәчәк халыкның патшасы итеп улы Тирренны билгели.

Күчеп китүчеләр үзләренә кораблар төзиләр, аңа кирәк-яракны төйиләр дә яңа җир эзләп ачык диңгезгә чыгып китәләр. Күп халыклар яшәгән җирләрне узып, алар берзаман Италиягә, умбрлар дип аталган халык

яшәгән җиргә килеп чыгалар. Анда алар тора-бара калалар төзиләр. Инде алар элекке кебек лидлар дип аталмыйлар, үзләренә аларны яңа җиргә алып килгән патша улы Тиррен исемен алалар һәм тирреннар булып китәләр», – дип яза Геродот.

Тирреннар исемен кабул иткән бу халык Италиянең урта бер җирендәге зур өлкәгә килеп урнаша. Моңарчы анда умбр кабиләләре яши. Күчеп килүчеләр белән җирле умбрлар арасында бәрелешләр булу-булмавы хакында хәбәрләр юк. Шулай да җирле умбрлар килмешәк тирреннарны колач җәеп каршы алмаганнардыр. Ни генә булмасын тирреннар анда урнашып кала. Күрәсең, умбрларга Апеннин тауларына таба бераз чигенергә дә туры килгәндер. Тирреннар килеп урнашкан өлкә хәзерге көндә Тоскана өлкәсе дип атала.

Геродот без югарыда телгә алган Кече Азиядәге Кария дәүләтенең башкаласы Галикарнас шәһәрендә туа. Соңрак ул сәяхәтләре вакытында Италиядә дә була. Б.э.к. VIII гасырда тирреннардан этрускларга әверелгән халык турындагы хикәятне Геродот йә Кече Азиядәге сәяхәтләре вакытында, йә Италиядә яшәгәндә ишеткән булса кирәк.

Әмма Геродот язганнар белән килешмәүчеләр дә бар. Әйтик, шулай ук б.э.к. V гасырда яшәгән, Эгей диңгезенең Лесбос утравында туган грек тарихчысы Гелланик (485–400 елларда яши) этрускларның килеп чыгышы турында капма-каршы фикердә торган. Аның фикеренчә, Борынгы Эллада (Греция) җирләрендә кайчандыр бик борынгы халык пеласклар яшәгән. Греклар басып кергәннән соң пеласклар Элладаны ташлап китәргә мәҗбүр булганнар. Пеласк атлы патшалары җитәкчелегендә алар Италиягә ук барып чыгалар һәм яңа урында үзләренә яңа исем алалар. Шулай алар үз илләрен Тирсения, яисә Тиррения дип атый башлаганнар, имеш. Геродот та хезмәтләренең бер урынында: «Эллада элекке заманда Пеласгия исемен йөрткән», – дип язган.

Гелланик Лесбослы ничек пеласкларның тирреннарга әверелеп китүен «Фавонида» дип аталган хезмәтендә тагын да ачыграк язган: «Тирреннар әүвәл пеласклар дип аталганнар,» – ди.

Гелланик Лесбослы, әйткәнебезчә, б.э.к. V гасырда яшәгән һәм аның язганнары пеласклар-тирреннар турында соңрак гасырларда язган грек авторлары мәгълүматларына караганда ышанычлырак дип уйларга кирәк. Шулай итеп, Гелланик Лесбослы пеласклар белән тирреннарны бер үк кавем дип исәпли. Бәлки алар тугандаш халыклар булгандыр, шуңа Италиягә күчеп килеп, тора-бара үзара кушылып киткәннәрдер. Галимнәр пеласкларның теле һинд-аурупа телләре төркеменә кермәве турында да язалар. Димәк, һинд-аурупа телле халык саналган греклар өчен бу җирләрдә борын-борыннан яшәп килгән пеласклар бөтенләй ят халык бул-

ган, шуңа күрә аларны туган җирләреннән (Борынгы Пеласгиядән) кысрыклап чыгарганнар, дип уйларга нигез бар.

Аннан соң Гелланик Лесбослының югарыда китерелгән хәбәрендә төрки исемнәрне хәтерләткәннәре дә игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, Пеласкның хатыны Менишпа татардагы ирләр исеме Мөнипне хәтерләтә. Шулай ук Пеней да Пинәй булырга мөмкин. Аминтор исә «имин» һәм «тор» сүзләреннән ясалган исем Иминторны барлыкка китерә. Тагын өзектә «Нан» атлы соңгы патша исеме китерелә. Татарда «наный», «наныем» сүзләре бар. Сүзнең тамыры «нан». Ул кеше исеме булырга да мөмкин. Бәлки, Борынгы Греция территориясендә чыннан да грекларга хәтле төрки кавемнәр яшәгәндер. Соңгы вакытта фәндә Аурупа территориясендә һәм Урта диңгез буйларында арийларга хәтле төркиләр яшәве турында дәлилле сүзләр ишетелә башлады.

Иберияда (хәзерге Испания) борынгы заманда яшәгән иберларның төркиләр булуы турында да язалар. Грек телендә төрки сүзләрнең байтак булуы да шул хакта сөйли кебек. Ике генә мисал китерәм: грекларның «агора» сүзе халык җыеннары уздырылган мәйданны аңлата. Шул җыеннарда тавыш бирү тәртибе белән идарәчеләр сайлап куелган. «Агора» – төркичә «акыра» сүзеннән барлыкка килгән булса кирәк. Күрәсең, ул заманда «акыру»ның тупас мәгънәсе булмаган, ул бары тик кычкырып тавыш бирүне генә аңлаткандыр. Шулай «акыру»дан «агора» хасил булган. Икенче мисал: мәшһүр грек шагыйре Гомерның «Одиссея» әсәрендә феак халкының 12 изге басилейны сайлап куюы телгә алына. Һәр басилей кабилә башында торган, ул бер үк вакытта рухи остаз да булган. Без борынгы грек телендәге «басилей» сүзен төркиләрдән кергән дип уйлыйбыз. Сүз «бас» һәм «ил» иҗекләренә бүленә. Хәзер татарда президентны «илбашы» дип атау гадәткә кереп китте. «Басилей» дә шул ук мәгънәне аңлаткан булырга тиеш: «башиле» – «илбашы».

1885 елда француз археологлары Ж. Кузен һәм Ф. Дюрбах Эгей диңгезендәге Лемнос утравында таш стела (тораташ) табалар, анда кулына сөңге тоткан сугышчы һәм ике текст язылган була. Археологлар өчен бу бик кыйммәтле табылдык булып чыга. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Лемнос утравы Эгей диңгезенең төньяк читендә урнашкан, ул Гомерның «Илиада» әсәрендә тасвирланган Троя каласы каршында тора. Троя каласы ул дәвердә Троада ярымутравындагы дәүләтнең башкаласы булган. Лемнос утравында табылган ике текст матбугатта басылып чыкканнан соң этрускларны өйрәнүче галимнәр арасында байтак елларга сузылган бәхәсләр башланып китә. Һәркем таш тактага язылган текстны үзенчә укып, аны иң дөресе дип якларга тырыша. Ялгышлар бик күп була, галимнәр бер-берсе белән килешмичә, язуларны укуда үз вариантларын

тәкъдим итәләр. Тора-бара күп нәрсәләр ачыклана. Лемнос утравында табылган язуларның тиррен халкы язуларына бик якын торуы ачыла. Мәсәлән, немец филологы П. Кречмер Лемнос язуларының этруск язуларына бик якын торуын һәм алар арасында бары тик диалектлар аермасы гына күзәтелүен әйтә. Лемнос язуларын аңлау мәсьәләсендә В. Бранденштейн исемле галим иң зур эш башкара. Ул Лемнос һәм этруск телләрен якынлаштыручы берничә пунктны билгеләп үтә: беренчедән, ике телнең дә фонетик яктан бик охшаш булуын; икенчедән, суффиксларның үзара тәңгәллеген һәм аларның сүз ясалышындагы роленә һ.б. үзенчәлекләргә игътибар итә. А.И. Немировский шушы һәм башка тикшеренүләргә нәтиҗә ясап: «Этруск һәм Лемнос язуларындагы аермалар бары тик тиррен телендә сөйләшүчеләр көнчыгыштан көнбатышка таба хәрәкәт иткән очракта гына барлыкка килә алган һәм бу күченеш, башка телләр белән очрашу-кушылу кебек үк, шактый озак дәверләргә сузылган. Шул сәбәпле Лемнос теле ядкярләре кебек этруск теленә якын торган башка бер язуны табу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә», – дип яза. Галим бу очракта пеласк телен Лемнос теле дип атый.

Лидия патшалыгында яшәгән тирреннарның (ул вакытта алар әле лидлар дип аталган) Көнбатыш Анатолиядән кояш баешына таба күченеп китүен исбатлаучы фактлар бардыр? Әйе, сакланып калган топонимнар шул хакта сөйли икән. Мәсәлән, Лидиядә кайчандыр Торра шәһәре булган. Торраны без Тура булган дип саныйбыз, төркиләр яшәгән төбәкләрдә андый исемле калалар билгеле. Мәсәлән, Себердә Тура каласы булган. Бу атама хәзер дә саклана.

Геродот сәяхәтләре вакытында Кече Азияне дә йөреп чыккан, шулай ук Көньяк Италиянең Тарент култыгындагы греклар колониясе булган Фурия каласында да күпмедер яшәгән. Анда да күп мәгълүмат туплаган. Кыскасы, этрусклар тарихы, теле белән шөгыльләнүче галимнәрнең байтагы Геродот версиясен кабул итә.

Шактый еллар элек миңа телевизордан үземне сискәндереп җибәргән бер хәбәр ишетергә туры килде. Экранда мөлаем йөзле, матур гына ыспай сакаллы, алтын кысалы күзлек кигән бер карт белән журналист әңгәмә корып утыра иде. Мин әңгәмәнең башын күрмәдем, шуңа әле күзлекле картның кем икәнен белмим. Тыңлый торгач, сүз халыкларның борынгы заманнарда кайдан кая күченүе, нинди халыкның генетик яктан нинди халык белән тугандаш булуы турында барганы аңлашылды. Сөйләүче Италиядәге Турин университетында эшләүче профессор-генетик икән. Аның мине сискәндереп җибәргән сүзләре хәтеремә уелып калды. Ул менә нәрсә диде: «...Мин утыз ел дәвамында Урта диңгез буйларында яшәүче халыкларның 15 мең ДНК үрнәкләрен тикшереп чыктым. Беләсезме, мине

бер факт гаҗәпкә калдырды. Тикшеренүләр нәтиҗәсендә Кече Азиядәге Лидия дәүләтендә, Эгей диңгезендәге Лемнос утравында һәм Италиянең борынгы заманда этрускларныкы булган Ветулония каласында яшәгән кешеләрнең ДНКсын тикшереп чыкканнан соң аларның генетик яктан тугандаш булуын ачыкладым. Мин тарихчы түгел, шулай да бу минем өчен гаҗәп ачыш булды...»

Соңыннан мин бу картның атаклы генетик Альберто Пьяццо икәнен белдем. Шуннан соң тарихта этрусклар дип аталган халыкның, Кече Азиянең көнбатышыннан күчеп килеп, Италиядә гүзәл мәдәниятkә ия уникe кала конфедерациясе төзүенә мин тәмам ышандым. Күрәсең, пеласкларның Борынгы Грециядән (Пеласгия) кысрыклап чыгарылганнан соң, Италиягә килеп урнашуы да хактыр. Тирреннар белән пеласкларның телләре бик якын булган, алар генетик яктан тугандаш халыклар икән лабаса. Шунысы кызык, Лемнос утравындагы пеласклар Троя шәһәренә дә бик якын торганнар. Аларның бер өлеше хәтта Троада ярымутравында яшәгән. Гомер үзенең «Илиада» әсәрендә Трояны греклар һөҗүменнән саклаучылар арасында пеласкларны да искә ала:

Гиппофоой предводил племена копьеборных пеласков,
Тех, что в Ларисе бугристой, по тучным полям обитали;
Гиппофоой предводил их и Пилей, Ареева отрасль,
Оба сына пеласгийского Лефа, Тевталова сына.

Димәк, Пилей, Арей, Леф, Тевтал, Гиппофоой – пеласк исемнәре булган. Аның берсе генә грек исеменә охшаш. «Гиппос» грекча «ат» дигәнне аңлата. Икенче юлдагы Лариса шәһәре Фессалиянең башкаласы булган. Борынгы грек тарихчысы һәм географы Страбон да Фессалияне пеласклар ватаны дип атый. Фессалия Борынгы Грециянең төньяк-көнчыгышында урнашкан дәүләт булган. Бу халыкны греклар үз илләреннән кысып чыгаргач, алар Италиягә күчеп килеп, анда Агилла дигән кала төзиләр. Ул соңрак латинча Цере (этрускчасы Цисра) дип үзгәртелә һәм Этруриядәге 12 шәһәр-дәүләтләрнең берсе булып китә. Күрәсең, Борынгы Грециянең төньяк-көнчыгышында урнашкан мөстәкыйль зур өлкә халкы пеласклар греклар белән дустанә мөнәсәбәттә яшәмәгән, шул сәбәпле алар атаклы Троя сугышы вакытында бу шәһәрне греклар һөҗүменнән сакларга килгәннәр. Бәлки, пеласклар троялылар белән тугандаш халык булгандыр, шуңа ярдәмгә килгәннәрдер. Троя сугышы б.э.к. 1200 елда тәмамлана, ул ун ел дәвам итә. Ул дәвердә, ягъни б.э.к. XII гасырда, пеласклар әле Борынгы Грециядән куылмаган була. Бу хәл соңрак чорга туры килә.

Геродотның тирреннар Кече Азиядән күчеп килгән дигән хәбәре шактый заманнар иң борынгылардан саналып килгән. Әмма тарих фәнендә

күтелмәгән ачышлар ясалып тора. Галимнәр Борынгы Мисырдагы Мәдинәт-Абу храмы диварларына чокып язылган язуларны укып, б.э.к. XIII–XII гасырларда «диңгез халыклары»ның Мисырга яу белән килүе турындагы тексттан өр-яңа мәгълүматлар алуга ирешәләр. Кемнәр булган соң ул Мисырга һөҗүмнәр оештыручы «диңгез халыклары»? Мәдинәт-Абу храмындагы текстта аларның исемнәре дә аталган. Анда лүкү, акайваша, пелешет, шакалуша, шардана һәм турша дигән халыклар телгә алынган. Бу һөҗүмнәр ике фиргавен – Мернептах һәм Рамсез III заманында ике тапкыр ясалган. Мәдинәт-Абу храмындагы текстта аларның исемнәре Мисыр телендә язылган. Галимнәр тарафыннан бу халыкларның сәер исемнәре ачыкланган. Лүкү дигән халык Кече Азиянең яр буендагы Кариядә яшәүчеләр, ягъни карлар икән. Акайвашалар – ахей греклары, пелешетлар – филистимнәр, шакалушалар – Сицилия утравыннан килгән сикеллар, шардана – Сардиния утравыннан килгән сардлар, ә туршалар – шулай ук Кече Азиядәге Лидия дәүләтендә яшәүче лидлар булган. Ул заманда Эгей диңгезе бассейнында яшәгән карлар, тирреннар, ахей греклары, диңгез утрауларында яшәүче башка халыклар бик актив тормыш алып барган. Алар оста диңгезчеләр булганнар, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр, җае чыкканда пиратлык-юлбасарлыктан да баш тартмаганнар. Һәркайсы үз көнен үзенчә күргән. Ара-тирә берничәсе берләшеп, бай Мисырга яу белән дә баргалаганнар, андагы калаларны талап кайтканнар. Ә кайвакыт фиргавен гаскәре аларның үзләрен туздырып ташлаган.

Шунысы мөһим, галимнәргә Мисыр язмаларындагы «турша» дигән халыкның ватаны Кече Азиядәге Лидия патшалыгы булуы һәм туршаларның шул ук тирреннар икәне инде билгеле була. Димәк, Геродотның тирреннар турындагы хәбәре дөрес булып чыга. Бу мәсьәләгә карата күренекле этрусколог В. Бранденштейн да үз фикерен әйтә. «Ул тиррен-туршаларның көнбатыштан килгән «диңгез халкы» булуын тулысынча кире кагып, аларның Кече Азиядәге халык булуын раслый торган дәлилләр китерә: беренчедән, Мәдинәт-Абу храмындагы рельефларда туршалар Кече Азиянең типик халкы буларак сурәтләнгән; икенчедән, хетлар падишаһы Тутхалияша IV текстында «таруиша» исемле халык телгә алына, бу халыкның туршалар булуы ачык күренә, соңгы вакытта аларны Троя халкы белән дә тәңгәл күрәләр; өченчедән, грекларның тирреннарны Эгей диңгезе бассейнында яшәүчеләр дип сөйләүләре тиррен-этрускларның Италиягә килеп урнашуына караганда күпкә иртәрәк башланган».

Димәк, Геродот язып калдырганча, тирреннар Эгей диңгезе бассейнында күптән яшәгән. Шул сәбәпле диңгезче греклар аларны яхшы белгән. Грекларның Кече Азия ярларында колонияләре, шәһәрләре дә булган.

Бу очракта тарихчы Дионисий Галикарнаслы фикерен дә әйтеп үтәргә кирәктер. Ул этрусклар тарихы мәсьәләсендә бөтенләй капма-каршы фикердә торган. Бу тарихчы, Геродот кебек үк, Кече Азиядәге Кария дәүләте башкаласы Галикарнас шәһәрендә туа. Б.э.к. I гасырда Римдә яши, анда тарихи хезмәтләр яза. «Борынгы заманда Рим» исемле хезмәтендә Геродот фикеренә кискен каршы чыга: «...лидлар (тирреннар) белән этрусклар арасында бернинди уртаклык юк – алар төрле телдә сөйләшәләр, төрле аллаларга табыналар, гореф-гадәтләре һәм кануннары да башка. Шуңа күрә, минем фикеремчә, этрускларны җирле халык дип санаучылар хаклы, алар беркайдан да күчеп килмәгән, гомер-гомергә шунда яшәгән», – ди.

Кыскасы, Дионисий Галикарнаслы якташы Геродотның фикерен кабул итми. Тик шунысын да истә тотарга кирәк – Геродот б.э.к. V гасырда яшәгән, ә Дионисий б.э.к. I гасырда Римдә яши. Бу ике галим арасында 400 еллык ара бар. Бу бик күп вакыт. Дүрт гасыр арасында Кече Азиянең көнбатышындагы Кария, Лидия, Мисия дәүләтләрен Рим империясе яулап ала, алар Римнең «Азия» дип аталган провинциясенә әверелә. Тарихчы Дионисий Кече Азиядәге Галикарнас шәһәрендә туса да, карьера ясау өчен империя башкаласы Римгә барып урнаша, тырышып латин телен өйрәнә. Халыкара телгә әйләнгән латин телендә «Борынгы заманда Рим» исемле һәм башка хезмәтләрен яза. Ул вакытта Рим инде Этрурияне дә күптән яулап алган, бу халык дәүләт теленә әверелгән латин теле йогынтысында ассимиляцияләнгән була. Шулай этрусклар Рим гражданнарына әверелә. Шул сәбәпле Дионисий Галикарнаслының Геродотка каршы чыгуы бик табигый, бу сәяси яктан да файдалы булгандыр. Ник дигәндә, Рим яулап алган халыклардан латинлашкан империя халкы ясау өчен күп көч куя. Империяләр һәрвакыт халыкларның үз йөзен бетерергә, унификацияләргә омтылалар. Шуңа күрә Геродот язганнар дөреслеккә туры килә дип уйларга нигез бар.

*Энҗе Даутова*

# МӨГАЛЛИМӘ

***Аннотация.** Татар халкы тарихында үз эзләрен калдырган татар хатын-кызлары бик күп, әмма бүгенге көндә аларның исемнәре, кызганычка каршы, онытылып, тарих шәүләсендә калып бара.*

***Төп сүзләр:** мәктәп, укытучы, мәгариф, китап, тәрбия.*

Унтугызынчы гасырлар башында Россиядә җәдитче татар мәгърифәтчеләргә таянып татар мәктәпләре ачыла., анда ярлы балалары да белем ала башлый. Ул мәктәпләрдә дин генә түгел, математика, география, табигать белеме, әдәбият һ.б. укытыла. Балаларга кул эшләре өйрәтелә. Ул җәдитчә мәктәпләр дип атала . Шул елларда инде Владимир Ленинның әтисе Илья Ульянов Симбирск өлкәсенең мәгариф башлыгы буларак йөзләгән мәктәпләр ача. Халык белемгә омтыла башлый. Халыкның аң-белемен арттыру белән байлар да кызыксына. Татар телендә газет-журналлар чыга. Бик күп яңа язучылар, шагыйрьләр ул журналларда үз әсәрләрен бастыралар.

Шул чорларда Бөгелмә өязе Миңлебай авылында 1893 елны Вәлиәхмәт мулла гаиләсендә өченче бала булып кызы Ситдика туа.



*Ситдика Хәбибуллина (Даутова) белән Гасимә Мостафина (Рафикова)*

Вәлиәхмәт Мөхетдин улы Даутов яшьлегендә Ырынбур губернасының Троицк шәһәренең мәдрәсәсендә белем ала, Миңлебай авылына кайткач Вәлиәхмәт атаклы Гыйльман ахун Ибраһимов мәдрәсәсендә аның улы киләчәктә бик абруйлы һәм дәрәҗәле булып танылган мәгърифәтче Фатих Карими белән бергә балалар укыта. Үзенең өч кызын (Ситдика да араларында) һәм җәмәгатен Вәлиәхмәт үзе укыта. Алар барысы да дүрт тел беләләр: фарсы, гарәп, рус, татар. Коръән сүрәләрен, аятьләрен яттан беләләр. Рус телен өйрәнү өчен Вәлиәхмәт күрше Федотовка авылыннан рус укытучы

Екатеринаны өенә китереп 3 ел кызларын русча укыта, кызлары кул эшләренә дә өйрәнә: чигү, тегү, бәйләү һ.б. Гаиләгә гәҗит-журналлар килеп тора, шуның белән кызлар Габдулла Тукай, Закир Рәмиев, Галиәскәр Камал һәм башка язучылар, шагыйрьләр әсәрләрен укып торалар.

Яр Чаллы кантонының ике бертуган байлары Хальфиннәр Бөгелмә өязе Миңлебай авылындагы укытучы Вәлиәхмәт Даутов белән кызыксыналар һәм алдынгы карашлы, гыйлемле укытучыны Каенлы авылына Гариф мулла мәдрәсәсенә мөгаллим итеп куялар, бер ничә елдан Каенлыдан алып Зәй өлкәсе Кадер авылына мулла-мөгаллим итеп җибәрәләр. Шул авылда Ситдика 14 яшеннән авыл балаларын укыта башлый. Аның уңышлы эшен күреп торган янәшә-тирә байлары, муллалары үз кызларын укыту өчен аңа китерәләр. Дини дәресләре белән бергә ул дөньяви фәннәр: тарих, география, математика, грамматика, сарф-нахү укыта, дәресләрдән соң кул эшләренә өйрәтә.

Революциядән соң Ситдика әтисе биргән белемнәр белән Бөгелмә педучилищесына барып, мәгърифәтче Хади Атласида укып, рус телендә имтиханнар тапшырып, башлангыч класслар укытучысы белгечлеге буенча диплом алып кайта һәм 32 ел – 1944 елга кадәр – укытучы булып эшли.

Совет власте килгәч Ситдика мәгариф бүлеге кайсы авылга җибәрсә, шунда укыта. Ул дәһшәтле елларда укытучыларның эшләгән эшләре күп кырлы һәм аларга һөҗүм иткән чаклар да күп булган. Бигрәк тә сәнәкчеләр сугышында авыл укытучыларының гомерләре еш кына куркыныч астында калган. Мәсәлән, үземнең әтиемнең бер туган сеңлесе Рәсиха яшь укытучы буларак Карабаш авылында эшләп йөргәндә, сәнәкчеләр кулына эләгеп фаҗигале үлем белән үлә, аны сәнәк белән чәнчеп бәкегә батырып үтерәләр.

Кызганыч, Ситдика Даутова да сәнәкчеләр кулына эләккән була һәм нинди могъҗиза белән үлемнән котылганын үзенең истәлекләренә болай итеп язып калдыра: «1920 нче ел 18 нче февраль көне бик салкын көн иде. Мәктәпкә барып уку сәгатьләрен бетереп кайтырга чыктым. Балалар белән бергә зур урамга чыккач балалар һәр кайсы салкыннан куркып йөгереп үз өйләренә таралдылар. Мин үзем генә калдым. Зур урамда берничә урында ирләр җыелышып торуын күреп, мин куркып калдым. Шуннан квартирга ашыгып кайттым. Күрше кызы Гайнеҗинан мунчага чакыргач, кереп, юынып чыктым да өстәл янына чәй эчәргә утырдым. «Бабай» ишекне ачып башын тыкты да: «Апа, бирегә чык», – дип дәште. Шул вакыт күтәрелеп тышка карасам, ишек алды тулы халык – ирләр, кайсы мылтык, кайсы сәнәк күтәргәннәр. Шул вакыт берсе өйгә килеп керде һәм миңа: «Партбилетыңны миңа бир» – дип кычкырды. Мин:

«Минем партбилетым юк, мин партиядә түгел әле» дигәч икенче башлыклары кычкырды (анысы атка атланган иде) партбилетың булмаса әйдә үзең безнең белән» диде. Мин: «Мине кая алып барасыз соң? дип сорагач, «баргач күрерсең» диделәр. Шул вакыт мин киенеп чыктым, капка төбендә җигүле ат тора иде, берсе: «Утыр шул чанага, үзеңне ватып алып барырбыз» дигәч, икенчесе: «Атка ник утыртасың аны? Шул көе генә кирәк ватып алып барырга аны» диде. Мине алып киткәнне карарга һәр йортның капка төбенә йорт хуҗалары чыкканнар һәр кайсы елап тора... Зур урамга чыккач минем күземә алда кара урман кебек кара зур шәүлә күренә башлады. Аякларым атлаган саен артка киткән кебек тоела, кайсы яктан китереп чәнчерләр дип куркып киләм. Шул вакытта ул кара шәүләне күп халык төркеме икәнен аңладым һәм анда барып җиткәнче чәнчерләр кебек тоелды. Барып җиткәч, һәммәсе яхшы таныш кешеләрне күргәч күңел сөенеп китте. Мин: «Исәннәрме абзыйлар» дип дәшсәм, һич кем минем сәламемне алмады, ягъни берәү дә дәшмәгәч, мин «Болар мине үзләре китергәннәр икән» дип уйладым. Сәнәкчеләрнең хуҗасы миңа мөрәҗәгать итеп: «Халыкка карап торма, безгә карап тор» дип команда биргәч, аларга борылдым. Тыңлап торсам: «Менә халыктан синең турында сорыйм, алар яхшы дисәләр – тимибез, әгәр начар дисәләр – үзебез белгәнчә эш итәрбез» диделәр. Ат өстендә килеш халыкка карап: «Бу мөгаллимә нинди, яхшымы? диде. Бер кем дәшүче булмады. Шул вакыт бик начар өс-башлы 5–6лап кеше бердән кычкырдылар: «Бик начар, балаларга җыр өйрәтә, театрларга йөри, Коръән таптый, фәлән-төгән» дип кычкыргач, мин түзмәдем: «И абзыкайлар, мин сезне беренче күрәм, шулай ук сез дә мине беренче күрәсез, сезнең мәктәптә укучы балаларыгыз юк, каян беләсез минем Коръән таптаганны, театрга барганны яки җыр өйрәткәнемне?» дигәч, хуҗалары тагын кычкырды: «телләшмә» дип. Аннары команда бирде, «Приклад белән кыйнап кертеп ябыгыз үзен» дип, һәм шунда ук мине приклад белән суккалап алып кереп киттеләр. Иң элек бер яхшы өйгә алып керделәр, ул өйдә безнең директорыбыз Ибраһим Туйкин тора, аның йөзләре канаган, иреннәре шешкән, күзләре кара янган, аягында көчкә басып тора. Аның янына барып: «Сине кыйнадылар мыни?» дип сорадым. Ул: «Кыйнау түгел, ваттылар гына» дип җавап бирде.

Безне керткән йортны кем йорты икәнен белмәгән идем, анда Зәйнәп Мисбахова дигән укытучының апасын күргәч, «Бу апа бирегә ни өчен килгән икән дип уйлаган идем. Юкса мин һәр вакыт аларга барып йөри идем. Мине чишендереп ягъни пальто һәм шәлемне салдырып бер күлмәктән генә калдырып салкын амбарга чыгарып яптылар. Яңа мунчадан гына чыгып килгәнгә, киемнәрне салырга да өлгермәгән идем. Юеш

чәчләр белән салкын амбарга кергәч артык каты туңдыра-калтырата башлады. Кеше бит курыкса да туңа башлый, ә монда курку да нык тәэсир иткәндер, һич чыдый алмыйм туңуга. Туйкинның өстендә толып һәм эчтә юка гына булса да пальто сыман нәрсәсе бар, аны ничек алмаганнардыр, шуңа ул бердә калтырамый. Мин бик туңгач ул кычкыра: «Мөгаллимәне туңдырып үтерәсез бит!» дип. Амбарны каравылларга шул авыл кешесен куйганнар иде, ул Туйкинга җавап итеп ишек ярыгыннан: «Бергәләп елышыгыз инде ничек булса да, үлергә тырышмагыз, алар икенче авылга китсәләр сезне чыгарып җылытырбыз» ди. Сәнәкчеләр ыгы-зыгы йөргән арада теге апа минем пальтоны алган һәм яшергән икән, рәхмәт төшкере. Бик калтырагач, Туйкин миңа: «Кил минем толыпка, бергә булгач туңмассың» ди. Мин: «Ибраһим иптәш, туңып үлсәм үләрмен, шулай да синең өстәге толып эченә керә алмам» дигәч, үзенең эчтән кигән казакиен салып бирде. Ул буйга кечкенә иде шуның өчен аның кием минем ярты гәүдәмне дә капламады. Төн булгач безне җылытырга чыгарабыз дип амбарны ачканнар иде сәнәкчеләр китте дип, кире кайттылар дип яңадан бикләделәр. Шул рәвешле таңга кадәр торып таң аткач иртүк тагын чыгардылар. Шул вакыт апа минем пальтоны китереп биргәч, шунда дөньяда миннән бәхетле кеше булмагандыр. Пальто кигәч алай калтыратмады да. Тагын көн үтеп, икенче төн җиткәч шул авылның муллалары (ул авыл бик зур, өч мәчетле, шуның өчен анда муллалар да күп иде) үз ара сөйләшкәннәр «Ул укытучыларны нишләп үтертәбез» дип. Аларның балалары да укый иде. Алар халыкны җыеп аңлатканнар безне коткару турында. Тәүлек ярымнан соң безне амбардан чыгарып икебезне ике кешегә парукага бирәләр. Мине безгә туган тиешле Әхмәтзия исемле бер кеше ала, Туйкинны дин сабагы укытучы Сабирҗан дигән кеше ала. Минем белән Зәйнәб тә бар әле. Әхмәтзыя абзыйларга кайткач, аның хатыны безгә тәмле ашамлыклар китереп куйды һәм ашарга кыстый иде.Тик миндә ашауга һич аппетит юк, бер нәрсә дә ашап булмады. Шул килеш йомшак урынга ятсак та һич йоклап булмый, чөнки минем гомеремнең актык көне бит дип уйлыйм, куркам. Сәнәкчеләр икенче авылга киткәндә мине халыкка тапшырганнар. Янәсе халык үзләре мине юк итүне хәл кылсыннар дип комендантка әйтеп киткәннәр. Комендант халык белән сөйләшкән һәм мине исән калдыру турында Штабка үтенеч язып җибәргәннәр. Инде йоклый алмый туңып-калтырап ятканда абзыйның ишеген кагалар, ишектән комендант Галимҗан килеп керде. Ул кергәч абзый аннан штабка китүче кеше турында: «Нинди хәбәр алып кайткан» дип сорады. Мин йоклаганга салынып шыпырт кына ятам. Галимҗан бик сакланып кына: «Начар хәбәр шул, иртәгәгә калдырмыйча төнлә уборка ясарга дигәннәр» дигән хәбәрне әйткәч, икесе дә байтак сүз дәшмичә тордылар.

Шуннан соң Галимҗан әйтеп куйды: «Әхмәтзыя абзый, әллә без аны Мөәминҗанга хатын дигән исемне ясасак, алып кала алмабыз микән? Шулай итик ме әллә?» дигәч, мин түзмәдем, яткан урынымнан әйтеп куйдым: «Мине Мөәминҗан хатыны дигәнче атсалар яхшырак булыр» дип. Чөнки Мөәминҗан дигән бер мулла унлап хатын алып аерган кеше иде. Шуннан соң икесе дә сүзсез аптырап торгач, шундый карарга килделәр «Булмаса икебез дә бик иртә торып, укучы балаларның өйләренә барып, хәлне аңлатып, балаларны һәммәсен минем янга җыерга һәм аларны ничек эшләү турында ныклап төшендерергә» дип киңәш итешеп Галимҗан кайтып китте. Ул вакытта бик соң иде, ягъни ярты төн узган иде. Шуннан соң Зәйнәб белән икебез дә йоклап киткәнбез.

Таң сызылып атканда Зәйнәб миңа төш сөйли: «Апа, мин бик яхшы төш күрдем, сине атмаслар, бик күп йомырка җыйдык синең белән» ди. Таң аткач тордык, һаман күңел курка-тынычсыз, һич нәрсә ашап булмый ике тәүлек ашаган булмаса да. Шул вакыт минем укучыларым килеп тула башладылар. Мине күргәч елыйлар һәм үзләре белән дини китапларын алып килгәннәр. Әти-әниләре биреп җибәргән, янәсе алып китә башласалар: «Без дин укыйбыз» диегез дип. Ул вакытта гарәп хәрефе белән укыта идек. Миңа әйтәләр: «Апа, без сине атарга бирмибез, без шуның өчен бирегә килдек» диешәләр. Бер вакыт ишектән алты кеше мылтыклар, сәнәкләр, кайсы чашка тоткан, өйгә килеп керделәр. Мин бүлмә якта утыра идем. Балалар дәррәү кулындагы китапларын гөр килеп укырга тотындылар. Кергәннәрнең арадан берсе: «Укытучыгыз кайда?» дип кычкырды. Мин балалар курыкмасыннар дип тизрәк алар янына чыктым, бу кешеләр миңа нәрсәдер дәшәләр тик мин балалар тавышы белән ишетмим. Балалар һәммәсе минем янга җыелдылар, өстемә өелделәр, кайсы алдан, кайсы арттан мине кочакладылар: «Без апаны сезгә бирмибез, аны кайда алып барсагыз аннан калмыйбыз, сезгә атарга бирмибез, өстенә ятабыз» дип акырышалар. Шуннан мин аларны тынычландырырга тырышып: «Туктагыз әле, укучылар, абыйларны тыңлыйк әле, алар нәрсә әйткәнен белик әле, туктагыз!» дигәч, бераз тынычландылар шулай да һаман миңа сырышкан хәлдә үзләре. Балалардан: «Иртә нәрсә? Төштән нәрсә укыйсыз?» дип сорагач һәр кайсы үзенең кулындагы китап исемен әйттеләр. Шуннан кулына чашка тотканы сүгенеп: «Сезне өйрәтеп куйганнар» дип, чашкасын тартып чыгарды, тик шул вакыт балалар сискәнеп куйдылар, шулай да җыйнаулашып: «Алай булса без аны укый белмәс идек бит, менә кайсы җиреннән укытып карасагыз да укый алабыз» дип, чатнап торалар. Шуннан соң ни дип тә әйтмичә: «Шул китапларны гына укыт» диеп чыгып киттеләр. Сәнәкчеләр китеп, берничә көн үтеп киткәч Туйкин белән мине сельсоветка чакырып алалар һәм бездән справка со-

рыйлар, ягъни авыл халкы сәнәкчеләр восстаниясында катнашмады дип справка язып бирдек. Димәк шул көнне безгә Мәләкәс шәһәреннән отряд килә икән дигән хәбәр ишетелде. Бер заман 100 подвод белән отряд килеп төште. Авыл советыннан мине чакырып бер кеше килде. Ә мин, безнекеләр килгән дигәнгә ышанмыйм дагын сәнәкчеләр дип куркам, барырга теләмим. Шул вакыт бабаң: Без ялганчы түгел, дөрестер, курыкма, дигәч аңа ияреп киттем. Әйтүе дөрес икән, мине отряд начальнигы ачык чырай белән каршы алып миңа кул биреп күреште һәм безне, укытучыларны, восстание беткәнче алып китеп үзләре белән саклап йөртәчәкләрен әйтте. Янымда Зәйнәб барлыктан барырга теләмәүмне белдергәч, миңа восстаниянең тиз бетмәвен, яңадан килеп юк итүнең куркынычы барлыгын әйткәч, мин алар белән китәргә риза булдым. Без өч укытучы (Туйкин, мин һәм өй базларында качып яткан Зәйнәб тә) чыккан иде. Безнең өчен өч толып, бер ылау әзерләнгән иде, шул ылауларга утырып 100 ылау булып юлга чыгып киттек. Без иртә сагать уннарда киттек, шул көнне сәнәкчеләр әйләнеп килеп безне сораганнар. Авылда булган булсак, белмим нишләткән булырлар иде.

Юлда барганда авыл советларына кереп ул авылның халкы сәнәк сугышына катнашканмы, юкмы тикшерәләр, гаепләре булганнарга һөҗүм ясыйлар. Безне бердә курыкмаска кушалар.

Безнең өчебезгә дә пистолет бирделәр һәм атарга өйрәттеләр. Шул рәвешчә бер ничә көн йөргәннән соң Шөгергә (район үзәгенә) килеп җиттек. Авылга җиткәндә тау битендә урман эченнән төшәсе, авыл ап-ачык күренә. Авыл эчендә берничә җирдә халык төркем-төркем булып җыелганы күренә. Шуны күргәч, отряд начальнигы (Мингачев) безгә каршы һөҗүм әзерләнүче дошманнардыр дип уйлап, отряд цепка таралырга команда бирде, ләкин бер каршы торучы булмады. Киресенчә, төркем халкы таралып һәммәсе юкка чыктылар. Авылга тыныч кына барып керсәк, аңлаттылар. Ул төркемнәр каберлектә мәетләр күмүчеләр икән. Элек көнне Яңа Иштирәк авылында сәнәкчеләр белән сугышканда Шөгернең бер ничә кешесе үлгән булган. Шөгердә безне, ягъни укытучыларны бик яхшы, бай йортка квартирга куйдылар һәм безне бик яхшы кунак итәргә кушты начальник, үзләре тикшерү өчен китте. Без Зәйнәб белән квартирада калдык, ул йорт хуҗалары безне руслар дип белгәннәр икән. Хуҗа кеше шул авылның мулласы икән, аның хатыны авыру икән. Безнең татарлар икәнен белгәч, бик шатланды һәм безгә үзенең кайгысын сөйләп безгә үтенеч белдерде: «Сез үзебезнең туганнар икәнсез, зинһар начальнигыгызга иремне атмаска, исән калдырырга әйтегезче, ул сезнең сүзне тыңлар» дип. Без аптырап калдык һәм: «Ни өчен алай әйтәсез?» диештек. Ул безгә сөйләп бирде: «Мулла мәетләр күмүче һәм Корьән укып озатка-

ны өчен аңар начальник әйткән икән: «Син сәнәкчеләрне, ягъни яхшы кешеләрне үтерүчеләрне зурлап озаткансың, шуның өчен үзеңне дөньяда калдырмабыз, атып китәбез» дип. Ул безгә шулай аңлатты. Ул үлүчеләр сәнәкчеләргә каршы сугышчылар, яхшы совет кешеләр булганын. Без дә начальниктан мулланы атмавын үтенеп сорадык. Без киткәндә мулла абзый күз яшьләре белән елап бик зур рәхмәтләр әйтеп озатып калды.

Шөгердә вакытта начальник бер байның яхшы атын алып разведчик булып үзе бармакчы булып әзерләнде һәм үзе атка менеп китте. Барачак җиребез 10 км чамасы ераклыкта булган Керкәле дигән авыл иде. Авылга җитәргә бер км. чамасы калгач, начальнигыбыз безнең янга чабып килеп безгә әйтә: «И туганнар, минем гомерем бетмәгән, сезнең дә бәхетегез бар икән» ди. Без ни булды дисәк: «Бер нәрсә дә уйламастан авылга җиткәндә пулялар оча башлады, тик ат муйнына ятып кына исән калдым» ди. Шуннан соң солдатларга цепка таралырга команда бирде һәм байтак вакытка кадәр кара-каршы сугыштылар. Зәйнәб белән без: әйдә яңадан авылга кайтыйк дип сөйләштек һәм безне алып килүче рус малаена да шул сүзне әйттек. Ул малай бик курыккан, безнең сүзгә бик тиз риза булып атын кайту юлына борды. Артка борылып карасак, отряд авылга кереп бара.

Армияда алда гына түгел, артта да разведчиклар була икән. Арттагы разведчиклар килеп җиттеләр дә бездән: «Кая барасыз?» дип сорадылар. Без: «Өйгә кайтабыз, куркабыз» дидек. Алар безне орыштылар һәм безне кире алып килделәр: «Әллә восстание бетте дип уйлыйсызмы? Сезне бүген үк килеп үтерәчәкләр бит» диделәр.

Керкәле авылына килеп кердек, ату туктаган иде инде. Керкәле зур гына базарлы авыл иде. Без авылга кергәндә бер җирдә дошман күренми, барысы да качып беткән иде. Авылда берничә урында пожар иде, шулай да һич бер кычкыручы яисә пожар янына килүче һичкем күренми. Шулай ук авыл кешеләре дә һичкем күренми. Тик бер зур амбарның таш түбәсенең шарт-шорт килеп янган тавышы гына килә иде. Ул амбарның түбәсе салам белән ябылган икән. Яна торгач янган агачлары эченә төшә башлаган, пешеп үлүдән куркып инде эчтәге сугышчы геройлар һәммәсе шунда кереп качкан булганнар икән. Алар савылып чыга баралар, солдатлар чыккан берсен ата баралар. Шулай итеп барлыгы 35 данә кешене бер өем итеп куйдылар. Атылганнардан тыш байтак кеше авылның теге-бу урыннарда качкалап калганнар. Аларны төрлесе төрле яктан айкаладылар да бераздан тындылар. Сугыш тынгач начальник сугышчыларга әйтте: «Безнең арттан килүчеләр булган, без яңадан Шөгергә кайтып һәм аларның арт сабакларын укытыйк, юкса аларны бик тыныч калдырдык» диде. Сугышчылар риза булдылар һәм яңадан

Шөгергә юл тоттык. Шөгергә җиткәндә, авыл башында, яхшы гына киемле бер хатын басып тора иде. Иң алдагы ылауда начальник белән ике солдат утырып бара иде. Теге хатынның ишарәсен аңлап алар хатын янына барып бер кадәр сөйләшкәннән соң кузгалып киттеләр, шулай үк алар артыннан без дә киттек. Алар авыл советы янына килгәч, эчкә кереп киттеләр бер ничә кеше, без чаналарда утырып калдык. Байтак кына утырудан соң безгә дә чакыру хәбәре килде. «Мөгаллимәләр, бирегә керегез!» дип кычкырдылар. Без: нәрсә бар икән дип? ашыга-ашыга килеп керсәк, ишек төбендә бер кешене күрәм, чишендергәннәр, ялан аяк карга басып тора, мине арестовать итеп амбарга япкан кеше иде. Ул кеше безне амбарга япкач Ибраһим Туйкинның абыйсы Фатих Туйкинны тиф белән каты авырып яткан җиреннән кырга алып чыгып, атып, тирескә ташлап калдырган иде. Үзенең өстендә Фатих киемнәре, Ибраһимның яхшы яңа тектергән туны иде. Начальник без килгәч безгә күрсәтеп: «Бу кешене таныйсызмы?» дип сорады һәм аңа сораулар бирде: «Болар кемнәр, алар сиңа нинди начарлык эшләделәр?». Бу сорауларга дәшми торды, аннары: «Ул укытучыны ни өчен аттың, ата-анаңны үтердеме яки йортыңны басып әйберләреңне урладымы?» дигәч: «Мин атмадым, кыйнадым гына» диде. Шуннан соң начальник аны сүгеп, аның йөзенә төкерде дә аны атарга рус солдатларга команда бирде дә һәм шунда ук тездән тирәнлектәге карга бастырып аттылар.

Без киткәч Шөгергә зур төркем сәнәкчеләр килгән һәм безнең арттан барып отряд белән сугышмакчы булып, үзләренә күп кораллар табып, сугышмакчы һәм җиңмәкче булып килгәннәр. Аларны Шөгерлеләр нинди юл беләндер тоткарлап, җибәрмәгәннәр. Теге авыл башында торган хатын шул хакта сөйләгән икән. Начальник әйтә: «Менә кулыңда Американски мылтык ди, кемнәрне ничек атуларын һәм башка төрле эшләгән начарлыкларын барын сөйләттем, һәммәсен сөйләп бирде» диде. Шул хәлләрдән соң берничә генә көннәр солдатлар белән йөргәч, бик тынгысызлыктан туңдырды, шунлыктан Туйкин белән без Бөгелмәгә илтүне сорадык. Ул безне Кляулин стансага 10 солдаттан илттерде».

Ситдика Даутованың тормышында һәм шул чорда яшәгән башка укытучыларның да дәһшәтле еллары байтак кына булган. Шулай да Ситдика кыенлыкларга бирешмичә, 70 ел гомерен мәгариф хезмәтенә багышлаган, һәм үзенең биш баласын үстереп (улы – Нил Фатих улы Хабибуллин КАИ институтының Чебоксар һәм Үзбәкстанның башкаласы Ташкенттагы филиалларының ректоры иде, оныгы Фәрит Нилович Хәбибуллин әле бүгенге көнгә хәтле радио- телекомпания системасында башлыкларның берсе), 82 яшендә бакый дөньяга күчә. Кабере Казан шәһәренең зиратында.

Бу мәкалә Ситдика Даутованың үз кулы белән язып калдырган көндәлек дәфтәреннән алынды.

## Чыганаклар

1. Даутова Э. Дауд и потомки. Казань: изд. «М-Принт» 2011.
2. Альметьевская энциклопедия. Из истории Альметьевского региона. Альметьевск: Изд. «Татполиграф», 1999.
3. Ибрагимов М. Сайланма әсәрләр. Казан. 2005.

*А.С. Хохлов, А.Ш. Кабирова, Р.Б. Гайнетдинов*

## «КАЗАНСКИЙ ОБВОД» В НАШЕМ КРАЕ

Строительство грандиозного Волжского военно-инженерного оборонительного рубежа на территории трех автономных республик Поволжья в 1941–1942 гг. является одним из крупнейших трудовых подвигов советского народа в истории годы Великой Отечественной войны и яркой страницей трудового героизма в более чем столетней летописи Татарстана. История «Казанского обвода» до сих пор является малоизученной темой, не названы поименно простые герои этого величественного деяния, не выявлены и не мемориализованы места погребения всех лиц, умерших при выполнении этого важного государственного задания.

В середине октября 1941 г. немецкие войска находились в 120 км от Москвы на Можайской линии обороны. Сложившееся под Москвой опасное положение потребовало проведения серьезных оборонительных работ и подготовки территории на случай распространения военных действий с целью противостоять продвижению противника в глубь страны.

13 октября 1941 г. решением Государственного комитета обороны при Наркомате обороны СССР было организовано Главное управление оборонительных сооружений (ГУОС). В составе ГУОС НКО СССР было организовано 17 Управлений оборонительного строительства, целью которым ставилось возведение тыловых оборонительных рубежей от Архангельска до Астрахани протяженностью 10 тыс. км.

16 октября 1941 г. Государственный Комитет Обороны принял решение о сооружении Волжского оборонительного рубежа. 29 октября 1941 г. по приказу ГУОС НКО СССР было сформировано 11-е управление оборонительного строительства во главе с И.С. Шикторовым. В составе 11-го УОС было организовано 10 участков военно-полевого строительства, из них пять (№ № 1, 2, 3, 4, 5) на территории Татарской АССР; три (№№ 6, 7, 10) на территории Чувашской АССР и два (№№ 8, 9) на территории Марийской АССР. На территории Татарстана оборонительные сооружения располагались полукольцом вокруг Казани (отсюда название – «Казанский обвод») и проходили от деревни Покровское на берегу реки Волги через станцию Урмары, райцентр Кайбицы, райцентр Апастово к райцентру Куйбышеву (ныне г. Болгар).

Участок военно-полевого строительства № 3 занимал территорию по реке Свияга от с. Бишево в Апастовском районе до д. Никольские Выселки (в 5 км от д. Степановка Буинского района Татарстана выше по течению Свияги), с центром военно-полевого строительства в с. Черки-Дюртиле (Буинский район).




Схема "Казанского обвода"

Решением Татарского обкома ВКП(б) и Совнаркома ТАССР начальником полевого строительства был утвержден начальник Управления строительства железной дороги Казань–Бугульма Франц Семенович

Друскис, имевший хороший организационный опыт на строительстве Казанской железной дороги[1].

Мобилизация населения на работы началась с 25 октября 1941 г. по распоряжению Казанского комитета обороны. В первую очередь привлекались жители Казани и тех районов, по территории которых проходил Казанский обвод: Апастовского, Кайбицкого, Буинского, Тетюшского и других. Затем начали использовать труд колхозников близлежащих к строительству районов. Каждому району устанавливались свои задания. К примеру, Буинский район должен был выполнить наряд на 10 тыс. человек, Кайбицкий – на 9,3 тысячи, Нурлатский – на 7,8 тысячи, Верхнеуслонский – на 3,8 тысяч. Более удаленные от строительства районы предоставляли меньшее количество людей: Балтасинский – 3 тыс. человек, Ципьинский и Высокогорский по 2 тысячи. Казань по плану должна была отправить на сооружение рубежной линии 83 550 человек. Всего по разнарядке в строительстве предусматривалось участие 281 900 человек: студентов, рабочих промышленных предприятий, колхозников, учащихся школ ФЗО. Кроме того, для работы на Казанском оборонительном рубеже мобилизовался авто- и гужевой транспорт: 12 660 лошадей, 162 трактора, 71 грузовая автомашина.

Первая группа строителей оборонительных сооружений была направлена на участок ВПС № 3 из Казани 28 октября водным путем по реке Волга до пристани Тетюши. 14 ноября в распоряжении начальника ВПС № 3 находилось 8029 человек. Всего из Казани прибыли 13 тыс. человек.

На строительстве оборонительных сооружений на участке ВПС № 3 участвовали работники казанских заводов, предприятий и организаций: завода имени Ленина, завода № 387, мясокомбината, речного порта, 5-й швейной фабрики, завода «Серп и Молот», завода № 543, Союзного стройтреста № 12 Наркомстроя, Союзного треста № 14 Наркомата авиационной промышленности, а также колхозники из районов ТАССР. Также возводила оборонительные сооружения 8 саперная бригада 4 Саперной армии. В соответствии с объемом работ на трассе ВПС № 3 еже-

[1] Решение о строительстве железной дороги Казань–Бугульма было принято И.В. Сталиным в 1938 г. В апреле 1939 г. народным комиссаром путей сообщения Л.М. Кагановичем было утверждено проектное задание на постройку магистрали Казань–Бугульма длиной 354 км. Организация строительных работ должна была производиться в три этапа. На первом предусматривалась постройка стокилометровой линии от Дербышек (Казань) до реки Кама, на втором – от Чистополя до Бугульмы, на третьем – переход мостом через Каму и устройство подходов к нему. В том же году началась подготовка к строительству, а в 1940 г. на трассе приступили к основным работам. В течение полутора лет было произведен значительный объем земляных работ и началось возведение инженерных сооружений на первом участке дороги, но начавшаяся война прервала работы. В дальнейшем проект был свернут.

дневно работало от 15 тысяч до 18 тыс. человек. Наибольшее количество работников вышло 15 декабря 1941 г. – 18 940 человек.

Условия работы на строительстве были чрезвычайно тяжелые. Норма выработки составляла 1,6–1,7 кубометра грунта на человека. Механизированной техники не хватало, средства взрывания до второй половины декабря не поступили вовсе. Поэтому использовались материалы, которые мобилизованные приносили с собой. В основном это были лопаты, ломы, кирки, топоры, пилы. Все колхозные кузнецы изготавливали инструменты, пуская в дело железный хлам, который удавалось наскрести по избам. С каждым днем на оборонительном рубеже прибавлялось огневых точек, удлинялись окопы и противотанковые рвы.

Не способствовала оперативному проведению работ и погода. Строительство пришлось на осенне-зимний период. Вслед за осенней распутицей грянули морозы и начались снежные заносы. С понижением температуры земля начала промерзать, условия ужесточились. По воспоминаниям участников, мороз был жуткий, доходил до 35–40°, при возведении окопов землю оттаивали кострами, затем долбили её сантиметр за сантиметром тяжелыми ломами, а глубина окопа достигала 3 м в глубину.

Самым насущным и болезненным вопросом на возведении Казанского обвода являлась организация питания работающих: снабжение продуктами осуществлялось с большими перебоями, хлеб вовремя не подвозился, не хватало даже питьевой воды. Частыми явлениями были производственные травмы, особенно на лесных разработках. С наступлением холодов болезни стали нормой, фиксировались случаи инфекционных заболеваний.

Сооружение Казанского обвода в значительной степени было вытянуто только за счет сверхнапряженного, подчас каторжного труда, а также высокой сознательности и ответственности занятых на его строительстве людей.

Работа по сооружению Волжского оборонительного рубежа была завершена 25 января 1942 г. 11 февраля 1942 г. правительственная комиссия приняла выполненную работу с оценкой «хорошо».

Общая протяженность рубежа ВПС № 3 составила 42 км. Были возведены бетонные долговременные огневые точки (доты), углубленные укрытия для танков и артиллерийских орудий, а также километры окопов с оборудованными блиндажами и укрытиями для личного состава. Все эти сооружения давали возможность решить основную задачу – не допустить противника на ближние подступы к промышленному центру – Казани. Сооружения оборонительного рубежа поддерживались в постоянной боевой готовности до тех пор, пока сохранялась угроза Поволжскому региону

Один из дотов был сооружен на территории кладбища с. Черки-Дюртели, другой – на возвышенном склоне южнее в сторону с. Большое Фролово, два других – на склоне горы вдоль дороги от Черки-Дюртиле в направлении д. Черки-Кильдуразы. Всю долину р. Свияги испещрили окопы. Таким образом, в случае продвижения противника к Волге в этом районе с. Черки-Дюртиле представляло серьезный рубеж обороны и бои здесь могли быть немалые… Хорошо, что до этого не дошло.

Дополняют рассказ об объектах легендарного военного строительства в Заволжье в первые военные годы воспоминания Рустэма Гайнетдинова: «Мое детство в деревне прошло в окопах, блиндажах и дотах «Казанского обвода». В доте, что стоял на горе у нынешней д. Большое Фролово Буинского района, после войны расположилась пасека фролчан. Навел меня на нее отец. Ох, и вкусный был там мед! В окопах, что раскинулись в долине реки Свияга перед деревней Каеннык (Чирки-Дюртиле), мы ловили рыбу, заплывшую туда во время весеннего свияжского половодья... А мать, вышедшая из блокадного Ленинграда по «Дороге жизни» весной 1942-го, не успев окрепнуть, вышла на строительство рокадной железной дороги на Сталинград[1]. Она – 23-летняя девчушка, худющая после блокады, валила в апастовских и буинских лесах деревья под шпалы... Вспоминала, как в д. Чирки-Кильдуразы ночевали в одной избе с пленными немцами, которые строили железную дорогу. Вовсе не страшные были эти немцы. Местные жители их подкармливали…».

Мы гордимся этой героической страницей истории в жизни родного Буинского района и нашего края.

---

[1] Линия Свияжск–Ульяновск – часть Волжской рокады – железной дороги от станции Иловля (на правом берегу Волги в 80 км от Сталинграда) до станции Свияжск (30 км от Казани) через станции Саратов, Сызрань и Ульяновск. Волжская рокада общей протяжённостью 978 км была построена за 6 месяцев мая по октябрь 1942 г. в разгар Великой Отечественной войны. Она обеспечила эвакуацию населения и промышленного оборудования из Сталинграда, а затем успех Сталинградской битвы. Длина линии Свияжск–Ульяновск – 202 км.

# МИРАСЫБЫЗНЫҢ ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАГЫЛЫШЛЫСЫ

# НАШЕ ИСТОРИКО-КРАЕВЕДЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ

*Илсөяр Закирова*

## «ИДЕГӘЙ» ДАСТАНЫНЫҢ ГАБДУЛЛА ВАРИАНТЫ ТУРЫНДА

«Идегәй» дастанының татар вариантларын язып алу XIX йөз урталарыннан башлана. Хәзерге вакытта «Идегәй» дастанының 34 варианты мәгълүм. Алар арасында зур күләмле тулы сюжетлы әсәрләр дә, дастанның аерым мотивларын бәян иткән кыска күләмле, әмма тәмамланган сюжетлы текстлар да бар.

Дастан татар фольклористикасында да шактый өйрәнелгән. Әмма фәнни мәкаләләрдә нигездә берничә, төгәлрәге ике вариант тикшерелә. Алар – Нәкый Исәнбәтнең җыйналма варианты һәм Нигъмәт Хәким варианты. Бу мәкаләдә фәндә әлегә кадәр аз билгеле бер вариант белән таныштырырга телибез. Бу вариантның барлыгы беркемгә дә сер түгел, әмма ул озак еллар тикшерүчеләрнең игътибарыннан читтә калды.

«Идегәй» дастанының Габдулла варианты дигән текст Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә, ягъни Институтның архивында, 52 фондта саклана. Ул 23 битле дәфтәрдә гарәп графикасында язылган. Дастан традицияләренә туры килеп, чәчмә һәм тезмә өлешләре аралашып бара. Әмма тезмә текст өлеше зур түгел. Текст катнаш татар-төрек телендә язылган. Гарәп һәм фарсы алынмалары күп.

Текстның үз эчендә бу вариант турында шактый мәгълүмат теркәлгән.

Беренчедән, әлеге әсәрнең ата-бабалары сөйләп калдырган булуы, аның буыннан буынга күчеп саклануы күрсәтелә: «Ушбу риваять кала килгән бабаларымыздан бабаларымызга. Туктабай Гәрәй углы андин Сахип Туктабай углы андин Миңлебай Сахип углы. Мин Габдулла Әхмәҗан углы Акъегет кариясендә тугып үстем. Бабам Миңлебайдан яшь чакта тыңладым вә соңра гыйлем тәхсил[1] кыйлып кайттым. Бабам вафат улмыш иде. Мин бабадан калмыш нөсхәне хәреф би хәреф язып алдым. Һәм дә ятлап үз яшьтәшләремгә риваять кыйлып сөйләдем». Бу юллардан күренгәнчә, текстны башлап Акъегет кариясендә, ягъни Акъ-

[1] Тәхсил – гыйлем алу.

егет авылында яшәгән Миңлебай бабай беренче булып язмага күчергән. Вакыты билгеле түгел. Аннан калган кульязманы хәрефенә дә хилафлык китермичә аның оныгы – Габдулла күчерә. Габдулла Миңлебай бабайның улы Әхмәтҗанның баласы. Габдулла үзе дә Акъегет авылында туып үскән. Ул күчергән вакытын да күрсәтә. Бу – 1270 һиҗри ел. Шәвал 15, ягъни милади ел исәбенә күчерсәк, 1854 елның 10 июле. Шушында ук Акъегет авылын да ачыклап китәбез. Бу – хәзерге вакытта Зеленодольск районына караган авыл.

Акъегет авылыннан Габдулла Себергә китә. Китүенең сәбәбе билгеле түгел. Шулай да, аның турында олылап «моһаҗир Габдулла әфәнде» дип телгә алалар икән, аның Себердә дә ихтирамлы шәхес булганы күренә.

Дастанны 1897 елда «Тара өязе Саргат волсы Тартамак кариясе»ндә Миңлебай улы Гаффар күчереп яза. Тартамак авылы хәзерге көннәргә килеп җитмәгән, ул Омск өлкәсенә караган авыл һәм төп халкы Идел буеннан күчкән татарлар булган булырга мөмкин. Гаффар бабай да «хәреф би хәреф язып алмыш идем», дип, текстка үзгәрешләр кертмәвен күрсәтә. Шулай да ул дастанның башында Идегәй турында Идел буеннан килгән мөһаҗирләр сөйләвен ассызыклый: «Идел буеннан килгән мөһаҗирләр Идыгы Туктамыш ханның сәр[1] гаскәре Исмагел бин Сантимер углы идеген риваять идеюрләр». Ягъни, Идел буеннан килгән мөһаҗирләр дастанның кульязмасын гына сакламыйлар, бу турыда телдән дә сөйләгәннәр. Миңлебай улы Гаффар ул турыда болай дип яза: «Габдулла әфәнде ушбу риваятне ерак бабаларыннан мирас улуын сөйлидер һәм аның ушбу риваятькә гаид[2] шәҗәрәсе вар иде».

Гаффар бабайдан ул әсәрне Хафиз Рахматуллин 1917 елда язып ала. Хафиз Рахматуллин 1896 ел Омск өлкәсендә туып үскән, Себердә балалар укыта, 1921–1936 елларда, «Азат Себер» газетасы мөхәррире урынбасары була. Ул татар халык иҗаты белән кызыксына, Тубыл губернасының Тара өязе авылларында «Идегәй», «Атаклы кыз Тукбикә», «Тимер батыр», «Илдан белән Гөлдан» дастаннарының вариантларын язып ала. Хафиз Рахматуллин язып алган «Идегәй» дастанының өч варианты татар фольклористикасы өчен зур табыш булды. 1938 елда ул Казанга күчenә һәм Татарстан китап нәшриятында эшли башлый. 1940 елда үзе Себернең төрле өлкәләрендә туплаган фольклор материалларын Тел һәм әдәбият институтының фольклор секторына тапшыра.

Сезгә тәкъдим ителгән вариантның кыскача тарихы шушы.

[1] Сәр – башлык, баш кеше.

[2] Гаид – бәйләнешле.

# ИДЫГЫ



*«Идегәй» дастанының Габдулла вараинты. 1 нче бите.*

Идыгы Туктамыш ханга каршы мөнәсәбәттә шөһрәт казанмыш бер шәхестер. Идыгының кайсы әквамнан[1] вә кем баласы булуы хакында риваятьләр күптер. Идел буеннан килгән моһаҗирләр Идыгы Туктамыш ханның сәр[2] гаскәре Исмагел бин Сантимер углы идеген риваять идеюрләр. Исмагил бин Сантимер хәстәлеге сәбәбендин тәбдил[3] һава касды[4] илә Крымга варып шунда вафат итмештер. Аның гаиләсендә Кондызбикә намлы[5] хатыны вә Идыгы намлы углы калмыштыр. Моһаҗир Габдулла әфәнде риваятенә бинәен Идыгы сәр гаскәр Исмагил гаиләсендә 711 нче һиҗри ел тугмыштыр. Сәр гаскәр Исмагил вафат улганнан соң аның зәүҗе[6] Кондызбикә Туктамыш ханга кияүгә вармыштыр. Алты яшеннән Идыгы Туктамыш ханның гаиләсендә тәрбияләнмештер. Идыгының сабый вактыннан башлап икътидарлы[7] бер бала улганы хакында күп риваятьләр вардыр. Үзенең гакылы вә иктидарлы нәтиҗәсе уларак, ул Тукта-

[1] Әквам – кавем.
[2] Сәр – башлык, баш кеше.
[3] Тәбдил – үзгәртү, алмаштыру.
[4] Касд – уйлау, ният белән, максат.
[5] Нам – исем, ат.
[6] Зәүҗе – ир хатыны, хатын.
[7] Икътидарлы – көчле, куәтле, булдыра торган.

мыш ханга бик охшамыштыр. Идыгы сабый вакытыннан башлап хәрби уеннарга күңел куймыштыр. Балаларны әгъва кыйлып, хәрби уеннарга тартмыштыр. Аларга үзен сәр гаскәр улмыштыр. Мохарәбәләрдә[1] галип[2] уланнарын мактамыштыр. Шуның нәтиҗәсе уларак Туктамыш хан аны уникe яшькә килгәннән соңра хәрби һөнәр тәхсид[3] иттерү морады илә чит вилаяткә күндермештер. Һәм Идыгының Госмания вилаятендә булдыгы хакында риваять идәюрләр. Идыгы тиз арада шәҗәгатле[4] сәр гаскәр була.

729 нчы һижри елда Тимерлан илә улган бер мохарәбәдә бер уч гаскәр илә Тимерланның (Аксактимер) гаскәрләрен тар-мар идәрәк берничә шәһәрен забыт[5] итмештер һәм словяннар эквамы илән улган мохарәбәдә Идыгының гаять тә зур шәҗагать күрсәткәнлеген риваять идәюрләр. Ләкин Туктамыш ханның ханлык вактында дахли фетнә вә фәсәдләр күбәя. Алтын Урда дәүләте хәдердени[6] гакыллара сыгмаз дәрәҗәдә тәүсыйг[7] иткән Туктамыш хан үзенең дахле сәясәте илә дәүләте инкираз капкасына алып вара. Аның хакында шуйлә назым вар:

Алтын Урда дәүләтендә
Туктамыш намлы хан булды:
Дәүләтләри забыт итте
Әлеф би әлеф гаскәр җыйды.
Күп вилаят забыт итте,
Әлеф би әлеф әсир төште.
Маэсур[8] улан кавымнары
Дәлил итте, нәсех итте.

Туктамыш хан фәүкылгадә[9] күп гаскәр сакламыштыр. Анлари азык илә тәэмин итү чарасы уларак, дахли ригатләреннән[10] агыр салымнар алмыштыр.

Тимерлан гаскәрендә улан бер гарәп Туктамышның чит эквамләрә улан могалләмәсе хакында шуйлә риваят идәюр:

و وصـل او البـــائس سـلم يقـال لمزان الأجل فســاعة لا لـو
ألـف ألـف بـــألف اعنـف و المغبـــون صـــفقة الـوداد اهل عليـه يصـــفق
بهـا يزيـــدون او طوقتـــامش بأيـــدي هالك

[1] Мохарәсә – сугыш, яу.
[2] Галиб – җиңүче, көрәштә өстенлек алучы.
[3] Тәхсид – тәхсил – белем алу.
[4] Шәҗәгать – батырлык, гайрәт.
[5] Забыт – забит – басып алу, буйсындыру, сугышып алу.
[6] Хәдердени - һәдер – 1. кан үче алу, 2. әрәм итү, югалту
[7] Тәүсигъ – киңәйтү, арттыру, җәелдерү.
[8] Маэсур – мәэсүр – тоткын, әсир.
[9] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[10] Ригат – ригаять – кайгырту, карау.

Ягъни: «иштә әҗәл вакты якын улса иде, Туктамыш тарафыннан һәлак иделмеш ун мең җөмләсендә бән дә үләчәк идем».

Туктамыш ханның шуйлә дахли сәясәте эквамлара охшамамыштыр. Шуны бинаән вилаяттә ихтилал[1] башланмыштыр. Шәҗагәтле[2] вә акылга малик улан Идыгы Туктамыш ханның вилаятне инкыйраз[3] алып баруын алдан күрмештер. Ул ихтилалчылар тарафыннан булып, гаскәрләр арасында Туктамыш ханга мохалиф[4] әгъва йөртмештер. Ригаятләрдән гади кимсәләр илә мосахәбә[5] кыйлып, анларның кәсепкарлареннән, хәл-әхвалләреннән сорашып, тәкәллефсез вә халис[6] уларак сөйләшеп тормыштыр. Ошбу сәбәптән Идыгыга халыклар мәхәббәт вә һәр йирдә аны мәдех[7] кыймышлардыр. Туктамыш ханга бу хәл охшамамыштыр. Ул Идыгыны күздән төшерер өчен сәбәпләр изләргә керешмештер. Ахырында бер бәһанә[8] табып Идыгыны камчы илә суктырмыштыр. Ушбу хәрәкәт вә мәсхәрәләр Идыгыга дәрес вирмештер. Туктамыш ханнан интикам[9] алмак касды илә Идыгы үзенә тарафдарлар пәйда кыйлырга мәҗбүр улмыштыр. Туктамыш ханың гәскәрләре вә әсирләр һәм коллар арасыннан үзенә күп тарафдарлар тупламыштыр. Идыгыга хәбәр вирмешләрдер. Туктамыш ханның тарафдарлары ошбу хәлдән Идыгыга хәбәр вирмешләрдер. Туктамыш ханның сарай әһелләреннән дә Идыгы тарафдарлар күп улмыштыр. Җарияләр дә аңа мәхәббәт кыйлмышлар. Словян каумыннан улан бер җария ушбуча Идыгы хакында назым әйтүен риваят кыйлалар:

Роскошь хана не манит меня,
В любви Идиги жажду всегда...

Идыгы озын буйлы, монтасип[10] әгъзалы, зур вә үткен күзле, гүзәл йөзле, гаять көр тавышлы бер шәхес улмыштыр. 732 нче һиҗри елда Туктамыш ханның гаскәрләренең бер кыйсме[11] ханга мохалиф[12] ихтимал башламышлар. Идыгы ушбу ихтилалга башчы уладыр. Ихтилалга күп санлы әсирләр вә коллар катнаша. Пайтәхет шәһәр мохарәбә[13] мәйда-

---

[1] Ихтилал – ихтиляль – баш күтәрү, фетнә.
[2] Шәҗагать – батыр, гайрәтле.
[3] Инкыйраз – бетү, юкка чыгу.
[4] Мохалиф – каршы, охшашмаган.
[5] Мосахәбә – кара-каршы сөйләшеп утыру.
[6] Халис – саф, чын.
[7] Мәдех – мактау, шәплеген сөйләү.
[8] Бәһанә – сылтау, сәбәп.
[9] Интикам – үч алу, үч кайтару.
[10] Монтасип – монтәсыйф – уртача.
[11] Кыйсем – өлеш, бүлек.
[12] Мохалиф – каршы килә торган, охшашмаган.
[13] Мохарәбә – зур сугыш, яу.

нына әверелә. Ярым көн дәвам иткән мохарәбәдән соң Идыгы Пайтәхет шәһәрен ташлап чыкмыштыр. Алар Идел суын кичү ичөн күп чаралар күрмешләрдер. Ихтилалчыларның бер кыйсме суны кичү ичен чалышсалар[1], бер кыйсме каһарманә[2] рәвештә хан гаскәренә мохалиф мохарәбә әйләмештер. Ушбу мохарәбәдә Идыгының күрсәтмеш шәҗагәтенә[3] ихтилалчылар хәйран калмышлардыр. Бер уч гаскәр илә ханның гаскәрләрен маглүп[4] улып качырга мәҗбүр итмештер. Ихтилалчылар Идел суын кичеп беткәндә хан тарафыннан күндерелгән дәхи алтмыш мең гаскәр килмештер. Идел суын кичкән ихтилалчыларның саны биш мең микдары улганын риваят идәюрләр.

Хан тарафыннан килмеш гаскәрләрнең сәр гаскәре Кыпчак намлы шәхес улдыгы күрсәтелә. Идел аркылы Кыпчак аваз вирмештер:

Ай калкып акрын туадыр,
Ир егет ярда үләдер;
Яудан качкан ир булмыйдыр,
Ил алдында көн күрмидәр!
Егет булып яу башладың,
Башладың да ник ташладың.
Куяндаен бөркет куган,
Идел суын кичеп качтың!

Идыгы аваз вирмештер:

Ай калкып акрын туадыр,
Ир егет яуны куадыр;
Ир булсаң суны үткел,
Суны үтеп мине тоткыл!

Кыпчак аваз вирмештер:

Көчле илгә син яу ачтың,
Батыр булып алга бастың;
Батырлыгың күзтәр мордар,
Суны үтеп нигә качтың!
Идыгы аваз виргән:
Таймам баскан юлыннан,
Салмам сөңге кулымнан;
Салмам калкан иңемнән,

[1] Чалышу – эшләү, тырышу.
[2] Каһәрманә – батырларча, каһарманнарча.
[3] Шәҗәгать – батырлык, гайрәт.
[4] Маглүп – мәгълүб – җиңелгән, аста калган.

Яу йиярмын илемнән.
Яуга тиңдәш яу йисам,
Идел суын кичәрмен;
Кем батыр вә куян,
Шул вакытта ил күрер!

Идел аркылы улан мохатаба[1] лардан соңра ике арада мохарәбә башланмыштыр. Туктамыш хан гаскәрләре Идел суын кичмәгә бик зур көч сарыф итмешләрдер. Саллар ясатып Идел суын кичмәгә түккән көчләре нәтиҗәсез калмыштыр. Бик күп саллары вә гаскәрләре ихтилалчылар тарафыннан тәхрип[2] ителмештер. Идел суында улан мохарәбәдән соңра Идыгының словян әквамнары хөкем сөргән вилаяткә варганын риваят идеюрләр. Вә аның Анисим намлы словян ихтилалчысы илә берлектә кушылып юл басучылык илә мәшгуль улуын вә шул сәбәптән сәүдә юлларның киселүен, сәүдә карваннарның тукталуын сүләюрләр. Туктамыш вә Мәскау вилаятләреннән качмыш бик күп әсирләр вә коллар бу ике фетнәчеләр кул астына йиылып дәһшәтле бер фирка улганын, фәсадчылар саны кырык мең микъдары улуы сөйләнмештер.

Идыгы вә Анисим арасында түбәндәге могаһәдә[3] улмыштыр:

1) Мөселман кавымы илә словян кавымы арасында улан мохалифәтләр[4] бетеп ушбу ике фирка бер беринә якын улачаклар.

2) Һәр ике фирка хан вә патшага каршы улан мохарәбәләрдә бергә чалышмакта улачаклар.

3) Хан вә патшаның пайтәхетләрен забыт иткәннән соңра гаделлек илә бүленеп бер фирка илә икенче фирка арасында мохаләфәтләрә[5] юл куелмас.

4) Хан һәм патша мохарәбәләре вактында әсир төшкән әсирләрне кайтармаска.

5) Риваятләрдән хан вә патша тарафыннан алына торган төрле салымнарны бетереп, харикҗи[6] һәм дахле[7] ихтыяҗларны ябар һәм микътар бер төрле салым алмаска.

6) Ихтилалы мохарәбәне Алтын Урдага һөҗүмнән башларга.

Ихтилалчылар әһали исә бу шартларны кабул илтмешләр вә гаһед[8] кәгазе язып мөһерләре илә таэкид[9] итмешләр. Мөселман вә словян кавым-

---

[1] Мохатаба – кара-каршы сөйләшү, бер-беренә эндәшү.
[2] Тәхрип – тәхриб – хәрап итү, җимерү, бозу.
[3] Могаһәдә – сүз бирешү, договор, килешү.
[4] Мохалифәт – мохалиф, мохаләфәт – каршы, каршы булу, оппозиция.
[5] Мохаләфәт – каршы, каршы булу, оппозиция.
[6] Харикҗи – тышкы эшкә караган.
[7] Дахле – дәхел – эчке.
[8] Гаһед – килешү, договор.
[9] Таэкид – раслау, куәтләү, ныгыту.

нары дуслыгына каршы өч кемсә наризалык[1] күстәреп сүз сөйләргә керешмеш исә дә Идыгы әмре илә шул дәкыйкадә[2] башлары киселмештер.

Идыгы һәм Анисам ике кавымнан олуг гаскәр тәртип идеп Алтын Урда мәмләкәтенә каршы сәфәр кыйлмышлар. Күп шәһәр вә карияләрне забыт итмешләр. Туктамыш хан ихтилалчыларга каршы углы Мәрдал сәр гаскәрлеге астында илле мең гаскәр күндермештер. Биш тәүлек дәвам иткән канлы мохарәбәдән соңра Мәрдал гаскәрләрне чигенмәгә мәҗбүр улмышлардыр. 733 нче һиҗри елның җәендә улан бу мохарәбәнең иң канлы мохарәбәдән улмышы телләрдә сүләнмештер.

Ошбу мохарәбәдә мозаффият[3] казанганнан соңра Туктамыш хан идарәсендә нарази[4] фиркаләрдән тәбриэ[5] илчеләре килмештер. Идыгы тарафдарлары күбәеп ихтилалчылар саны алтмыш меңнән артмыштыр. Шул ук сәнәдә улан бер мохарәбәдә Туктамыш ханның йөз мең гаскәре маглүп[6] улып чигенмештер. Ушбу вакыйгадән соңра Туктамыш хан гасби[7] хәстәлек илә мобталә[8] улып урынсыз йирдә ачыгланырга, юк сәбәпләр илә сүэзан[9] кыйлырга, вә сүэзан кыйлмыш адәмләрини катил иттерергә керешмештер. Идыгының анасы Кондызбикәне шуйлә сүэзан нәтиҗәсе уларак катил иттермештер.

Идыгының шуйлә мозаффарияте Алтын Урда мәмләкәтен гауга астына куймыштыр. Галимнәр арасында җәдал[10] вә моназара[11] башланмыштыр. Бер фирка галимнәр ушбу фәсаднең[12] сәбәбен Туктамыш ханның дахли сәясәтеннән эзләсәләр, икенче фирка галимнәр моның сәбәбен словян кавымнары коткысыннан эзләерләр. Ушбу җәдал вә моназараларның нәтиҗәсе уларак Туктамыш хан тарафыннан мосавәрә[13] мәҗлес чакырылды. Күп мәзакәрә[14] вә моназаралардан соңра Сафардау намлы галим: Бу фәсад ислама мохалиф[15] фәсад улдыгыннан Идыгыны дин дошманы диярәк игълан итәргә, ислам ханнары ихтилалны бастыру вә

---

[1] Наризалык – наразыйлык – разый булмаулык, риза булмаучылык.
[2] Дәкыйкә – минут, өлеш, кисәк.
[3] Мозаффият – өстенлек, теләккә ирешү.
[4] Нарази – разый булмау.
[5] Тәбриэ – тәбрия – аклану, котылу, ераклашу.
[6] Маглүп – мәгълүб – җиңелгән, аста калган.
[7] Гасабә – нерв җебе, гасби хәстәлек – нерв авыруы.
[8] Мобталә – мөбталя – дучар булу, бәхетсезлеккә эләгү.
[9] Сүэзан – начар фикер, начар уй тудыру.
[10] Җәдал – бәхәс, сүз көрәштерү.
[11] Моназара – моназәрә – сүз көрәштерү, бәхәс.
[12] Фәсад – бозык, бозыклык, азу, әшәке эш.
[13] Мосавәрә – ?
[14] Мәзакәрә – мөзакәрә – киңәш; фикер алышу.
[15] Мохалиф – каршы, каршы килә торган.

фәсадчыларны хибес[1] кыйлу ичән үз араларында улан мохалифәтләрне бетереп, бер беринә ярдәм кыйлуны ушбу чараларны хәл кыйлу ичен Тимерлан ханга (Аксактимер) илчеләр күндереп мосалиха[2] тәкъдим кыйлуны таләп кыйлмышлар.

Мосаварә мәҗлисендә улан галимнәр Сафардау тәкъдимен якламышлар. Шуйлә мәзакәрәләрдән соңра Туктамыш хан Тимерланга илчеләр күндерилмештер. Соңра Тимерланнан түбәндәге маузугта[3] шартнамә алынмыштыр:

1. Арада улан мохалифәтләне бетереп, ике мәмләкәт гаскәрләрен ихтилачыларга каршы күндерергә разый булырга.

2. Ихтилалчыларга каршы улан мохарәбә ичән сарыф итмәгә тиеш улан чарәләр Алтын Урда дәүләте тарафыннан тагаен кыйлынырга.

3. Мохарәбә вактында сәр гаскәр һәр ике мәмләкәт гаскәренә мәнем[4].

4. Ихтилалчылар маглүп һәм тар-мар кыйлынганнан соңра ике мәмләкәтнең хәрби куәтләрен туплап, Мәскәү, словян хөкүмәтләрен тар-мар кыйлырга.

5. Мәскәү, словян хөкүмәтләрен табиг[5] кыйлганнан соңра Алтын Урда тәхет торасын Мәскәүгә күчерергә һәм Алтын Урда ригаятләрен һәммәсендә һиҗрәт6 вә табиг эквамнарның өчтән ике өлешен шул мәмләкәткә һиҗрәт кыйлып, Идел нәһринең сул тарафын мәнем идарәмә йир, кол һәм эквамнары илә тапшырырга, ике мәмләкәт арасында ходуд[7] улар Ак Идел нәһрен билгеләргә.

6. Шуйлә ясалган мосалихә гамәлгә наил[8] улсын ичен даими уларак мәнем тарафтан Алтын Урда мәмләкәте тәхет торасында йөз илле мең микъдар гаскәр тәшкил кыйлынсын.

Туктамыш илә Тимерлан арасында улан бик күп мосахәбәләрлән соңра ике дәүләт арасында гаһетнамә[9] төзелмештер. Идыгы ушбу гаһетнамәдән хәбәрдар улып, Туктамыш ханның Тәхет торасын забыт кыйлыр ичен чалышмыштыр.

736 һиҗри елында яңадан ике арада мохарәбә башланмыштыр. Ундүрт тәүлек дәвам иткән мохарәбәләрдән соңра Идыгы гаскәре Тукта-

---

[1] Хибес – тоткынлык, кулга алу.

[2] Мосалиха – мосаләхә – ике хөкүмәт арасындагы килешү, дауны бетерү.

[3] Маузуг – мәүзугъ – 1.тема, проблема. 2. куелган, урнаштырылган.

[4] Мәнем – ?

[5] Табиг – буйсындыру.

[6] Һиҗрәт – бер урыннан икенче урынга күчү, күчеп китү; төпләнеп яшәр өчен башка урынга китү; эмиграция.

[7] Ходуд – хәд – чик, үтмәскә тиешле нокта.

[8] Наил – ирешә торган, ирешә алган; ирешүче.

[9] Гаһетнамә – договор, килешү, вәгъдә язуы.

мыш хан гаскәрләренә галип[1] улып, Тәхет торага сәфәр кыйлмыштыр вә һичбер каршулыкка очрамадигы хәлдә Тәхет торага 25 мил[2] кадәр якыйн килмештер. Ушбу вакыйгадән соңра Туктамыш хан гаять дәрәҗәдә куркуга калып, нә кыйларын белмәмештер. Шуйлә хәвефләнеп йөргән вактында Сарай диварында түбәндәге мәүзугта намә күрмештер:

Ташла, атма арысланга агач укны,
Калып булмай әҗәл килгәч кысып тешне.
Чалышмагыл чыгып мәйданга сер бирми,
Арысланга куян мәйданда тиң булмый!

Сарай ригаятләреннән сүэзан кыйларак Туктамыш хан гаиләсе илә чит мәмләкәтә качарга мәҗбүр улмыштыр. Ушбу хәллрдән соңра ихтилалчылар тәхет тораны забыт итмешләдер. Хәл шуйлә уларак Туктамыш илә Тимерлан арасында улан гаһет гамәлгә наил улмамыштыр.

Тәхет тораны забыт иттектән соңра Идыгы вә тора аһаленә[3] мәмләкәтнең сәяси вә икътисадый хәлләреннән бәлыйг[4] вә хотбә[5] сөйләмештер. Вә соңра түбәндәге идарә намәне ригаятләрә игълан кыйлмыштыр.

1. Мәмләкәтне идарә идәргә моктадир[6], җәсүр[7], кабилиятле[8], гадел бер кемсә ригаятнең гомуми мәҗлесе тарафыннан сайланыр.

2. Ушбу шәхси мәмләкәт идарәсен башкару сәяси вә икътисади канунлар чыгаруда ригаять мәҗлесе күндергән вәкилләр илә мосавәрәдә уларак эшен кыйлыр.

3. Тәхет мирас улу канунын юкка чыгарырга идарәгә сәлахиятсез[9] улан шәхесне ибдал[10] итүгә ригаят мәҗлесе хакы улуын танырга.

4. Хан хакимияте вактында алына торган күп төрле салымнарны бетерергә, дәүләт ихтыяҗларын ябар кадәрле бер төрле вакыт салым билгеләргә.

5. Гаскәри улан адәмнәрнең гаиләләрен салымнан азат кыйлырга.

6. Ушбу көнгә кадәр мохалифәттә[11] улан хөкүмәтләргә мосалихә ясау тугрында морәҗәгать кыйлырга, солыхларның виргүсез улмагын таләп кыйлырга.

---

[1] Галиб – җиңүче, өстенлек алучы.
[2] Мил – озынлык үлчәү берәмлеге, 1870 метр.
[3] Аһәл – әһел – кеше, халык
[4] Бәлыйг – матур, төзек, тулы мәгънәле итеп.
[5] Хотбә – нотык, сөйләнгән сүз.
[6] Моктадир – могтәд сүзеннән, санала торган, хөрмәтле.
[7] Җәсүр – батыр, гайрәтле.
[8] Кабилият – 1. сәләтлелек, булдыклылык, кулдан килү. 2. аңлый алу сәләте.
[9] Сәлахиятсез – сәляхиятсез – сәләтсез, булдыксыз.
[10] Ибдал – алмаштыру.
[11] Мохалифәт – каршылык.

7. Мәмләкәткә хыянәт кыйлгучы шәхесләргә үлем җәзасы улачагын танырга.

8. Шәхесләрнең ихтыярын ибдал итәрәк, коллар, кәнизәкләр илә сәүдәне мәныйг[1] кыйлырга.

Туктамыш хан идарәсендә улан ригаятләр ушбу идарә намәя мәмнүн улмышлардыр. Һәм дә Идыгының дәүләт идарәсенә галиҗәнап итәрәк сайламышлардыр. Алтын Урда дәүләте Идыгы идарәсенә күчкәннән соңра үзара улан дахле низаглар бетмештер. Вә Идыгы монтазим[2] гаскәр тәртип итмәя керешмештер. Сәр гаскәр итәрәк ике кимсәне билгеләмештер. Үзенә рәкыйп[3] улан Анисимны вә атасының туган кардәшләреннән улан Янбай намлы шәхесне.

Ушбу Янбай намлы шәхес Идыгының тар[4] атасы улуын, вә Туктамыш хан Идыгы анасы Кондызбикә мил[5] кыйлып, Янбайны катил иттерү куркынычы улганлыктан Тәхет торада улан Идыгы тарафларында яшеренеп торганын риваять идәюрләр. Һәм дә Идыгы Туктамыш Тәхет торасын забыт иттектән соңра Идыгы илә Янбайның Кондызбикә кабре өстендә назымнар әйтеп кайгырулары моны раслыйдыр.

Идыгы мохалифәттә улан мәмләкәтләргә шуйлә мәндәрәҗле[6] намә илә моражәгать кыйлмыштыр:

1. Мәмләкәтләр арасында улан мохалифәтләрне бетереп мосалиха турында мозакәрә башламага.

2. Һәр ике мәмләкәттә улан әсирләр азат кыйлынып, үз утаннарына[7] кайтарулыр.

3. Мохалифәтләре сәбәп улан ходуд[8] мәсьәләсе һәр ике мәмләкәт вәкилләре тарафыннан хәл кыйлынып чикләр нашанәләр[9] илә һәм дә намәләр илә таэкит[10] кыйлыныр.

4. Һәр ике дәүләт хөкемдарлары хозурында даими вәкилләр улыныр.

5. Ушбу вакытлара кадәр улан мохарәбәләрдә әсир улынып, аерым шәхесләрә кол вә кәнизәк итәрәк сатылмыш кемсәләр беделсе[11] котка-

---

[1] Мәныйг – манигъ – тыю, тоткарлау.

[2] Монтазим – ?

[3] Рәкыйп – рәкыйб – конкурент, эштә башкалардан өстен булырга теләүче.

[4] Тар – ?

[5] Мил – ?

[6] Мәндәрәҗ – мөндәриҗ – арага кертелгән, теркәлгән.

[7] Утан – ватан.

[8] Ходуд – хәд – чик, үтмәскә тиешле нокта.

[9] Нашанә – нишан – билге, тамга, эз.

[10] Таэкит – тәэкид – раслау, ныгыту.

[11] Беделсе – бәдәл – бәя, хак, алмаштыру бәясе.

рылыр һәм дә үз утаннарына кайтарылыр. Ушбу максатка наил улу ичен һәм ике дәүләт хәзинәләреннән сәрмая[1] сарый кыйлыр.

6. Мәмләкәт идарәсендә улан гадәләтсезлекләр[2] һәм дә хуҗалары тарафыннан улмыш гадәләтсезлекләрә разый улмай бер мәмләкәттән икенче мәмләкәткә качмыш шәхесләр һәм дә коллар вә кәнизәкләрне кайтару таләп кыйлынмас. Ушбу кемсәләр үз ихтыярлары илә шул мәмләкәт шәхесләре ула калырга хаклы.

Мосалихәдән баш тартып тәҗавез[3] башламыш мәмләкәт мәглүп[4] улса, галип[5] улан мосалихә тарафдары мәмләкәт, маглүп улан мәмләкәттән авыр виргү алмага хаклы, тәҗавез башламыш мәмләкәтнең хакимдарлары катил улыныр.

Ушбу намә Мәскәү һәм Тимерлан ханга күндерелмештер.

Мәскәү патшасы һәм Тимерлан хан ушбу намәдә күстәрелмеш шартларны кабул кыйлудан баш тартмышлардыр.

739 һиҗри ел Мәскәү патшасы Алтын Урда мәмләкәтен забыт кыйлу максады илә күп санлы гаскәр илә тәҗавез башламыш исә дә максудына наил улмамыштыр. Идыгы, Анисим һәм Янбай сәр гаскәр уларак өч тарафтан һөҗүм кыйлып Мәскәү гаскәрләрен тар-мар итәрәк, качарга мәҗбүр кыйлмышлардыр. Һәм дә Мәскәүгә кадәр урыс-славян гаскәрләрен эзәрлекләп варып урыс-славян патшасы кыримелен[6] мохазарә кыйлмышлардыр. Ләкин Туктамыш хан тәҗавезе вактында сәламәт калмыш кыримел ушбу кәрәдә[7] сәламәт калмыштыр. Сәбәп: кырималга ябылмыш урыс-словян гаскәрләре гаять көчле мохалифәт[8] күрсәтсәләр, икенче сәбәп Идыгының урыс-словян әквамлары илә мохарәбәсеннән[9] файдаланып Тимерланның Алтын Урдага тәҗавез башлавында улмыштыр. Мәскәү кыримелен мохазара[10] вактында күп еллар Идыгыга рәкыйп улан Анисим авыр җәрәхәтләнеп вафат улмыштыр вә аның Заря намлы гүзәл зәүҗәсе[11] Идыгы илә Алтын Урдага кайта юнәлмештер. Ушбу хатынга Идыгының җефетләнүен риваят идәюрләр һәм аңа Сара дип ләкап[12] кушмышлардыр.

---

[1] Сәрмая – акча, бәя.

[2] Гадәләтсезлек – гаделлексезлек.

[3] Тәҗавез – гаепне (хатаны) кичерү, гафу итү. 2) Узу, чиктән үтү. 3) Басып керү.

[4] Мәглүп –җүңелү.

[5] Галип – җиңүче.

[6] Кыримел – кремль.

[7] Кәрә – кәррә – мәртәбә, тапкыр

[8] Мохалифәт – каршылык.

[9] Мохарәбә – сугыш, яу.

[10] Мохазара – ?

[11] Зәүҗә – хатын, кәләш, ир хатыны.

[12] Ләкап – кушамат, бу очракта исем.

Идыгы Алтын Урдага кайтмыш вә дәхи бөек гаскәр тәшкил кыйларак, Янбай командасы астында Тимерланга каршы гаскәр күндермештер. Вә ике мохалиф[1] гаскәрләр Җаек суы буенча очрашмышлар. Ике тәүлек дәвам иткән каты мохарәбәдән соңра Тимерлан гаскәрләре чигенергә мәҗбүр улмышлардыр. Ушбу маглүбияттән[2] соңра Тимерлан 150 мең микъдар гаскәр илә үзе килмештер һәм дә Янбай командасы астында улан Идыгы гаскәрләрен чигенергә мәҗбүр кыйлмышлардыр. Ушбу вакыйганы ишетү илә, Идыгы 170 мең микъдар гаскәр илә үзе сәфәр кыйлмыштыр. Бу сәфәрендә Идыгы гаять зур каһарманлык илә Тимерланга каршы мохарәбә кыйла вә Шәрык мәмләкәтләренең бөтен әтрафына аның даны тарала. Арал дәрьясы буйларын забыт идә һәм дә ушбу вакытта Амудәрья аталмыш нәһер буйлап Тимерланның Тәхет торасы улан Сәмәркандга сәфәр кыйла. Бу мохарәбәләрдә аның күстәрмеш каһарманлыгын шуйлә риваять кыйлу ядкаре калмыштыр.

Кереп чиреккә уйнай башлады ул,
Кырып ашлык башактай ташлады ул.
Гаһи[3] уңга, гаһи сулга чыгадыр,
Чирекләр сөрлегеп аннан качадыр.
Тәне аның тимердер сөңге батмас,
Каны мез[4] парәседер утта янмас.

Идыгы Амудәрья аталган нәһерне дә кичә. Ләкин моннан соңра ул таҗавезен дәвам кыйла алмамыштыр. Лутва[5] мәмләкәтенә атасы илә качмыш Мәрдар билдермәксезин Идыгы гаскәре сафына сыгынмыштыр. Идыгы ойкуга китмеш вакытны ул агулы пычак илә Идыгыны чәнешмештер. Идыгы авыр җәрәхәтләнмештер. Мәрдарны катил кыйлмышлар исә дә Идыгы ушбу җәрахәттән вафат улмыштыр. Идыгының 711 нче һиҗри ел тугып 746 нчы һиҗри ел, 36 яшендә вафат улдыгын риваять идәюрләр. Идыгы үлем алдында булганы хәлдә гаскәренә васыятен калдырмыш.

1. Мәмләкәтне идарәя иктидарлы[6] шәхесне сайларга.
2. Ригаятләрә лазым улан гадәләтне[7] сакларга.
3. Шәхесләрә имтиязга8 юл кулмай коллара вә кәнизәкләр илә сауда кыйлдырмаска.

---

[1] Мохалиф – каршы, дошман.
[2] Маглүбият – мәгълүбият – җиңелү.
[3] Гаһи – гяһи – әле.
[4] Мез – ?
[5] Лутва – Литва.
[6] Иктидар – икътидар – 1) кулдан килү, булдыра алу, көч җитү. 2) Көч, куәт.
[7] Гадәләт – гаделлек.
[8] Имтияз – өстенлек, өстен хокук, привилегия.

4. Мохарәбәләр вактында әсир төшкән адәмләри катил кыйлуны мәныйг[1] кыйлырга, кол вә кәнизәкләрне сатмаска, дәүләткә мәнфагатьле эшләрдә кулланырга.

Мәмләкәт идарәсенә галиҗанәплыкка кемне сайларга дия сорадыкларында, хәзерге Сарәне диярәк җавап вирмештер.

Туктамыш ханның Тәхет торасын забыт кыйлуга кадәр Идыгы Алтын Урда Тәхет торасыннан ерак бер йирдә Идел нәһренең югары агумында ихтилалчылар илә кормыш Тәхет торасы улуын риваять идәюрләр. Идыгы Тәхет торасы шәһәре Болгардан утыз-кырык чакрым мосафәдә[2] Идел нәһренең икенче тарафында Сембер өязе Олуг Тархан кариясе улан йирдә улдыгын зан[3] идәюрләр. Йир тетрәтеп һәйҗан[4] казанмыш бер шәхеснең Тәхет торасына Олуг Тархан торасы диярәк атау гаҗәп имәстер.

Идыгы вакыйгасыннан соңра Алтын Урда инкыйраза юл тотмыштыр. Үз араларында улан низаглар нәтиҗәсе уларак Крым, Астрахан, Казан ханлыклары тәшкил улмыштыр.

Ушбу риваятнең мафһүмен[5] 1897 нче сәнәдә моһаҗир Габдулла әфәнде нөсхәсеннән хәреф би хәреф язып алмыш идем. Габдулла әфәнде ушбу риваятне ерак бабаларыннан мирас улуын сөйлидер һәм аның ушбу риваятькә гаид[6] шәҗәрәсе вар иде.

Габдулла әфәнде туган вә үскән илен сагынып риваятен түбәндәге маузугта[7] улан назым илә башлый иде.

Башлаймын сүзне туган илемнән,
Идел буенда күргән көнемнән.
Идел буенда тугып үстем мин,
Аның суыннан бик күп кичтем мин.
Без яшь чакларда авыл картлары
Идел ярына йиылалар иде.
Башларын иеп, билләрен бүгеп,
Иделгә карап ерлайлар иде:

Идел!
Буең ямьле,
Суың тәмле,
Тәмле суың эчкән чакта,

---

[1] Мәныйг – манигъ – киртә, каршылык.
[2] Мосафә – ара, ераклык.
[3] Зан – ачык булмаган, якынча гына уй.
[4] Һәйҗан – дулкынлану, борчылу, шатлану.
[5] Мафһүм – мәфһүм – эчтәлек.
[6] Гаид – бәйләнешле.
[7] Маузуг – мәүзүг – тема.

Янган йөрәк ял ала,
Авыр нужа үткән төсле,
Кайгы, хәсрәт тарала.
И Идел син генә,
Шәфкатьле әнкәмез генә!

Минем бабам Миңлебай
Бик күп риваять
Сөйләйдер иде.
Үткән заманда Идел буенда,
Безгә кадәрле ниләр булганын.
Бик күп ханнарның ,
Бик күп байларның,
Колларны биләп,
Әсир сөргәнен.
Халыкны талап,
Күз яшьләр коеп,
Идел буенда байлык йиганын.
Явыз кара көч, туган илемнән
Ерак Себергә мине аерды.
Бабам сөйләгән бик күп риваять,
Минем күңлемдә мәңгегә калды.
Сөйләймен сезгә бабам мирасын
Идыгы аталган батыр кыйссасын, –
диярәк риваять башлайдыр иде.

Шәҗәрәдә түбәндәәге сүзләр вар:

Ушбу риваять кала килгән бабаларымыздан бабаларымызга. Туктабай Гәрәй углы андин Сахип Туктабай углы андин Миңлебай Сахип углы. Мин Габдулла Әхмәҗан углы Акъегет кариясендә тугып үстем. Бабам Миңлебайдан яшь чакта тыңладым вә соңра гыйлем тәхсил[1] кыйлып кайттым. Бабам вафат улмыш иде. Мин бабадан калмыш нөсхәне хәреф би хәреф язып алдым. Һәм дә ятлап үз яшьтәшләремгә риваять кыйлып сөйләдем.

1270 һиҗри ел. Шәвал 15. Акъегет.

Габдулла әфәнденең носхәсеннән күчереп язгучы Гаффар Миңлебай углы. Тара өязе, Саргат волсы, Тартамак кариясе.

Гаффар бабайдан яздым Х. Рахматуллин. 1917 ел.

[1] Тәхсил – гыйлем алу.

## БАБАБЫЗНЫҢ ДӘФТӘРЕ

(*Дәвамы. Башын укыгыз № 1, 2, 2025*)

Без ник ашыгыб кайтдык? Манжуриадан безнең пулкга дингез берлән кайтырга кирәк иде. Ул вакыт күб җирләр күрергә була иде. Әгәр дә без су берлән кайтганны көтсәк, безгә тагы 6 ай Манжуриада торырга кирәк иде. Бу бер сәбәб, икенче сәбәб – Мөхәммәдша Камали углы хатынын сагынган иде. Сөнгатулла Гайнулла углының үләнәсе бар: аның сүгән кызы Гыйнаүвәл Камали кызы көтә иде. Минем йапун сугышына киткәч хатын үлгән иде. Үләнәсе бар. Тизрәк кайтыб үләнергә кирәк иде. Менә шуның өчен без бик ашыкдык.

Без кайтыб өйдә бераз торгач үләнергә диб уйланыб йөрсәм дә, этинең үләндерәсе килмәгәнен сизә идем. Чөнки аның бераз акчасы булса да, үзенә шәһәргә төлке эчле толыб тектрергә хәзерләнгән булган. Ул шәһәргә барганчы мин дә кайтыб килдем. Менә бу көнләр минем өчен күңелсезрәк иде. Бер ун көн үткәч эти толыб тектерүен куеб мине өйләндерергә уйлаганы башлаганы сизелде. Бер көн көндез сәгать 11ләрдә безгә бик сирәк килә торган Хирали исемле кешенең хатыны килеб әнигә: «Әгәр дә сорасагыз, Микнәбикә абыстайлар кызларын бирергә ниәте бар» диб сүйләб киткән. Менә шул көн кич эти миңа: «Мин сине үләндерергә уйланам, кем кызын алыйк?» диде. Мин анарга: «Теләсәгез кем кызын алыгыз, мин кыз сайламыйм» дидем. Шунар каршы эти: «Үзебезнең Гарифулла кызын сорасак ничек булыр икән?» диде. Мин дә: «Бик йахшы булыр» дидем. Эти: «Алай булса, мин иртәгә менеб карыйм» диде. Йарый, иртәгәсен эти Гарифулла бабайларга барыб кыз килешеб тә кайтды. Шундан соң туйлар булыб бездә Бибинәфисә Гарифулла кызын алыб кайтдым. Менә инде кайтуның куанычы шул иде.

Сөнгатулла Гыйнаүвәлне алдымы соң? Җук, ул 1906 нчы елның синтабр аинда Гыйлмеддин салдат кызын алды. Никах мәҗлесенә мине киндер орлыгы җолыккан җирдән кырдан барыб чакырды. Ул вакыт Гыйнаүвәл да бездән җырак түгел киндер җолка иде. Гыйнаүвәл Сөгнәтулла Гыйлмеддин кызын алганын ишедеб бик күңелсезләнде. Ләкин Сөнгатулла бу хатын берлән озак тормады. Өч атнадан соң аны аерыб Гыйнаүвәлне алды. Менә шуның берлән бу кугыш[1] тәмам булды.

***6. Урыс-герман сугышы***

**Герман көе**

*татар халык җыры*

*1914 нче ел*

Утырдым атның биленә,
Киттем герман җиренә.

---

[1] гонка

Герман җире – кара үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.
Дуслар, безне озаткачтын
Капкаларны япмагыз.
Безнең газиз балаларны
Ятим диеп какмагыз.
Әнкәй ашын әзерләгәч
Балалары җыелыр.
Алар булып без булмагач
Күз яшьләре коелыр.
Туган җирдән алып китте
Тимер юлның такыры.
Өстемдәге ак күлмәгем
Кәфен булыр ахыры.
Кояш чыга өйләнеп[1]*,
Ак болытка уранып.
Туган илгә берәр вакыт
Кайтырбызмы әйләнеп?

1914 нче ел Герман сугышы башланды. Сугышка запаснуй салдатларны мблизауит иткәндә мин дә эләгеб китдем. Мин 1897 нче ел салдат булыб иң актык җылгы мин идем авылда. Бу вакытда без инде Сбиридә Тара өйәзе Такмык влсте[2] Казан авылында идек. Җомга көн иде. Иулнең 18 нче көне. Мин иртә берлән җомга кадәрле[3] иген басуларын караб йөреб кайтдым. Бодайлар, арышлар бик куанычлы, бик йахшы булыб килә иде. Җомгадан соң чәй эчкәч йәнә икенче басуга ике балам берлән иген карарга китдем. Авыл тыныч, һич бер җыр җук. Халык аны-моны, бернәрсә белми. Эшли йәки бу җомга көн йал итә иде. Без кырдан кайтканда төшдән соң сәгать 5ләрдә менә халык астансга[4] кабкасы төбенә җыелган. Нидер бар, кайнашалар иде. Мин бу халыкны күргәч дә абдраб калдым. Вакытсыз нинди җыелыш бар диб өйгә керсәм, хатыным бик күңелсез. «Герман сугыш бар имеш, хәбәр килгән. Сезне кала диб әйтәләр» диде. Мин тиз генә җыен йанына бардым. Барсам ни күрим: йазуда 1897 нче ел бара диб йазылган. Мин бер минут да тормыйнча өйгә кайтыб хатынга күлмәк, ыштан һәм салдатка кирәк нәрсәләр хәзерләргә кушдым. Иртәгесен, беренче баланы алыб, чапкан печәнләрне җиарга китдем. Без бу көн 60 чүмәлә печән җиеб кайтдык. Иртәгесен 19 нчы иулдә иртә сәгать

1 «өйле» булып, ак болытка уранып (М. Кашгари сүзлегеннән)

2 волосте

3 җомга намазына кадәр

4 станцияга бара торган(?)

8ләрдә авылдан чгыб китдек. Без Такмыкка барганда салдатлар җыела башлаган иде. Төшдән соң сәгать 2дә без уизни[1] гуртка таба чгыб китдек. Салдатларны ат арба белән озаталар иде. Без 29 нчы иулдә иртә сәгать 11ләрдә инде Тара шәһәрендә идек. Бу көнләр руза[2] вакыт иде. Без Тарада Мөхәммәд берлән Сагдулаеф дигән кешегә фатирга кердек. Ләкин монда көндез чәй эчү мөмкин булмады. Руза вакыты булганга. Без Мөхәммәд берлән чәй эчәргә урыс арасына китдек. Ләкин урыслардан да рәтле урын табмагач бер бик факыйр чатан урыска креб чәй эчдек. Шундан соң без Тарада 12 көн торыб 5нче каманда берлән парахутка утрыб Омскига китдек. Без Балшуирич дигән авылда Иртиш буенда хатыным, өч улым карый алыб күрешеб калдылар. Без мондан йәнә кузгалыб китдек, вакыт таң алды иде. Безгә Омскида чуен йул барыб вагунларга утрырга иде. Мин Омскида авылдашларны табыб алар берлән чәй эчеб астансиага китдем һәм ибдәшләрне табыб вагунга креб утырдым. Озак да тормый без Омскидан Уркутскига таба китдек. Безне Кански[3] дигән уизни гуртка илтеб куйдылар. Без барганның иртәгесен ураза гаиде иде. Ләкин безне рутный бәйрәмгә җибәрмәде. Безгә бу көн салдат киемнәре бирделәр. Без Канскида йорт саен таралыб тордык. Монда бик еш бачрак, игмур күб җава иде. Без менә синтабрнең 15нә кадәр тордык. Канскида миңа бик озын шинил биргәнләр иде. Бачарактда ул буйалыб бик авырыб китде. Мин аны бер көн кич тирәли бер чирек аршын кисәргә уйланыб кайчы алыб тирәли кисеб чкдым. Ләкин башта бер чирекдән кисә башласам да, ахрында йарты аршынга кадәрле киселгән. Хасил[4] итәктән йартысы киселгән иде. Моның өчен миңа зур бәла булу ихтимал бар иде. Ләкин шул көн мине бер афиср үзенә хезмәт итәргә диншик итеб алды. Бу кеше йәш кенә афиср нимс[5] баласы Птракрадның иде. Хәзерге көндә Линнград исемендә. Бу шәһәрдә без моның берлән фатирда тордык, Канскидан чгыб киткәнче синтәбрнең 15дә. Афиср миңа «Мин астансага барам шалун прнмаит итәргә, син әйберләрне төйәб йәмшк берлән астансага бар, бүген сугышка чгыб китәбез» диб чгыб китде. Мин ашаб-эчеб, җыеныб барганда инде шалун тәмам тулган иде. Салдатлар килеб беткәнләр. Мин аз гына соңга калмаганмын.

Мин әйберләрне вагунга урнаштрыб, үзем диншиклар вагунына үз әйберләремне алыб бардым. Ләкин монда инде салдатлар тулыб куйганлар. Алай да мин дә шунда кереб кысылдым. Ләкин озак бармадык. Урынлар рәтләнделәр. Йулда барганда пуизда мине афисирлар үз вгунларына са-

1 уездный
2 ураза
3 канск
4 килеп чыккан
5 немец

мавр куирга кушдылар. Мин җулда 15 көн афисрлар вгуннда самавр куиб чәй эчреб бардым. Күб көн шул вагунда йокладым. Афисрлар төн-көн карта уйнилар. Мин аларга чәй йасаб бирәм. Самаврда су беткәч йәнә самавр куйам. Чөнки самавр бик кечкенә иде. Менә без шулай итеб октбрнең 1 нче кичендә Аршау шәһәренә барыб җитдек. Бу вакыт гирман салдатлары Варшауга 12 чакрым генә җитмәгән иделәр. Туп аткан тавыш безгә җулда ук иштелә башлаган иде. Без Аршау астансасына килеб туктау белән безгә вагунлардан бик тиз чгарга кушдылар. Без бик тиз әйберләрне пласфурмага ташдык. Соңра әйберләрне салдат арбаларына төйәб Аршау аша грманларга таба чгыб китдек. Без Вршауның крыена чгыб туктаб байтак торгач безнең пулкга кире Аршауга кайтыб бер-ике көн фатирда торырга әмер булды. Салдатларны җорт саен таратб урынлашыб ике көн җал итеб өченче көн бар дивизи җыелыб беткәч безнең дивиз гирман фрунтна пазисга барыб урнашты һәм дә кич һәр баталиунны бүлеб пазисага җибәрделәр. Иртәнгесен инде рани салдатлар да күренә башладылар. Безнең рутаның камандиры да рутаны ташлаб пазисдан качыб кайтды.

Аны тотыб даставит итеб йәнә пазисага ибрделәр. Иртәгесен миңа баталиуни духтр: «Син афсирның кайда икәнен беләсеңме?» диб сорады. Мин дә: «Җук, белмим» дидем. «Киткәндә әйтми китде» дидем. Духтр миңа аның кайда икәнен әйтде. Ул пазисада 8нче рутаның йартрута[1] берлән артилиринне саклый. Йагни тупчыларның германларга таба җагында үзебез пазиса берлән герман пазисасы арасында сикртда җаткан акупда. Мин көндез сәгать 11ләрдә азык алыб афисерны эзләб китдем. Чөнки ул икенче батрины саклый икән. Миңа духтр икенче батари кайа торган сөйләгән иде. Мин шунда китдем.

Мин духтр әйткәч барыб икенче батарины табдым. Урман артында бер астыр[2] җиргә тубларны беркеткән, үзләре германларга карата аталар. Алардан уң җакда бер зур таш җорт, аның артында атлар, арбалар тора иде. Германлар безнекенә таба аталар, ләкин тидерә алмыйлар. Безнең тубларның өстендән узыб китә здәрәләре[3] Мин грман здәрәләре астындан икенче батари йанына бардым. Снардлар баш очындан узыб китә. Мин снарт узгач башны тотыб карим. Баш исән. Мин барганда тилифунда утручы афиср тупчыларга каманда бирә иде. Тубның соңгы присел йугарырак диб. Мин бер салдат җанына барыб афисрны сорадым. Ул мине бик гәебләб, сүгеб «Монда җөрмә, үзең дә бетәсең, безне дә хараб итәсең» диде. Әнә анау[4] азбадан барыб сораш, анда афисрлар бар

---

[1] «полурота»

[2] яшерен

[3] ядрәләре

[4] андагы

диде. Мин ул күрсәткән йорт йанына баргач андагы салдатлар «Хәзер афисерларны күреб булмый, өйнең ишеге грманлар җагында, менә кич кенә килергә кирәк. Кич, төн атмыйлар, афисерлар җанына креб була» дигәч мин йәнә килгән җулым берлән кайтыб китдем һәм сәләмәт чыкдым. Бу минем беренче мәртәбә пазис күрүем иде. Мин кич берлән 8 нче рута кухнасы берлән барыб афисрны табдым. Ул мине күреб «Ник монда миңа ашарга, бер нәрсә кирәкми, монда афисрлар өчен аш бар, ләкин иртәгә кичкә күлмәк ыштан алыб кил» диде. Мин өзак тормадым, кайтыб китдем. Икенче көн кич афисрга күлмәк ыштан алыб бардым. Төн йәнә кайтыб китдем. Чөнки безнең обуз пазисадан өч чакрым артда тора иде. Өченче көн грманлар иртә берлән пазисаны ташлаб качыб китделәр.

Безнең пулклар аның артында 50 чакрым баргач кире Аршауга кайтды. Гирманлар артындан Сибирскиның бренче стрилкавай двизисы куыб китде. Без аубз берлән пулк артындан барыб Аршаудан бер крык чакрым барыб бер палк[1] авылында куныб иртәгесен пулк берлән Аршауга төне кайтыб кердек. Безне Аршау сәүдәгәрләре күбесе бүләк берлән каршы алды. Бөтенесе папирус, баһәсез квас, баһәсез бүләкләр бирәләр иде. Без бу кайтуда Аршауда 5 көн тордык. Аршауда мин йапун сугышында Манжуриада күргән ваини мулла Хафизуфны күрдем һәм анарга кунакга да бардым. Аның фатиры Каракауаски[2] урам нумер 3 квартир 7 иде. Ул бер көн салдатларны җыеб намаз уктыб салдатлардан 15 сум алыб җыеб китде. Шундан соң без йәнә Аршаудан чгыб китдек. Без пазисадан Аршауга кайтканда 9 нчы октбр иде. Безне туры сапурни баталиун торган казармага алыб кайтдылар. Без Аршауда 15нче октабр кадәргә тордык. 15 нче октабрда без иртә сәгать 8дә йәнә Аршаудан чгыб койаш чгышына таба караб китдек. Без бу көн көн буе туктамыйча барыб Йабулин астансасы йанына бик зур казармага креб кундык.

Ләкин бик арган идек. Айаклар кабарган иде, чөнки бүген җалдан соң беренче көн һәм бик күб йөрдек. Без кергән казармаларны салдатлар чгыб киткәч тазартучы булмаган. Без бер бүлмәне тазартыб афсрлар өчен хәзерләб чәй кайнатыб афисрларны ашатыб-эчереб үзебез сәгать 12дә җокларга җатдык. Иртәгесен 16 нчы октабрда иртә сәгать 6да торыб бик тиз чәй кайнаб афисрларны уйатб чәй эчеб сәгать 7 бик тиз җыеныб чыгыб да китдек. Бу көн без Нави Йургифаска крипч[3] җанына туктаб төшке ашны ашадык. Ашадан соң Нави Йуркф крипчн аркылы чгыб китдек. Бу җакта крипчны бик ашгыб төзәтәләр иде. Инде без Аршаудан җыраклашдык. Сугыш тавышы ишетелми иде. Ләкин йөрегән бик борчый иде. Без бу

[1] ноляк

[2] краковский

[3] крепость

көн кич сәгать 10нда гурт Ситлст җанына барыб туктадык. Төн караңгы, игмур җава. Шәһәргә креб фатир табар хәл жук иде. Пулк шәһәр читенә палатка корды. Без 7 нче рута камндиры паручик Паснк берлән шәһәргә фатир эзләргә китдек. Урам буйлаб креб йөри торгач бер палка[1] хатын бер бәләкәй өйне күрсәтә. Өченче кат җугары өйдә хуҗасы палк өйен бикләб үзе икенче өйгә күчеб салдат кертмәскә уйлаган икән. Ләкин йахшылаб сорагач ишек йозагын ачды. Без 7 афисрның караватын кчкенә генә бер бүлмәле өйгә кртеб урнаштырдык. Өйнең алдында кчкенә генә кухнә да бар икән. Шунда чәй кайнатдык. Утын да булды. Өй хуҗасы маҗтр[2] икән. Анардан җомшкалар алдык. Йәнә безгә булышырга ике кызы да. Монда без бүген чәй эчеб бу өйдә җылы йокладык. Без 18 нче октабрдә иртә сәгать 8дә чкдык. Бу көн безгә бары 8 чакрым барырга иде. Без бу авылга сәгать 12дә барыб кердек. Палк авыл, исеме хәтердән чыккан. Бу авылда салдатлар үзләре урын табыб кайсы анбарда, кайсы лапасда тордылар. Без баталиун афисрлар өчен бер ташланган балчык ызбаны тазартдык. Ләкин без үзебезнең рутаны камандир Зубинко һәм минем афисрым прапорчик Тимм һәм ике диншк палкларның үз йакларына кереб ике көн тордык.

Без бу өйләрдән җырак түгел икенче авылга барыб кибетдән 10 кадак май алыб кайтдык һәм бу өйдә катлит һәм какулар[3] кайнатыб эчеб ике көн рәхәтләнеб тордык. Икенче көн безнең йулга азык аз булганга һәм җулда шәһәрләр дә тиз булмас дигәч кич берлән Ситалистка булки алырга бардым. Ләкин кайтканда җулны адашыб озак йөреб кенә авылны табдым. Безнең пулк бу авылда 19нда һәм 20 нче дикабрдә йал итде. 21ндә иртә сәгать 6да чгыб китдек. Без бу көн Сигануф дигән гурт аша чгыб 3 чакрым баргач бер нимс авылына төн 10нарда барыб кунарга туктадык. Без афисрлар берлән бер нимс өенә кереб урнашдык. Афсрлар җорт хуҗасы нимсне чакрыб эчәргә вина кайан табыб булыр диб сораганлар. Нимс гурт Сигануфда булыр диб сөйләгән. Афисрлар мине чакрыб «Сафиулин, менә бу кеше берлән Сигануфка бар, 60 сум акча бирәмез, вина алыб кайтырсын» диделәр. Мин аларга бик арганымны һәм ашалган да жук дидем. Алар миңа «Кулыңа күмәч, май ал да бар, без башка кешегә ышанмыйбыз. Син барырсың» дигәч мин кулга күмәч, май алыб нимс берлән төн караңгыда баткакда йәнә Сигануфка китдем. Ләкин бару берлән бар кибет җабык иде. Урамда чораган[4] кешеләр дә һич бер җирдә вина җуклыгын әйтәләр иде. Урам буенча күб йөргәч бер йәври кибетен-

[1] полька (урысча – «полячка»)

[2] «мастер», агач остасы

[3] какао

[4] очраган

дә ут күреб кибетенә кага башладым. Кибетне бер йәври карчыгы ачты да үзе өстәл җанына барыб чәй эчә торган урнына барыб утырды. Мин баштан фурашканы салыб башка кара кәләпүш кидем. Шундан соң 15 йәшләрендә йәври кызы минем җанга килеб: «Бу салдат йәври икән» диб әбиенә әйтде. Карчык килеб караб, кәләпүшне тикшереб караб: «Җук, бу жид түгел» диде. Шул вакыт кибет эчендән 18 йәшләрендә бер йегт килеб чкды да, минем җанга килеб «Бу казан татары, инәм[1]» – диб мине чәй эчәргә утыртты. Мин булки берлән ике стакан чәй эчкәч бу егетдән вина хакында кузгатдым. Бик ышанычлы вәгъдә биргәч бу егет 7 бутилка вина чыгарды да 3әр сум диде. Мин: «Йарый, тулки тагы бир барын, калдырма» дидем. Ул тагы өч бутилка чыгарыб «7 сум» диде. Мин «Йарый, тагы бармы?» Егет йәнә бер бутилка алыб чгыб: «Бусы унбиш сум, бусы 7 нче ел эшләнгән» диде. Без шуларга акча түләб афсрларга алыб кайтыб бирдек. Афсрлар көн буйы гулит итеб уздырдылар. Без бу нимс авылында ике кич куныб 23 дикабрда бу авылдан чгыб китдек. Бу көн бик йүеш, йагмур җавыб тора иде. Без бу көн бик мәшәкать берлән Пулутски шәһәренә барыб бер нимс авылына килеб туктадык. Бу нимс авылында өч көн тордык. Иртәгесен Пулутски шәһәренә барыб мунча кердек һәм дә шәһәрне караб йөрдек. Шәһәрне нимслар бераз ваткан һәм тимер күперне ватканлар. Висла суы аша тимер күпер булган икән. Нимс кышын килеб ватыб киткәнләр.

Бу нимс авылында 2 нче нуйабрга кадәр тордык. Икенче нуйабрда төн сәгать 10ларда безнең пулкны кузгатыб Пулутски шәһәренә алыб китделәр. Төн бик карангы, җул бик баткак иде. Без афиср әйберләрен төйәб пулк артындан Пулутскига бардык. Безнең обуз Пулутскиның крыена Висла суы буена китеб туктатдылар. Монда артлилар да тублары берлән килеб туктаганлар иде. Без таң аткач пулкны эзли башладык. Ләкин пулк пархуд берлән Висланың икенче йагына чгыб киткән икән. Мин кибет ачылгач кибетдән күмәч, дунгыз ите һәм 5 кадак шикалад алдым һәм парухудга ултруб пулкны эзләб табыб афисрлар җанына бардым. Афисрлар бер өйдә салам түшәб җоклаб йаталар иде. Мин үз афисрмны уйатыб: «Чәй эчәсез килмиме?» дигәч «Булса йарар иде» диде.

Мин тиз генә чәй кайнатыб афисрны эчердем. Афиср миңа акча биреб: «Шәһәрдән әйберләр күбрәк ал, мондан соң сугышка керәбез, бәлки шәһәргә кереб әйбер алыб булмас» диде. Мин йәнә Пулутскига барыб әйберләр алдым һәм дә Висла аша луткалар[2] берлән йасалган күпердән абуз берлән чкдык. Инде кич иде. Без чкканда пулк сугышка китәргә хәзерләнә иде. Кич сәгать 10ларда пулк пазисага сугышка китде. Без дә алар

[1] әнием

[2] көймәләр

артндан абуз берлән китдек. Бу төн бик салкын һәм бик блчырак иде. Сугышка кузгалыр алдындан безнең рутаның камандиры мине һәм үз диншиге Иванны чакрыб: «Без хәзер сугышка барабыз, сез артда торырсыз, әйберләрне йахшы карагыз. Әгәр дә мин үлсәм, минем әйберләр йәш афисрга калыр. Әгәр дә йәш афиср үлсә, аның әйберләре миңа калыр» диде. «Әгәр дә сез рани булсагыз, сандык ачкычларын сәләмәт калганыгыз алыгыз да, рани булган кеше ачкыч алса китмәгез» диде. Мондин соң пулк кузгалыб китде. Без дә обуз берлән пулк артындан китдек. Ләкин төн буе блчыракда кайда барасын белмичә күб вакыт туктаб да тордык. Таң алдындан безгә Губнин дигән мистичкага барырга әмер булды. Без 4 нче нуиабрда иртә берлән Гунбнинда булдык. Без иртә сәгать 8ләрдә бер палкка креб чәй эчдек. Без чәй эчкәндә безнең абуз кайадыр киткән. Без бүтән урам буйлаб эзләб абузны табдык.

Ләкин безнең берлән бергә чәй эчкән ат башында йөрүче Хабибулинның ат жук иде. Ул ат арбасын пазис йанындан эзләб алыб кайтды. Чөнки деншиклар утрыб абузны эзләб пазис йанына барганлар.

Гунбинда иртә сәгать 9ларда камандир палка пулкын ташлаб качыб кайтды. Йанында 10 салдат да бар иде. Ул бер палк өйенә кереб җал итәргә җатды. Без моны күреб пулкны бетергәнләр икән нимслар диб куркдык. Мондин 5 нче рута камандиры паручик Троеский 7 салдат берлән кайтды. Рутаның һәм пулкның кайда икәнен белми иде. Мондан соң беренче баталиун камандиры капитан Пуркупчинко кайтды бер азвд[1] салдат берлән. Ул мине күреб монда нихәл бар диб сорады. Мин анарга: «Камандир палка качыб кайтды һәм башкалар да кайталар» дигәч ул пулкауның җанына кереб китде. Инде без бар пулк салдаты беткән икән, афисрлар һич нәрсә белми диб кайгырыб торганда пулк салдатлары җыела башлады. 5 нче рутаның фитфибиле рутаны алыб кайтды. Йәнә башка руталар да кайта башлады. Ләкин 2 нче баталиун 5 нче рута кайтмады. 6 нчы, 7 нче, 8 нче руталар җук иде. Салдатлар бераз җыелгач камандир палка салдатларга аш бирергә кушды. Без дә афисрлар кайтыр диб чәй кайнаткан идек. Мин руталар кайтыб килә торган җул берлән пазисага таба китдем. Әгәр дә үзебезнең рута очраса, тизрәк кайтыб ашарга диб әйтергә. Җулда кайтучы афисрлар: «6 нчы рута кайтыб килә ерак түгел» дигәч мин тагы да ашыгыб бара идем. Миңа 2 нче баталиун духтры чурады. Бу духтр үзе йәври булса да, пулкда иң шәб кеше иде. Раниларны йахшы карый иде. Бу духтр бик курыккан һәм бик арган килә иде. Мин йәнә 6нчы рутаны сорадым. Ул тиз килеб җитерләр диде. Мин йәнә тизрәк китдем. Озакламый 6нчы рута килеб җитде.

Рутни камандир Зубинко мине күргәч рутаны туктаб үзләре утрыб ашарга сорадылар. Миндә бер плитн шикалад бар иде. Кесәдән алб шуны

[1] взвод

бирдем. Аны ике афиср бүлеб ашый башладылар һәм «2 нче баталиун камандиры капитан Навихин андамы?» диб сорадылар. Мин: «Ул җук», камандиры палка капитан Пуркупчинко һәм парутчк Троескилар барын һәм башка руталар да кайтканын әйтеб тизрәк кайтыб ашаб эчәргә, хәзер пазисага китәчәген әйткәч рутни: «Сафиулин сүзен тыңлаб кайтик» диб ибдәш афиср берлән килгешеб Гунбинга кайтдык. Салдатлар тизрәк кухнага җөгерде. Афисрлар фатирга креб икешәр астакан чәй эчкәч бер салдат килеб: «Камандир палка хәзер җыелыб пазисга барырга әмер итте» дигәч афисрлар йөгрешеб чгыб китделәр. Салдатларның күбесе алган ашларын түгеб йәнә ач пазисага китделәр. Бу төнге сугышда палкави атутн[1] парутчк Качуби рани булган иде. Аның урнына прапршк Кутузуф калды.

Пулк пазисага киткәндә сәгать кичке 4ләр иде. Пазисада атышу бик шәб, нимслар Гунбига йакыннаша иде. Без әле сугышка бик күнекмәгәнгә бик курка идек. Инде абузга да Гунбинда калырга вакыт җук. Ихтимал абузны плин алулары. Безгә дә мондан китәргә әмер булды. Без дә бик тиз җөкләрне бәйләб җыеныб мондан чгыб китдек. Безгә бару бик кыен. Карангы, йагмур җава, блчырак, абына-җгыла барабыз. Инде сугышдагы салдатлар хәле әлбттә безнекендән кыйнарак[2], аны һәркем белергә мөмкин. Йулда барганда млтык, пулимут һәм туб тавышы йакын иштелә. Без плин төшүдән куркабыз. Гунбиндан 10 чакрым киткәч без бер нимс авылына туктадык һәм дә бик салкын булганга бер нимс өенә бик кыенлык берлән генә кереб җокладык. Чөнки нимс үзе өйдә җук. Хатыны балалары берлән бикләнеб җоклаган. Уйангач да урыс салдатлары икәнен белгәч ачасы килми иде. Ләкин ишекне ватудан куркыб ачды. Без бер бүлмәсенә креб җокладык. Бу авылдан иртә сәгать 8ләрдә күчеб китдек. Көндез йәнә бер палк авылына туктаб пешкән итне пурсга[3] бүлделәр. Без шул вакытда чәй кайнатыб бер палк хатыныннан 70 тиенгә бер кадак май алыб дүрт салдат бик тәмнеләб чәй эчдек. Без бу авылдан сәгать 1ләрдә чгыб китдек. Җулда мистичка Саликга туры килдек. Ләкин бу мистичкада бернәрсә дә йук, халык качыб беткән иде. Бик ашыгыч рәвешдә лазаритларны күчерәләр иде. Монда дивзинуй лазритлар палтка корыб күб ранилар җыелган булган. Хәзер аларны арба берлән артка күчерәләр иде. Зур арбаларга дүртәр ат җигеб аларга күб авыр җөкләр төиләр иде һәм рани салдатларны арбаларга утртыб китәләр. Алар акрышыб, скраныб кчкырышыб баралар иде. Без дә шулар берлән бергә бара идек. Безнең абузга Аликсандруфка авылына барырга әмер әйтелгән иде. Мондин соң кич

[1] адъютант

[2] кыенрак

[3] порцияларга

сәгать 6 ларда без бер палк авылына туктадык. Монда салдатлар шпиун диб бер йәврине кыйнаб үтерделәр һәм дә безнең абузга 9нчы рута килеб ашаб китде. Алар пулк килер дигән иде. Ләкин пулк төнге сәгать 1 нчегә кадәр көткәч дә килмәде. Мондин соң безнең абузга гурт Сигачуфка барырга әмер булды. Төн абуз бер зур палк авылына кереб җал итде. Бу авылда без бер салдат берлән икәү генә бер азбага креб йаткан идек. Без йоклагач абуз кузгалыб киткән. Без икәү генә калганбыз. Төн карангы иде, йөрүчеләр бар. Салдат да җөри, палклар да җөри. Ләкин берсе дә безнең абузны күрмәгән. Күрсә дә нindиен, абуз кайсы пулкныкы икәнен белмәгән. Без һаман алга барабыз. Менә безнең бәхеткә безнең абузның бер сыеры аврыб бара алмый калган. Шуны саклаб бер салдатны калдырганлар. Без анардан абузны сорашдык. Ул «Шул җул берлән китделәр» диде. Мин бу салдатка «Инде караб торма, сыер үлде диб әйтербез, барыбер үлә» дисәм дә, ул шунда калды.

Ашгыб-ашгыб барганда безне Данскуй казакларның абузы куыб җитде. Алар палклардан ат җыеб абуз йасаганлар. Без бу палк арбасына утрыб байтак баргач Сихачуф күренә башлагач арбадан төшкән идек. Мунә бер данскуй казак кылычын чыгарыб чавыб килде дә: «Сез нинди салдат, качыб йөрүчеме?» диб безгә бәйләнә башлады да, «Безгә приказ бар, качыб йөрүчеләрне чабарга» диб безгә ташлана. «Без 52 нче запаснуй пулкның афисрларның бистави[1], Сихаҗуфка абуз артындан барабыз» дигәч кенә китде. Мондан соң без җулдан бер крыйга креб бик каушаб Сихачуфка җитдек. Бзур[2] җылгасы аркылы салынган тимер күперне нимслар ватыб киткән икән. Бик начар гына күпердән чгыб без тав буенда таудан менә алмый торган атларны абузны куыб җитдек дә инде абуздан айрылмаска булдык. Чөнки казаклар куркыта. Безнең абуз Сихачуфдан өч чакрым бер авылга туктады. Без шунда чәй кайнатыб эчдек. Бүген 7 нче нуиабр иде.

Кичкә таба без йәнә Бзур җылгасын чгыб пулкны эзләб китдек. Пулк Сихачуфдан 8 чакрым бер бик зур палк авылына туктаган икән. Бу авылда зур памишк да бар икән. Мин авылның башына кергәч үк 2 нче баталиун сораша башладым. 2 нче баталиун авылның уртарак җиренә урнашкан икән. Мин аларны табыб 2 нче баталиун кухналарын һәм афисрлар әйберләрен китерергә чакырдым. Афисрлар бер палк өйенә кереб идәнгә салам җәеб рәхәтләнеб җоклаб җаталар иде. Без ашаб-эчеб йокларга җатдык. Иртәгесен 8 нче нуиабрда без бу авылда тордык. Иртә берлән мин чәй кайнатыб җөргәндә мине мөселман салдатлары чәй эчәргә чакыралар. «Әйдә чәй эчәргә кил, бал да бар, тавык да пешде» диләр. Болар

---

[1] вестовой

[2] Бзура, Висланың сулъяк кушылдыгы

пазисадан кайтканда төн марта[1] бакчасына чураб марта ватыб бал алган булганлар һәм тавык да тотканлар икән. Минем вакыт булмаса да, бал берлән чәй эчдек. Бу авылда памешикдан бик тәмне алмалар сатыб алдык. Бу көн кич пулк йәнә пазисга китде. Без абуз берлән йәнә Схачуфка кайтдык.

*(Дәвамы бар)*

[1] умарта

Хөрмәтле дин кардәшләрем!

Мин сезгә бөтендөнья әһәмияткә ия булган бер факт турында әйтергә телим. Ул – хәзерге вакытта Ташкент каласында саклана торган мөкатдәс Госман Коръәне. Чөнки аның язмышы безнең якташыбыз, дин әһеле, шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни исеме белән бәйле.

Госман Коръәне Урта Азиягә барып эләгүе турында берничә риваять бар. Шуның берсе буенча, «Коръән Аксак Тимер гаскәренең Якын Көнчыгышка яу вакытында алынган» диелә. Ул 1868 елга кадәр Сәмәрканд каласында Хуҗа Әхрар мәчетендә саклана. Аннан Санкт Петербургка Императорның публицистик китапханәсенә алып кайталар. 1924 елдан кадерле Коръән Кәрим Үзбәкстанга кайтарыла.

Габдерәхим Утыз Имәни Сәмәркандта булганда Хуҗа Әхрар мәчетендә таркалып яткан, югалган, урланган, битләре урынына яңа битләр язып, төзәтеп куя. Бу хакта ул үзе шигырь белән шулай язган:

Укырда бер кичә мосхәфе Госман,
Өйнең сорахыннан (**тишегеннән**) керде дошман.
Орар хәнҗәр илә, бакмаз үзенә,
Акар каны ушал (**шул**) мосхәф йөзенә.
Рәсулуллаһны дөшдә күрмеш иде:
«Бу көн безгә кәлүрсән», – димеш иде.
Сәяхәттә, бу мискин, йөрдекмедә,
Сәмәркандтә ничә көн тордыгымда,
Күребмән мосхәфе: бер җайда (**урында**) тормыш,
Вәраклары (**битләре**) тузыб, бәнде өзелмеш.
Гаҗәиб хатты (**язуы**) вардыр, һич ирсә,
Укый белмәз алыб бакыб күрерсә.
Кылыблар пуст аһудан вәраклар (**җәнлек тиресеннән битләре**),
Җәли хаттыр (**Таныла язуыдыр**), уникедер сәтырлар (**юллары**).
Олугдыр, катгый тула (**буе**) дүрт карышдин,
Дәхи гарза (**иңе**) кылыбтыр өч карышдин,
Йуанлыгы улыр ике карышдин,
Агырлыгы улыр пәнеж (**биш**) сир дик (**375 г**).
Булашмыш канига берничә әүрак (**битләре**),
Хисаб итсәң, чыкар үндан зиядәрәк (**артыграк**).
Тузыб китмеш вәракларны (**битләрне**) йигыбмән (**җыеп**),
Ике такта арасига куйыбмән,
Дәхи мәхкәм (**нык**) йиб (**җеп**) илә таза баглаб (**бәйләп**),
Куйыбмән такчага хуб агырлаб (**яхшылап чистартып**).

Сәмәрканд шәһәренә варсаң күрерсән,
Бинаи Хуҗа Әхрарадан сорарсән.
Улыр <u>хәштдин кылан</u> (**яндырылмаган кирпечтән**) ак <u>мәдарис</u> (**мәдрәсә**),
Бинасы <u>мәрфуг имәсдер</u> (**күтәрелмәгән**), ирәр пәс.
Эчендә вәкыфханә <u>хөҗрәи</u> (**бүлмәсе**) вар,
Табарсән шунда керсәң, и таләбдар.

Сүзлек: *сорах – тишек; ушал – шул; җайда – урында; вәрак – бит; хатт – язу; пуст аһу – җәнлек тиресе; җәли – ачык таныла; сәтыр – юл; тула – буе; гарза – иңе; әүрак – битләр; пәнеҗ – биш; сир – авырлык үлчәме = 75 г; зиядә – артык; йигыб – җыеп; мәхкәм – нык; йиб – җеп; баглаб – бәйләп; хуб агырлаб – яхшылап чистартып; хәшт – яндырылмаган кирпеч; мәдарис – мәдрәсәләр; мәрфуг имәстер – күтәрелмәгән; хөҗрә – бүлмә.*

Шиһабетдин Мәрҗани дә үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән хезмәтендә әсәрендә шулай яза:

«Габдеррәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым әл-Утыз Имәни... Мосхафе имам Госман» (**«Имам Госман Коръәне»н**) <u>дидеке мосхафыны тәрмим идеп мәху улмыш</u> (**тәртипкә китереп шөгыльләнә**). <u>Бәгъзе мәвазыйгъны</u> (**кайбер урыннарын**) язып, ертылмыш кәгазьләрени ябыштырып <u>ислах итмеш</u> (**төзәтә**)...»

1891 елда шәрыкне өйрәнүче А.Ф. Шебунин «Куфический Коран Императорской С.-Петербургской публичной библиотеки» китабында шушы ук сүзләрне китерә (С.-Пб., Типография Императорской АН, 1891).

Филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Рәмил Исламов язганча, «ничәмә-ничә гасырлар дәвамында төрле вәзгыятьләр кичергән бу «Госман Коръәне»нең сакланып калуында татар зыялысы Г. Утыз Имәнинең мөкатдәс гамәле дә мөселман дөньясында биниһая тарихи әһәмияткә ия. Ул һичшиксез халыкара яңгыраш алырга тиеш!»

Шуңа күрә, хөрмәтле дин кардәшләрем, Утыз Имәнинең әлеге гамәлен мәңгеләштерү йөзеннән Ташкентта аның бюстын кую мәсьәләсен карау өчен Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановка мөрәҗәгать кирәк.

## МОСХӘФ ХӘЗРӘТЕ ГОСМАН РАЗЫЙ АЛЛАҺУ ГАНҺЕ

Матбугатта Петроградта сакланмакда булган ошбу Кәлям Шәрифне Әхмәд бәк Салиховның соравы буенча большевиклар мөселманларга бирмәкче булдыклары язылган иде.

Бу Кәлям шәрифне Русия дәүләте Сәмәркандны алгач, Сәмәркандта Хуҗа Гобәйдулла әл-Ахрәри кабере янында булмыш мәдрәсәнең бер хөҗрәсендә улганлыкындан Кауфман хәбәрләнеп, 1869 нчы ел 24 нче октябрьдә Петроградка мәгариф министрына йибәргән. Бу Кәлям шәриф хатты куфи илә язылып (пергамент) иләнгән хайван тиресенә язылган. Бу хакда голямаи кәрамнең сүзләре ошбулардан гыйбарәтдер: Рөсүм Коръән фәнендә маһир хафиз Әбү Габид әл-Багдади җанабләре Сәмәркандта улмыш мосхәфне хәзрәте Госман яздырган мосхәфләрдән дәгел димешдер.

Ул мосхәфләрдән берсенең 552 сәнәдә Кортаба шәһәрендә улдыгыны вә берсенең 735 сәнәдә Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә улдыгыны сөйләмешдер.

Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Җәзири «ән-Нәшер» исемле әсәрендә бойлә дия: хәзрәте Госман мосхәфене Мисырда мәдрәсәи Фазылиядә күрдем, кан әсәре дә бар иде.

Ибне Җәбир дәхиләсендә бойлә дия: «Мәдинәдәге мосхәф – хәзрәте Госман яздырган мосхәфләрнең берсе, шулай да ул хәзрәте Госманның шәһадәтендә укып торган Коръән дәгел.

Ибне Котәйбә бойлә диядер: «Хәзрәте Госман шәһадәтендә аның алдында булган Коръән углы Халидкә калды. Андан соң аның әүладендә калды. «Нөзһәт ән-назыйрин» сахибе Бәрзәнҗи бойлә диядер. Мисырда, Мәдинәдә, Мәккәдә улан өч нөсхә хәзрәте Госман мосхәфләренең өчесендә дә кан әсәре бар. Моны тәүҗиһ итеп[1] диядер: «Моның берсе генә хәзрәте Госман алдында булган Кәлям шәриф улып, калган икесене тәбәррекән[2] шуңарга охшатып кызылга буяган булырлар. Ошбу Петроградта улан Кәлям шәрифтә дә кан әсәре бар диләр. Бәрзәнҗи тәүҗиһенә бинаән[3], ул да бер гарыз илә шөйлә кызылга буялган гына булыр, Мисырда булган булса, хәзер дә көтепханәи Хөдәйвиядә булырга тиеш иде, чөнки Мисырда табылган җөмлә иске әсәрләр анда җыелган. Җөмләдән хатты күфи илә хәзрәте Җәгъфәр әс-Садыйк тарафыннан язылган бер Кәлям шәрифне Мисырда үзем дә күрдем.

Утыз Имәни Габдеррәхим хәзрәт Сәмркандта булмыш Кәлям шәрифне күрмеш вә аны төзәтмеш, ул хакда бойлә диядер:

---

1 Тәүҗиһ итеп – мөрәҗәгать итеп.

2 Тәбәррекән – мөбарәк дип.

3 Бинаән – нигезләнеп.

«Укырда бер кичә мосхәфи Госман
Өйнең сорахындан[1] керде дошман
Орар хәнҗәр илә – бакмас үзенә,
Акар каны ушал мосхәф йөзенә.
Рәсүлуллаһны дөшдә күрмеш иде,
Бу көн безә килерсең димеш иде.
Сәяхәтдә бу мескин йөрдекемдә
Сәмәркандта ничә көн тордыгымда
Күрепмен мосхәфне – бер җайда тормыш
Вәрәкъләре[2] тузып бәнде өзелмеш
Гаҗәиб хатты вардыр, һич ирсә
Укый белмәз алып бакып күрерсә.
Кылублар пуст аһудан[3] вәрәкъләр,
Җылы хатдыр – уникедер сәтырләр[4].
Дәхи гарыз кылыбдыр өч карышдан
Юанлыгы улыр ике карышдик.
Агырлыгы улыр пәнеҗ[5] сәер дик
Булашмыш каныга берничә әурак[6]
Хисап итсәң чыкар ундан заядәрәк.
Тузыб китмеш вәрәкъләрне егыб мән.
Ике такта арасига куеб мән
Дәхи мөхкәм[7] йип илә тазә баглаб,
Куепмән такчага хуб агырлап.
Сәмәрканд шәһәренә варсаң күрерсән,
Бинаи Хуҗа Әхрардән сорарсән.
Улыр хиштдин[8] кыйлан бер ак мәдарис
Бинасы мәрфугъ имәсдер[9], ирер пәс
Эчендә вәкыфханә хөҗрәи вар.
Табарсың шунда керсәң, и талибдар».

Сәмәркандтан Минзәлә өязе Утар авылының Ибраһим исемле кеше бәгъзе вәрәкъләрне алып кайтып, Эстәрлетамакта Рәхмәтулла нам затка

[1] Сорах – тишек. Бирåдә тәрәзә мәгънәсендә.
[2] Вәрәкъләре – язылган кәгазь.
[3] Пуст аһу – кәҗә тиресе.
[4] Сәтырләр – юллар.
[5] Пәнеҗ – биш.
[6] Әурак – битләр.
[7] Мөхкәм – нык.
[8] Хиштдин – кирпечтән.
[9] Мәрфугъ имәсдер – ташландык түгел.

саткан, ул исә мөфти Габдессәлам әфәндегә сатып, углы Габдеррәзакъ Казанда бер байга сатканны да риваять итәләр.

Мөстәшрикъ[1] Вамбери Азия сәяхәтнамәсендә ошбу Кәлям шәрифне Аксак тимер Бурса шәһәрендән алып килдекене язмышдыр.

Бондан мөкаддәм[2] ошбу Кәлям шәрифдән 8 нче парә ахырында бәгъзе аяте кәримә басылып нәшер иделгән хәлдә бәгъзе ханәләрдә диварга асылып куелганы күрелә.

1905 сәнәдә[3] Кырыми әл-Ильяс морза Бораганский тарафындан бәс шәриф бит-тәмам[4] табигъ иделенеп нәшер иделенде, аның дидекенчә бу мосхәф шәриф йиде йөз дә алты сәхифәдер[5].

1322 сәнә 1904 сәнәдә Петроградта бит-тәмам йөз данә генә басылып, бәһасе 500 сум улдыгы язылдыгы кеби туле[6] аршындан артык, гарызы[7] аршин микъдарында идеке дә «Нур» газетасында язылган иде. Ошбу басмадан бер данәсене Мисыр сәфәремдә хидью[8] көтебханәсендә күреп зиярәт иттем.

Бу әсәре мөкаддәснең мөселманларның үз кулларына бирелеп, үзләре тарафындан саклануы олуг шадлыкдыр, Җәнабе Хак мөбарәк идеп, боны олуг тәфәәәл итсә[9] иде. Амин.

*Габдулла әл-Мәгаз*

*Алынды: журнал «Дин вә мәгыйшәт» 1918 нче ел, № 4, Б. 39–41.*

1 Мөстәшрикъ – шәрык белгече.
2 Мөкаддәм – элек.
3 Сәнәдә – елда.
4 Биттәмам – тулысынча.
5 Сәхифәдер – биттер.
6 Туле – озынлыгы.
7 Гарызы – киңлеге.
8 Хидью – әмир.
9 Тәфәәәл итсә – яхшыга санаса.

# ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ТАРИХИ ЧЫГАНАКЛАР

# ИСТОРИЧЕСКИЕ ИСТОЧНИКИ ПО КРАЕВЕДЕНИЮ

*Зыятдин хәзрәт Нәҗметдинов*

## МЕТРИКАЛАРДА ХАЛКЫМ ЯЗМЫШЫ
(*туган ягыбыз тарихының метрикаларда чагылышы*)

Авылларыбызның, аның халкының тарихын өйрәнүдә метрикалар бәһасез чыганак булып торалар, тарихның гаҗәеп күп төрле якларын ачарга ярдәм итәләр. Бигрәк тә һәр кешегә үзенең ата-бабаларын ачыклап нәсел агачын төзергә мөмкинлек бирә.

Метрикалар тарихыбызның зур бер өлеше ул. Анда ялган һәм өстәмә юк. Муллаларыбыз бик нык тырышканнар, татар халкына хас булган тырышлык белән кечкенә генә мәгълүматны да теркәп куйганнар. Тарихны өйрәнүдә, нәселне ачыклауда беренче чыганак метрикаларда.

Миңа зур бәхет тиде дип әйтә алам. Күп авылларның метрикаларын чагыштырып чиксез күп кызыклы нәтиҗәләргә килергә мөмкин икән. Бар яктан да. Бер авыл метрикасы шул авылның тарихын ачыклый, билгеле, әмма төбәк тарихын күз алдына китерергә күп авыл метрикаларын чагыштырырга кирәк. Еш искә төшерә торган чагыштыруда, мәсәлән, ил буйлап таралган 1849 елгы ваба (холера) авыруы. Иске Пенәгәрдә 1849 елның июль аенда шул чирдән 31 кеше вафат була. Зур Кукмара авылына чир августта килеп җитә, 28 кешенең гомерен ала. Аерым бик гыйбрәтле очраклар да бар. 1830 елда хәзер Саба районына кергән Тимершык авылында 135 кеше вафат була. Шуның 112 се 19–31 декабрь эчендә ваба чиреннән үлә. Көн саен 10–12 кешене соңгы юлга озатканнар. Аларны бит әле салкын кыш уртасында кабер казып күмәргә кирәк. Авыл өчен нинди зур хәсрәт, хәзер без бу хәлләрне аңлый да алмыйбыз, ышанмыйбыз да.

Имамнар гадәттә башка авыллардан килгән булган. Әле яңа гына, авылыбыз өчен зур ачыш ясадык. Авыл имамнары безнең Кукмара районына кергән Сабанчы (халык телендә Аты дип йөртәләр) авылыннан икәнен ачыкладык. Муллаларны халык санын алу списокларына кертмәгәннәр, алар ясак түләмәгән (җирләре булмаган). Алар бары тик метрикаларда гына күренә. Сабанчы авылында язылган безнең имамнар, үзләре Иске Пенәгәрдә хезмәт иткәннәр.

Элекке чорда халык арасында саф татар исемнәре күп таралган булган. Сөтимгән, Итимгән, Туганаш, Теләгекабул, Эшбирде, Казанбай исемнәрен очрату безнең өчен сәер тоела. Бикташ, Бикбау, Бикчәнтәй, Бикчура исемнәре Иске Пенәгәр авылында да еш очрый.

Исемнәрдә парлаштыру еш күзәтелә. Үзе Динмөхәммәд, әтисе Бикмөхәммәд. Мостафа–Мортаза, Хәсән–Хөсәен, Габделҗаббар–Габделгаффар, Мөфәххәр–Мозаффар, Бикташ–Бикбау исемнәре һәр авыл метрикаларында чиратлашып очрыйлар.

19 йөзнең ахырына таба элекке татар исемнәре аз очрый, аларны гарәп исемнәре алмаштыра. Безнең татар халкы аларны да үзенә хас үзенчәлек белән матур һәм катлаулы исемнәр кушкан балаларына. Нәҗметдин, Гарифулла, Бибинәфисә, Мостафа, Габделсаттар, Хөсниҗамал исемнәре бүген инде сирәк яңгырый. Әмма матур да, мәгънәле дә исемнәр. Катнаш исемнәр күп. Ир-атларның күбесе Аллаһның исемнәре белән Габдел (Габделсамат, Габделлатыйф кебек), пәйгамбәребезгә нисбәтле Мөхәммәд (Мөхәммәдшәриф, Мөхәммммәдзакир кебек) дип исемләнсә, хатын-кызларга Биби белән башланган (Бибисабира, Бибифатыйма кебек) яки Җамал, Камал белән тәмамланган (Хәбибҗамал, Гайникамал кебек) исемнәр күп кушылган. Матур исемнәр күп. Берничә исемне монда мисал итеп китерик: Әхмәдҗан, Габделвәли, Бикмөхәммәд, Гатиятулла, Гыйсмәтулла, Шәмселхәят, Шәһрезадә, Сәхиббану, Хәсбиҗамал, Гөлбаһар, Сәгадәтбану, Фәсыйхәтбану, Гыйззәтбану, Сәлимҗәүһәр.

Никах язмалары үзләре бер аерым өйрәнүне таләп итә. Никах бит ул үзе дини йола гына түгел, гаилә төзүчеләр өчен аның шартлары да бар. Имамнарыбыз алып барган никах язмаларында аның дини өлеше дә, тарихи яктан караганда зур материал да урын алган, татар халкының никах белән бәйле үзенчәлекләре дә күренә.

Никах язмаларында өчәр-дүртәр буынны ачыклап була, икенче никахлары булса, беренчесендә аерылганмы, ире яки хатыны үлгәнме – барсын да имамнарыбыз язып барганнар. Мәһәрләрен, әйбер белән бирелгән булса һәрнәрсәнең исемен, бәяләрен төгәл язганнар.

Безне мәктәптән «бик яшьли кияүгә биргәннәр», яки «үзләреннән бик олы кешеләргә кияүгә чыкканнар» дип өйрәттеләр. Бу фаразлар дөреслеккә туры килми. Статистикага карыйбыз. Күпчелек кызларыбыз 20–25 яшьтә кияүгә чыкканнар. Сирәк кенә кайбер авылларда олы яшьтән өйләнү яки кияүгә бирү очраклары күзәтелә. Монсы шул авылларның тормыш дәрәҗәсе яки аерым бер үзенчәлегеме икән – өйрәнү өчен бер тема булып тора.

Шунсы кызык, гадәттә егетнең яше олырак була бит инде. Элек бигрәк тә олы булгандыр дип уйлаган идем. Юк икән, киресенчә, кызның яше олырак булган никахлар шактый, хәзер дә шулай ук.

Нинди генә авылларга таралмаган безнең кызларыбыз.

Иске Пенәгәр авылында 281 ләп билгеле булган никахлар арасында барлыгы 57 авыл 160 тапкыр телгә алына. Мәсәлән, Төркәш авылының китабы басылып чыкты. Анда хатын-кызларның 69 авылга кияүгә чыгуы турында язылган. Камышлы авылында авыл эчендәге никахлар бик сирәк. Берничә елга, мәсәлән, 30 никах арасында 2 генә күренә. Иң күп никахлар якындагы авыллар белән, сирәгрәкераграк авыллар белән күзәтелә. Тулаем алганда, гомуми нәтиҗә ясаганда, бик тыгыз бәйләнгән безнең авылларыбыз никах белән.

Никахлар вакытында егетләр кәләшләренә мәһәр бирергә тиеш булган. Безнең халыкта ул калым дип атала. Никах язмаларындагы калымнарга игътибар итик әле.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16.01. 1852 | Малмыж өязе **Пенәгәр** авылының ясашный зәригатче **Мостафа Мөхәммәдрахим** улының кызы 24 яшендә булучы **Мөхибҗамалны** шул ук **Пенәгәр** авылының ясашный зәригатче 21 яшендә булучы **Хөрәмша Гыйззәтулла** улына никахландырылды. | Кыз тарафыннан атасы **Мостафа Мөхәммәдрахим** улы вәли вәкил булды. Кияү тарафыннан атасы белән бер туган агасы **Мөфәхәр Гыззәтулла улы** вәли вәкил булды. Ир белән хатынның ризалыклары шаһидләре: әүвәл **Һибәтулла Сәлимҗан** улы тамгам салдым **Корбангали Бәкер** улы тамгам салдым. | Мәһәр мөсәмме йөз җитмеш сум. Хәзердә бер ат белән 14 арбалы арыш кибәне – йөз ун сум. Калганны мәзкүрә **Мөхибҗамал** сораган вакытта кияү булучы **Хөрәмша Гыйззәтулла** улы бирәчәк булып тамгам салдым. Мәзкүр шартка кызым **Мөхибҗамалның** ризалыгы белән вәли вәкил булучы атасы **Мостафа Мөхәммәдрахим** улы тамгам салдым. |
| 22.02. 1869 | Малмыж өязе **Пенәгәр** авылының ясашный зәригатче **Тимергали Корбангали** улының кызы 21 яшендә булучы **Бибикадичәне** Казан губернасы Мамадыш өязе **Мазарасты** авылының ясашный зәригатче 21 яшендә булучы **Габдрахман Галиәкбәр** улына никахландырылды. | Кыз тарафыннан атасы **Тимергали Корбангали** улы вәли вәкил булды. Кияү тарафыннан атасы **Галиәкбәр Габдерахим** улы вәли вәкил булды. Ир белән хатынның ризалыклары шаһидләре: **Әхмәдша Йосыф** улы тамгам салдым. **Ибраһим Йосыф** улы тамгам салдым. | Мәһәр мөсәмме йөз тәнкә. Хәзердә илле тәнкә. Әүүәл әдрәс (8 тәнкә) кашага (2), басма (2), ука (5), кәҗи (3), шәл (5), сандык (3), читек (2), яулык (2), 3 төрле ситсы (10 тәнкә), 9 тәнкә акча, калганны мәзкүрә **Бибикадичә** сораган вакытта кияүнең атасы **Галиәкбәр Габдрахим** улы бирәчәк булып тамгам салдым. Мәзкүр шартка разый булып атасы **Тимергали Корбангали** тамгам салдым. |

Никах язмаларында без нәсел тамгалары белән танышабыз. Тамгалар алар кул кую урынына да йөргән, үз әйберләрен дә халык тамгалап куйган. Яза белмәгәннән генә түгел, бу нәсел билгесе. Метрикаларда «язу яза белмәү сәбәпле кул куймады» дигән язмалар да очрый.

Өлкәннәр урманга баргач кисә торган агачларны тамгалый идек диләр. Бер-берсенең агачын ялгыш та кисмәгәннәр, тамга торган.

Икенче гыйбрәтле очрак турында безгә Раилә ханым сөйләде. Бура бураган урыннан күршеләре агач сатып җибәрә. Шул агачлар арасына ялгыш аларның да бер агачы килеп керә. Әтиләре шул икенче авылга сатылган бураны табып тамгасы ярдәмендә генә үзенең икәнен раслый алган. Агач өчен алып киткән кеше акчасын түләгән.

Халык санын алу материалларында да, метрикалар буенча да гаиләләрдә дә беренче, икенче, өченче хатын турында мәгълүматлар бар. Ислам дине ике-өч хатын алуны тыймый, әмма тигез күр, тәрбия кыл, ди. Өйрәнә торгач бу хатыннар бер кешенең ике-өч хатыны бар дигән сүз түгел, бәлки, беренчесеннән соң, икенчесен алган дигәне аңлашыла.

Аерылышулар бик аз булган. Нәрсә булган соң? Нигә икенче, өченче хатын алганнар? Яшьли үлемнәр күп булган. Хатын-кызларыбыз күп бала тапкан, аларның үзләрен тәрбия кылырга мөмкинлек булмаган. Ул балаларны шул шартларда ашатып, киендереп, тәрбия кылырга кирәк булган. Үлем сәбәпләрендә баладан вафат дигәннәре шактый күренә.

1860 елда чәчәк авыруыннан 10 яшькә кадәр 40 ка якын бала вафат була. Ул елны барлыгы авылда 64 җеназа укыла. Ай саен 5–6 кеше. 1865 елда 66 кеше вафат.

Иң күп үлемнәр яшьли булган үлемнәр. Сәбәпләренә килгәндә беренче урында зыяндаш авыруы, икенчедә ютәл, тамак авырулары тора. Хатын-кызлар арасында иң күбе ютәл, тамак авырулары күренә.

Метрикаларда бер дә хәмер эчеп вафат булды дигән нәрсә юк, дисәм дә дөрестер. Меңләгән үлем сәбәпләре арасында Пенәгәрдә бер мәртәбә очрады. Һәм тагын бер авылда бер шундый бер язма күренде. Бу да тарих.

Балаларын яшьли җирләгән хатын-кызларыбызга күпме кайгы-хәсрәт кичерергә туры килгәндер.

| Сакланып калган 38 ел метрикаларда **1005** кеше вафат булуы турында язылган (вафат булган яшьләре күрсәтелгән) | | | |
|---|---|---|---|
| **474** ир-ат | | **531** хатын-кыз | |
| 1 яшькә кадәр | **127** | 1 яшькә кадәр | **94** |
| 1–10 яшькә кадәр | **185** | 1–10 яшькә кадәр | **186** |
| 10–60 яшькә кадәр | **93** | 10–60 яшькә кадәр | **196** |
| 60 яшьтән өлкән | **69** | 60 яшьтән өлкән | **55** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 яшькә кадәр **312 малай** | | 10 яшькә кадәр **280 кыз бала** | |
| 10 яшькә кадәр барлыгы **592 бала** | | | |
| Бер елга уртача **26** кеше вафат була, шулардан бер елга уртача **16 сы** балалар (10 яшькә кадәр) | | | |
| 10 нан 60 яшькә кадәр уртача елга **7–8** кеше, 60 яшьтән узганнар елга уртача **3** кеше. | | | |
| 11 ел ярымда **279** кеше вафат буган | | | |
| **145** ир-ат | | **134** хатын-кыз | |
| 1 яшькә кадәр | **10** | | |
| 1–10 яшькә кадәр | | 1–10 яшькә кадәр | |
| 10–30 яшькә кадәр | **9** | 10–30 яшькә кадәр | **3** |
| 30–40 яшькә кадәр | **4** | 30–40 яшькә кадәр | **1** |
| 40–50 яшькә кадәр | **19** | 40–50 яшькә кадәр | **3** |
| 50–60 яшькә кадәр | **26** | 50–60 яшькә кадәр | **7** |
| 60–70 яшькә кадәр | **26** | 60–70 яшькә кадәр | **17** |
| 70–80 яшькә кадәр | **24** | 70–80 яшькә кадәр | **42** |
| 80–90 яшькә кадәр | **27** | 80–90 яшькә кадәр | **46** |
| 90 яшьтән өлкән | | 90 яшьтән өлкән | **18** |
| 60 яшькә кадәр **68 ир-ат** | | 60 яшькә кадәр **14 хатын-кыз** | |
| 60 яшькә кадәр барысы **82 кеше** | | | |
| 60 яшьтән соң барысы **200 кеше** | | 60 яшьтән соң **123 хатын-кыз** | |
| Бер елга уртача **24** кеше вафат була, шулардан бер елга уртача **7 се** (60 яшькә кадәр), калганнары **17** сы (60 яшьтән соң) | | | |

Метрикалар барысы да гарәп хәрефләре белән үз телебездә язылган. Укыр өчен җиңел түгел, бераз игътибар булуны сорый. Метрикаларны һәр авылның үз имамы алып барган. Һәрберсенең язуы үзгә. Беренче битендә авылның үз чорындагы чын исемен, мулланың указлымы, юкмы икәнен күрергә мөмкин, тулы исеме фамилиясе белән бирелә. Мәсәлән, Балыклы авылының метрикасының титул битендә «Книга Мамадышского уезда деревни Балыклы указного муллы Сайфутдина Зябирова на 1830 год», дип язылган.

Авылларының тарихы белән кызыксынучылар, нәсел шәҗәрәсен өйрәнүчеләр, бигрәк тә авыл имамнары өчен метрикалар бәһасез чыганак булып торалар, алга таба тирәнтен өйрәнүне таләп итәләр.

## ИРЕК МӘЙДАНЫ: БӘХӘС КЛУБЫ

## ПЛОЩАДЬ СВОБОДЫ: ДИСКУССИОННЫЙ КЛУБ

*Рифат Каюмов*

### ЧУДЕСА ПЕРЕПИСИ: КАК В ТЕЧЕНИЕ 30 ЛЕТ СОКРАЩАЛАСЬ ЧИСЛЕННОСТЬ ТАТАР В БАШКОРТОСТАНЕ

Исследователь из Башкортостана на основе данных четырех переписей в период с 1979 по 2010 гг. проследил, как официальное число татар в татарских районах республики сокращалось в пользу роста численности башкир. Но количество жителей, указывающих родным языком татарский, остается стабильно высоким. С докладом ознакомился корреспондент «Интертат». «Миллиард.Татар» публикует перевод статьи.

#### Открытия ученых из Башкортостана

На организованной Институтом Татарской энциклопедии и регионоведения всероссийской конференции были приведены очень интересные данные, касающиеся результатов переписи в Башкортостане в период между 1979 и 2010 гг. Доклад на эту тему прочитал аспирант Института этнологических исследований им. Раиля Кузеева Комил Сиразетдинов. Именно прочитал – поскольку доклад подготовлен его научным руководителем, профессором упомянутого института, доктором исторических наук Фаилем Сафиным. Сам ученый на конференцию приехать не смог. Озвученные в докладе данные вызывают изумление – от переписи к переписи цифры делают аномальные скачки то в одну, то в другую сторону, но в большинстве случаев – в пользу роста численности башкир.

Проводимую в Башкортостане политику этнолог Фаиль Сафин показал на примере нескольких районов. О занижении численности татар в Башкортостане говорится давно, однако, пожалуй, впервые это предстает как факт, подтвержденный официальными цифрами. Комил Сиразетдинов от имени автора просил не обнародовать доклад, однако, будучи приглашенными на конференцию в качестве журналистов, мы сочли необходимым поделиться интересной информацией.

Всероссийская конференция с участием историков-аграрников, археологов, этнографов и других специалистов Евразии «Историко-культурное наследие российской деревни: сохранение и развитие» была по-

священа проблемам сохранения самобытного национально-культурного наследия народов России, в том числе, татар в их местах компактного проживания.

Итак, как же менялись итоги переписи на территории Башкортостана?

**Бакалинский район**

В Бакалинском районе в 2002 г. оказалось, что с 1989 г. (предыдущая перепись) башкир в районе стало больше на 3560 человек, а татар меньше на 3383 человека. К следующей переписи численность башкир, наоборот, уменьшилась на 1312 человек, и башкиры составили 17,3% всего населения района. Численность татар пропорционально увеличилась.

В докладе отмечается, что жители района, записанные как башкиры, в графе «Родной язык» указывали «татарский». Такое явление наблюдалось в переписи 1979 г.: в Бакалинском районе официальное число башкир – 6829 человек, и только 415 человек из них родным языком указали башкирский (всего 6,1%). Такая же тенденция сохранялась в 1989 г. – 2716 человек записались как «башкир», но башкирский язык своим родным языком признали лишь 244 человека (8,9%), а остальные 2441 человек, то есть 89,9%, своим родным языком назвали татарский.

В 2002 г. башкирами записались 6276 человек, но только 629 человек родным языком указали башкирский – 10%. Соответственно, 5516 человек родным языком назвали татарский язык. Другими словами, в 2002 г. 87,9% «башкир» в Бакалинском районе были татароязычными.

В промежутке между переписями 1979 и 1989 гг. количество тех, кто родным языком назвал татарский, увеличилось на 0,4%. А к 2002 г. этот показатель снизился на 2,6%. Автор исследования связывает это с ущемлением татарского языка в пользу русского языка, которое наблюдалось в те годы не только в Бакалинском районе, но и по всей республике. В 2002 г. 94,9% татар родным языком назвали татарский язык.

По результатам переписи 2010 г. продолжается расхождение в данных о национальной принадлежности и родном языке – у подавляющего большинства записавшихся «башкирами» родной язык не соответствует этой национальности. Так, всего по району записаны 4964 «башкира», однако 73 процента из этих людей своим родным языком считают татарский. Таким образом, несмотря на различные манипуляции по национальной идентичности, в Бакалинском районе численность татароязычного населения остается стабильной, резюмирует ученый в своем докладе.

**Балтачевский район**

В также расположенном на северо-западе Башкортостана Балтачевском районе в 2002 г. башкир по непонятной причине стало больше на 11 797 человек (в 3,1 раза), тогда как татар стало меньше в 4 раза (минус

11 092 человека). Если к переписи 1989 г. татары составляли 59,2% населения района, то в 2002 г. – лишь 14,7%.

Перепись 2010 г. – и численность татар увеличивается, но всего в 2 раза (плюс 6700 человек). По официальным данным, в том году татары составляли 31,2% населения района.

Что касается идентичности населения, то в 2010 г. из 10 962 человек, записанных как «башкир», 7819 человек родным языком указали татарский (71,3%). В то же время из записавшихся татарами 6701 человека 6613 человек, то есть, 98,7%, родным языком назвали татарский. Только четыре человека родным языком указали башкирский и 54 человека – русский язык. Таким образом, абсолютное большинство жителей Балтачевского района являются татароязычными.

**Бураевский район**

В Бураевском районе также наблюдаются колебания в данных переписи: в 2002 г. башкир в районе стало в 2 раза больше – 11 307 человек. А численность татар уменьшилась сразу на 5,6% (минус 12 413 человек). Если в 1989 г. в Бураевском районе татар было 50,8%, то в 2002 г. этот показатель снизили до 9,5%. В 2010 г. численность татар решили увеличить в 2 раза и сократить число «башкир» на 5 тыс. человек (с учетом того, что ранее численность татар была уменьшена в 5,6 раза, то в 2010 г. этот показатель не смог вернуться до своих прежних значений). Из 17 401 человека, указавших свою национальность как «башкир», 15 695 человек, то есть 90,2%, своим родным языком признали татарский язык.

**Кушнаренковский и Благоварский районы**

В Кушнаренковском районе данные переписи 2002 г. говорят о беспрецедентном росте численности башкирского населения. С 1989 по 2002 гг. башкир стало в 8 раз больше (плюс 11 121 человек). Если в 1989 г. башкирами себя указали 1899 жителей района, то в 2002-м – уже 12 472 человека, тем самым, официальная численность башкир в промежутке между двумя переписями увеличилась в 6,6 раза. Одновременно с этим татар в Кушнаренковском районе стало меньше на 10 591 человека, а в Благоварском районе – на 8565 человек. В 2010 г. наблюдается обратная тенденция – татар становится больше, а численность башкир несколько сокращается.

**Туймазинский, Чекмагушевский, Шаранский, Ермекеевский, Илишевский районы**

Проведенная в 2002 г. перепись населения показала, что в ряде районов Башкортостана резко прибавилось жителей башкирской национальности, а численность татар заметно сократилась. В Туймазинском районе

башкиры – плюс 8927 человек, татары – минус 8871 человек. В Чекмагушевском районе башкир стало больше на 5338 человек, татар – меньше на 5685 человек. В Шаранском районе башкир стало больше на 6089 человек, татар – меньше на 5485 человек. В Ермекеевском районе численность башкир выросла на 6371 человека, численность татар сократилась на 6078 человек. В Илишевском районе башкир прибавилось на 6271 человека, а татар убавилось на 6049 человек. Не трудно заметить, что численность башкир увеличивалась примерно в том же количестве, в котором уменьшалась численность татар.

В 2010 г. в этих районах наблюдается обратная тенденция – увеличение численности татар и сокращение численности башкир.

Что касается графы «Родной язык», то, к примеру, в Илишевском районе в 1989 г. 96,4% «башкир» своим родным языком указали татарский. В 2002 г. этот показатель по-прежнему высок – 91,3%. И только 3,3% из записавшихся башкирами жителей родным языком назвали башкирский язык.

### «Язык жителей северо-запада Башкортостана невозможно рассматривать как башкирский язык»

«Проведенные Фаилем Сафиным и Р.Г. Сибгатовым исследования не показывают переход разговорной речи проживающего в этом регионе местного населения на башкирский язык. Тридцать лет назад они продолжали разговаривать так же, как и 90 лет назад. Это зафиксировано в данных переписи 1926 г. и лингвистических исследованиях, проведенных в этих районах в 1930-х гг.. Признание некоторыми учеными языка населения этого региона северо-западным диалектом [башкирского языка] не оправдано», – говорится в докладе.

Ученый также напоминает, что известные башкирские лингвисты Юлдашев и Бикбаев считали невозможным включить говор жителей северо-запада Башкортостана в систему башкирского языка.

«Язык жителей запада и северо-запада Башкортостана как в историческом, так и в юридическом аспекте невозможно рассматривать как башкирский язык. По мнению некоторых теоретиков, этнос и его язык формируются в одно и то же время. Известный башкирский историк, теоретик по национальным отношениям Юлдашбаев утверждает, что «в процессе формирования башкир как единой нации башкирский язык развивался из двух диалектов – юрматинского и куваканского». В то же время он давно подчеркивал, что «язык жителей запада и северо-запада Башкортостана не башкирский, а татарский язык», – пишет в своем докладе Фаиль Сафин.

Далее ученый обращает внимание на резкие скачки цифр в графе «Родной язык» в некоторых районах Башкортостана. Так, в Аскинском

районе с 1979 по 2002 гг. число тех, кто считает родным языком башкирский, многократно увеличилось. Если в 1979 г. только 5,1% из записавшихся башкирами жителей родным языком называли башкирский, но уже к 1989 г. таких стало 41%, а в 2002 г. – целых 83,9%. Подобное происходит только в Аскинском и Татышлинском районах, в других районах республики такое не наблюдается, отмечает ученый, подчеркнув, что «это парадоксальное явление не поддается научному обоснованию и объяснению».

В том же Аскинском районе в 1979 г. 94,6% записанных башкирами жителей своим родным языком указывали татарский язык (16 541 человек из 17 489). В 1989 г. этот показатель снизился до 58% (8696 человек родным языком признавали татарский язык).

Таким образом, проанализировав данные переписей 1979, 1989, 2002 и 2010 гг. в Башкортостане, ученый Фаиль Сафин приходит к выводу, что, невзирая на имеющиеся в ходе переписи населения административные манипуляции, в Башкортостане татарская идентичность остается стабильной.

*Взято: https://milliard.tatar/news/cudesa-perepisi-kak-v-tecenie-30-let-sokrashhalas-cislennost-tatar-v-baskortostane-2220*

*Бибинур Сабирова*

## СЕБЕРДӘ ТАТАРЛАРНЫ КЕМНӘР ТАРКАТА?

*«Азатлык» радиосы сайтында чыккан «Себер татарларына кемнәр ят?» дип аталган язма уйландырды, үткәннәрдә милли хәрәкәттә булган хаталарны, югалтуларны да искә төшерде.*

Төмән дәүләт университеты бинасының бер бүлмәсендә генә шактый еллардан бирле профессор Хәнисә Алишина җәмәгатьчелек нигезендә торкан Тюркология үзәгенең университет ректоры фәрманы белән себер татарлары телен өйрәнүче үзәккә әверелдерергә җыенуы хакында иде ул язма. Бу үзәкнең оештырылуы бер яктан сөендерсә, икенче яктан, борчулы уйларга сала, чөнки хөкүмәт тарафыннан аның төп максаты итеп себер татарларын ят йогынтыдан саклау, дип билгеләнгән, ә ят йогынты Татарстаннан килә икән. Бу фикер күптән йөри Төмән-Тубыл якларында. Мин моңа карата үз фикеремне чынбарлык гамәли тормыш күзлегеннән чыгып әйтәм, фәнгә тирән керми генә.

Әлегә кадәр Татарстан Себердә татар мәгърифәтен үстерү өчен ифрат зур ярдәм күрсәтеп килде, тел галимнәре үстереп бирде. Тубыл педагогия институты каршында берничә ел эшләп алган тел һәм әдәбият буенча диссертацияләр яклау Советы да Татарстан ярдәмендә оешкан иде, Татарстан Республикасы галимнәре ярдәмендә себер татарларыннан 20 дән артык филология фәннәре кандидатларын чыгарды ул Совет. Себер татарларының азсанлы халык статусын алуга Себердә яшәүче казан татарлары гына түгел, Татарстан да бернинди каршылык күрсәтмәде, «алар каршы» дигән сүзләр – уйдырма. 2000 елның июнь аенда Бөтендөнья татар конгрессы Идарәсенең һәм Федераль татар милли-мәдәни мохтәрият Шурасының Төмәндә күчмә утырышы булды. Әхтәм Каюмов җитәкчелегендәге «Себер татарлары һәм Төмән өлкәсендә яшәүче татарлар милли-мәдәни мохтәрияте» каршы алды БТК рәисе академик Индус Таһиров җитәкчелегендәге Казан һәм күрше регионнар делегацияләрен, өлкә Хакимияте бинасының мәһабәт конференцияләр залында өлкә җитәкчеләре катнашы белән тантаналы төстә, югары дәрәҗәдә үтте ул җыен. Җыен карарларында мондый пункт та бар: «Оказать помощь сибирским татарам в местах компактного их проживания в Тюменской и других областях в получении статуса «коренной малочисленный народ региона РФ». Үзенең ачылу максатын «во избежание влияния извне» дип билгеләгән «Себер татарлары телен өйрәнү үзәге»нең мөдире итеп университет ректоры фәрманы белән билгеләнгән Хәнисә Алишина ул Үзәкнең максатларын ачмый тора, ә менә себер татарларын аерым халык итеп татар дөньясыннан аерып чыгару өчен көрәш алып баручыларның берсе Нәсия

Уразова ачыктан ачык белдерә Идел буе татарларына агрессив мөнәсәбәтен: «Бераз булса да себер татарларыннан читләшеп торыгыз, чылбырдан ычкынган этләр кебек булмагыз!» – ди бит ул татар халкын төрле этник төркемнәргә бүлгәләп таркатмаска кирәк, дигән фикер әйткән милләттәшләребезгә җавап итеп. Себер татарларын киң күңелле, юмарт халык, дип әйтүе белән килешәм. Себердә туып үскән, себер татарлары белән бергә укыган, себер татарлары авылларында балалар укыткан, себер татарлары белән катнаш гаиләләр корып туганлашкан нәсел вәкиле буларак, мин дә яхшы беләм себер татарларын. Сабыр, җыр-моңга бай, киң күңелле юмарт халык себер татарлары, чынлап та, ә менә Нәсиягә кадәр безне «чылбырдан ычкынган этләр» белән чагыштыручы булмаган иде алар арасында. Нәсиянең барлык себер татарлары исеменнән нәтиҗәләр чыгарып әйтергә хакы да юк, чөнки ул аларның рухи халәтен җентекләп өйрәнгән кеше түгел. Аларның миңа үз фикеремне әйткән өчен ризасызлык белдерәчәкләрен алдан чамалап торсам да, эндәшми кала алмыйм, чөнки себер татарлары – минем газиз халкым. Казан татарларын төрлечә гаепләүләр күп булды инде, күнегелгән, монысын да кичерермен. Минем, озын гомерем буе себер татарлары белән якын аралашып яшәгән, мәгариф системасының барлык баскычларын үткән (укытучы, мәктәп мөдире, инспектор, методист, өлкә Укытучылар белемен күтәрү институтның милли мәктәпләр кабинеты мөдире), соңрак журналист буларак та аларның тарихын, гореф-гадәтләрен менталитетларын өйрәнгән кеше буларак, үз фикеремне генә түгел, күпчелек себер татарларының минем фикерләрем белән уртак уй-фикерләрен халыкка җиткерергә хакым бар, дип уйлыйм.

Себер татарларын аерым халык итеп таныту хәрәкәтендә ялгыш фикерләргә килүчеләр (бу эштә казан татарлары каршылык күрсәтә, алардан аерылырга кирәк, себер татар теле татар теле белән уртаклыгы булмаган аерым тел, дигән һәм башка фикерләр) татар мәктәпләрендә белем алмаган, әдәби телне өйрәнми калган тел галимнәренең йөрәкләре дөрләп яна, аларга җәмәгатьчелек вәкилләре дә кушыла. Шуларның берсе менә – Нәсия Уразова.

Нәсия татар мәктәбендә укымаган, әдәби телне белми, халык фикере белән дә кызыксынмый. Ул Тубыл мәдәният үзәгендә эшләп алганнан соң, Төмәнгә килеп край музеена эшкә керде, аннан Хәмит Ярми мирасына хыянәт итүе сәбәпле куылды – моңа музей архивы мөдире Елена Усольцева сөйләгән аудиоязма дәлил, ул язма миндә саклана. Әдәби телдә бер татар китабы укымаган көенчә, ул, Флора Әхмәтова-Урманченың кандидатлык диссертациясенә ияреп, «Татар прозасында халык авыз иҗатының чагылышы турында Хәмит Ярми» дигән темага кандидатлык

диссертациясен яклады да, Себердә үзенә урын таба алмаганнанмы, Хәмит Ярми мирасының саллы өлешен юкка чыгаруы ачылу сәбәплеме, Төркиягә китеп тә барды, инде хәзер аннан Идел буе татарлары белән бернинди уртаклыгы юклыгын исбатларга маташып ята.

Ә менә кандидатлык диссертациясен яклаганда аңа Флора Әхмәтованың Идел буе татар язучылары әсәрләре нигезендә язылган диссертациясе дә, татар халкын бербөтен миллләт итеп карап Казанда яшәп һәм иҗат итеп танылган фольклорчы-галим – якташыбыз Хәмит Ярминең фәнни мирасы да бик кирәк булды, ул вакытта ул үзен татар итеп хис иткәндер, мөгаен. Хәмит Ярминең Төмәнгә кайтарылган фәнни мирасын кулына төшереп үзләштергәч, докторлык диссертациясе әзерлеге турында да хәбәр чыгарган иде, никтер якламый гына китеп барды Төркиягә, инде анда «Әлиппа» язган икән. Әлиппа да кирәк кирәген...

1990 нчы еллар башында Укытучылар белемен күтәрү институты каршындагы себер татарларының телен, тарихын, мәдәниятен өйрәнүче лаборатория «Әлиппа» эшләп бастырып чыгарган иде, аның авторы Сания Хәйретдин кызы Насыйбуллина. Институтның мөдире Ада Китайгородская мине дә чакырган иде себер татарлары Әлифбасын булдыруга багышланган киңәшмәгә (мин инде лаеклы ялда идем), лабораториянең фәнни хезмәткәре (читтән торып) Казан дәүләт университеты профессоры, себер татарлары телен фәнни тикшереп өйрәнгән галим, Диләрә Гариф кызы Тумашева да килгән иде. Мин тәҗрибәле укытучыларның уртак фикерен җиткердем киңәшмәдә катнашучыларга: әгәр дә Әлифба себер татар шивәсендә генә бастырылып чыгарылса, аны мәктәпләр кабул итмәячәкләр. Аны болай эшләргә кирәк: бер бите әдәби телдә, икенчесе – шул ук материал себер татар телендә. Әдәби телне укытуны ана теле укытучылары себер татарлары шивәсенә таянып, икесен чагыштыру юлы белән алып баралар, әмма телдән генә, язма ярдәмлек әсбаплар юк. Әлифба ике телдә эшләнелсә, укытучылар аны рәхмәтле булып кабул итәчәкләр һәм аны рәхәтләнеп кулланачаклар. Бу фикер исәпкә алынмады, «Әлиппа» чыкты, ләкин аны бер мәктәп тә кабул итмәде, чөнки себертатар телендә аннан соң кулланырга дәреслекләр юк иде, бүгенгә кадәр дә шулай.

Лабораториянең җитәкчесе итеп тарих фәннәре кандидаты Ильяс Рафиков билгеләнде. Ильяс татар дөньясына килеп кенә кергән иде, үзенең туган себер татар шивәсен әбисеннән отып калган кадәрле генә белә, сүз әйтмәде, чөнки бу хакта фикер әйтерлек әзерлеге юк иде. Диләрә апа да фикер әйтмәде «Әлиппа»га карата, чөнки аның Себердә татар телен укыту методикасы белән шөгыльләнгәне булмады, гәрчә кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре себер татарларының диалектларын фәнни тикшерүгә

багышланган булса да. Сания ханым Насыйбуллина Төмән шәһәренең рус мәктәпләрендә рус телен һәм әдәбиятын укыткан, ул вакытта татар мәктәпләрендә татар телен ничек укытылуы белән таныш түгел иде. Соңрак төшенде ул аның серләренә, Диләрә Тумашева җитәкчелегендә Казанда филология фәннәре кандидатлыгына диссертация да яклады.

Озак яшәмәде ул лаборатория, Укытучылар белемен күтәрү институты Төбәк мәгарифен үстерү институтына әверелгәннән соң таркалды, татар теле буенча бер фәнни хезмәткәргә калды, бүгенге көндә анда милли мәгариф буенча бер белгеч-хезмәткәр дә юк. Татар җәмәгатьчелегенең моңа да исе китмәде. Югарыда әйтелгән себер татарлары телен өйрәнү үзәге әнә шул лабораторияне хәтерләтә. Булат Сөләйманов укулары кысаларында үткәрелә торган фәнни-гамәли конференцяләрдә дә себер татарлары тарихы, әдәбият татар дөньясына бәйле каралмады, аерым себер татарыныкы булып кына каралып килә.

Нәсия шуны да белми: Себердә әдәби телне укыту традициясе тирән тамырлы, бик бай, бүгенге көндә себер татарлары ул язганча түгел, әдәбигә якынрак итеп сөйләшәләр. Себерчә генә басылып чыккан китапларны авырсынып укыйлар алар, без бит алай ук саңгыраулатмыйбыз телебезне, диләр. Себер татарларының өч төп диалектлары гына түгел (тобол-иртыш, бараба, том), Тобол-Иртыш төбәге татарларының төрле районнардагы сөйләшләре дә бер-берсеннән аерылып тора. Кайсы диалектны аерым себер татар теле итеп мәктәпкә кертмәкче була икән тубыллы Нәсия Уразова? Себер татарларының уртак әдәби теле формалашмаган, дәреслекләр дә булмау сәбәпле себер татар телен аерым туган тел итеп мәктәпкә кертү мөмкин булмады, әле дә мөмкин түгел. Себер татарлары телен аерым тел итеп мәктәпләрдә укыту таләбенең шаукымы мәктәпләрдә татар телен укытуга зур зыян китереп кенә калмады, гомумән татар милли-мәдәни үсешен дә тоткарлады, урыслашуны тизләтте.

Бер-береннән ерак төбәкләр генә түгел, бер тирәдәге авыллар да Себерә башкаларыннан тел үзенчәлекләре белән аерылып торалар. Бер Казанга баруымда троллейбуста барам, яныма бер татар ир-заты килеп утырды, көтмәгәндә үзенең кайгы-хәсрәте белән уртаклаша башлады минем белән, әнисен җирләгән көне икән. Таныш булмаган кешеләр белән сөйләшергә яратмасам да, мин тыңладым бу кайгылы милләттәшемне. Кинәт әйтеп салды ул: «Сез, ахырысы, я табиб, я укытучыдыр?» Аның соравына җавап бирү урынына: «Мин дә сезне беләм, сез Апастан», дип әйтүемне сизми дә калдым, ул кинәт утырган урыныннан сикереп торырлык булып тайпылды: «Кайдан беләсез мине, кем сез?!» – дип ялварып калды. Минем аңа җавап бирерлек вакытым калмаган, тукталышыма килеп җиткән идем. Аны тыңлаганда мин Себергә бабайлар Апас төбәген-

нән узган гасыр башында Столыпин аграр реформасы буенча килеп төзегән туган авылымда калган бәхетле балачагыма әйләнеп кайткандай, анам теле бишегендә тибрәлгәндәй сиздем үземне. Янымда утырган кеше нәкъ безнең авылча, димәк, апасча сөйләште, хәтта көе дә безнең авыл сөйләшенең көе иде. Ул сөйләшне Себердә безнең әби-бабайлар түкми-чәчми саклаганнар, буыннардан-буыннарга бирелгән ул. Һәркемгә кадерле күкрәк сөте белән бергә җанга иңгән газиз ана теле, бишек теле, мин туганнарым белән аралашканда шул телдә – гаиләм телендә сөйләшәм, татар дөньясына чыксам, уртак әдәби телгә күчкәнемне сизми дә калам, табигый күчеш ул. Себер татарларының ана телләрен саклау омтылышы миңа аңлаешлы, изге гамәл ул, әмма һәр төбәкнең телен аерым тел итеп карау мөмкин түгел ләбаса. Татарстанның үзендә дә татар теленең төрле сөйләшләре, диалектлары бар.

Еллар уза барган саен заманалар үзгәрә, тел дә үзгәрә. Себер татарлары белән Идел буе татарлары арасында күп еллар дәвамында булган тыгыз элемтәләр нәтиҗәсендә себер татарлары теле әдәбигә якынлашкан, бу турыда үзенең фәнни хезмәтендә Тубыл педагогия институтының татар теле кафедрасында хезмәт иткән филология фәннәре кандидаты Клим Садыйков та әйткән иде. Бүгенге көндә дәүләтчелеге, уртак әдәби теле булмаган себер татарларын борынгы телгә кире кайтарырга тырышу нәтиҗә бирми, Төмән –Иртыш буе татарлары, Омски татарлары, бараба татарлары өчен уртак әдәби тел формалаштыру өчен мөмкинлекләр чикле, чөнки себер татарлары яшәгән төбәкләр таркау, бер-берләреннән ерак, башка сәбәпләр дә җитәрлек.

Сәламәтлегем өчен климат алыштыру сәбәпле Ташкент-Ферганә якларында яшәп алдым мин, күпмилләтле катнаш мәктәптә рус телен укыттым, үзбәк, кыргыз, таҗик, рус класслары аерым булды, 15 тел укытучысының 14 – руслар иде. Алар арасында бер мин тугандаш төрки телләрне тиз өйрәндем, коллегаларыма ярдәмче-методист та идем, таҗик телен генә өйрәнеп җиткерә алмадым, чөнки ул төрки тел түгел.

Себер татарларының теле төрле төрки халыклар телләре йогынтысында, алтайлылардан башлап, формалашкан, шуның нәтиҗәсендә себер татарлары теленең төрле диалектлары барлыкка килгән. Себер татарлары фольклоры дөньясына кереп карасаң да, себер татарларының борынгы заманнардан бирле башка төрки халыклар, шул исәптән Идел буе татарлары белән дә икътисади-мәдәни багланышлары нык булганын күрәсең – бу да телгә йогынты ясамый калмаган. Галим-этнограф Дамир Исхаковның фәнни ачышларында Себер татарларының Идел буе татарлары белән багланышлары Себер ханлыгы формалашканга кадәр булганлыгын күрәсең. Соңгы гасырларда Идел-Урал татарлары теленең

йогынтысы көчле булу сәбәпле себер татарларының теле гомумтатар әдәби телгә якынлашкан. Себер татар теле белән гомумтатар әдәби тел арасындагы уртаклык кыпчак теленнән дә килә: кыпчаклар Идел буе татарлары этногенезында да, себер татарлары этногенезында да катнашкан. Мин өлкәнең көньягында себер татарлары сөйләшенең нигезендә үзбәк телен ишетсәм, Тубыл районының сазлар арасындагы Лайтамак, Вәчир авылларында кыргыз теле йогынтысын сизәм. Ә менә Вагай районының иң ерак авылларының берсе, шулай ук сазлар, күлләр арасында утырган Усак (Аусак) авылында себер теленә хас «ц»ләштереп түгел, урыс яңгырашында «ч»ләштереп сөйләшүләре казан татарларыннан, дип уйлыйм, тик «ч» авазы йомшаклыгын югалткан, дип фаразлыйм, әмма шуңа фәнни нигез таба алганым юк, ул авыл кешеләре үзләре дә белмиләр аның сәбәбен. Мин Төмән өлкәсе себер татарлары телен яхшы беләм, дип әйтә алам, ә Ом өлкәсенең бер районыннан чыккан укытучының сөйләшүен беренче ишеткәндә миңа тәрҗемәче ярдәме кирәк булды. Менә нигә кирәк һәр татарга да әдәби телне белү – аралашу, берләшү теле дә ул. Себернең үзәге – Күкрәнде авылыннан (Тубыл районы) чыккан, Казанда яшәп фольклор дөньясында хезмәт итеп танылган галимә Флора Әхмәтова-Урманченың якташларыбызга юллаган «Кадерлеләрем, якташларым, кардәш-кабиләм!» дип атаган хатында мондый сүзләр бар иде: «...Күрәсез, алда язылган һәммә матбугат безнеке, аны безнең кешеләр эшләгән, безнекеләр укыган. Бу уртак тел, уртак тарих. Без бөтен татар белән бергә тузга да, ташка да, чөй белән дә, каурый белән дә язганбыз...» («Ак калфак» №2, 1999 ел, Төмән).

Себер татар теле нык аерыла бит әдәби телдән, аны аерым тел итеп карарга буладыр, дигән фикер Казан галимнәре арасында да яңгырагалады. Ә менә миңа нык аерыла кебек сизелми, теләсә төбәк сөйләшен үз анам теле кебек кабул итәм,чөнки без, себерле һәм казанлылар, монда бер «казанда кайныйбыз», бер-беребезне аңлыйбыз. Соңгы 100 еллар дәвамында Себердә татарның этник төркемнәре аерылгысыз булып бергә уралган, себер татар әдәби тел формалашмый калган, себер татарлары телен аерым тел итеп ясау заманы үткәнме, үтмәгәнме – мин бу турыда өздереп әйтә алмыйм, әмма шуны әйтә алам – ике тел арасында уртаклык көчәйгән, шунлыктан себер татар телен әдәби телдән аерып үстерү уңай нәтиҗә бирмәгәнен чынбарлык яшәешебез үзе раслады.

Соңгы 30 ел дәвамында себер татарларының әдәби телен формалаштыру кирәклеге турында сөйләшүләр, әмма барлык себер татар төркемнәрен дә канәгатьләндергән алфавит әле дә төзелеп бетмәде. Казан татарлары, Татарстан тарафыннан каршылык булмады бит бу эштә, шунлыктан гомумтатар әдәби тел Себердә яшәүче татарларның мәдәни тормышында,

мәктәпләрдә укытыла. 1930 елда ачылып, 1955 елга кадәр эшләгән татар педагогия техникумы 1500 укытучы әзерләп чыгарган, аларны чын татар мәгърифәтчеләре итеп әзерләгән ул уку йорты, алар әдәби телдә укытканнар, халык арасында мәгърифәти эшчәнлек тә алып барганнар. Ул педагогия училищесының үз заманында Себер татарлары мәгърифәте өчен әһәмияте татар дөньясы өчен Мөхәммәдия мәдрәсәсеннән ким түгел, дисәм дә, ялгыш булмас кебек. 1953 елдан 1959 елга кадәр Тубыл педагогия институты каршында эшләгән рус-татар бүлеге 250 рус һәм татар теле укытучылары әзерләп чыгарган, аларны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап килгән белгечләр укытканнар, әдәби тел осталары булып чыкканнар анда укып белеп алган укытучылар. 1990 елда Тубыл педагогия институты каршында ачылган татар теле һәм әдәбияты кафедрасы 1991 елга кадәр эшләде, татар мәктәпләре өчен рус теле һәм татар теле укытучылары әзерләп чыгарды, шул ук елларда Төмән дәүләт университетында да татар теле укытучылары әзерли торган төркем булды, ул төркемдә себер татар телен өйрәнүгә игътибар аеруча җитди булды. Мин Төмәндә татар китапханәсеннән татар язучылары китапларын алып укып үстем, ул күптән ябылган иде инде. 1990 елларда өлкә фәнни китапханәсендә милли китаплар бүлеге эшләп алды, аңа да китаплар башлыча Казаннан китерелде, ул бүлек тә әдәби телне саклауга үзеннән зур өлеш кертте. Хәзер себер татар телендә дә иҗат итәләр каләм тибрәтүчеләр, китаплары әдәби телдә язылган китапларга караганда тизрәк бастырылып чыгарыла, әмма ул китаплар мәктәпләргә ургылып керә алмыйлар, чөнки алар балалар өчен язылмаган – татар теле укытучылары шулай аңлаталар. Ул китаплар бүгенге себер татар сөйләшендә булса (борынгылыкка тартылмыйча), мәктәпләргә керү җиңелрәк булыр иде аларга, дигән нәтиҗә үзеннән-үзе сорала. Мәсәлән, су – сыу дип языла икән, бүгенге себер татары шулай язылуны кабул итәме? «Сыу»ны фәндә калдырып, гамәлдә «су» кулланылса, себер татар телендә язылган әсәрләрне себерлеләрнең үзләренә уку җиңелрәк булмасмы?

Әмма әдәби иҗатта каләм тибрәтүчеләргә тиешле ярдәм күрсәтүче, алар арасында һәм китап укучылар арасында фикер алышуны оештыручы, шәхесләрме, оешмалармы, юк. Бар ул һәвәскәр язучыларны берләштерүче оешмалар: «Яңарыш» газетасы каршында Хәнисә Алишина җитәкләгән «Әдәби Төмән» оешмасы, Төмән татар мәдәният үзәге нигезендә Клара Кучковская җитәкләгән, Максим Сәгыйдуллин үз канаты астында тоткан «Себер татар язучылар берлеге», тик алар әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнмиләр, гәрчә аларның иҗатына югары бәя биреп мәкаләләр язучылар булса да. Әдәби тәнкыйть тумый калды бездә,

шунлыктан әдәби иҗатта, әдәби телдәме, себер татар телендәме, язылган әсәрләр, китаплар саны артканнан-артып барса да, сыйфат үсә алмый.

Тәҗрибә шуны күрсәтә: әдәби телне бүгенге себер татар теленнән – җирле шивәдән аермый, икесен бергә өйрәнеп алып барганда гына татар телен саклап калырга була Себердә. Хәзер, туган телне саклау кыенлашкан саен, татар теле укытучылары дәресләрен өч телдә алып барырга мәҗбүр – әдәби татар, җирле шивә һәм рус теле ярдәмендә дә, шулай үткәрелгән уңышлы дәресләрне күргәләдем мин мәктәпләрдә. Мәктәпләргә җирле шивәне факультатив итеп кертергә кирәк, дигән фикер яңгырады, шуны гамәлгә ашыру омтылышы да булды, тик шуның өчен укытучылар гына табылмады. Эш тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: әдәби тел белән себер татар теленең табигый рәвештә барлыкка килгән аерылгысыз бердәмлеген җимерү халыкны тупикка гына алып керәчәк, урыслашуга китерәчәк. Ике телне бер системага салып өйрәнгәндә, укытканда һәм кулланганда гына татар телен саклап калып булачак Себердә. Тик бу эш белән шөгыльләнүче галимнәр юк, булган галимнәр аерымлыкны тирәнгәрәк килеп өйрәнергә тырышалар.

Себер татарларының культурасы дигәннән, Себердә дә – Ислам дине нигезендә формалашкан гомумтатар милли культура, уртак фольклор, уртак моңнар, кайбер гореф-гадәтләрдә генә аермалык бар. Бервакыт Төмәндә үткәрелгән имамнар форумында Нәсия Уразова сүз сорап алып мөнбәргә чыкты да татар имамнары алдында урысча сөйли башлады: «Безнең, себер татарларының, иң югары культурасы – астаналар (Себергә Бохара якларыннан Ислам динен алып килгән шәехләр каберләре), нигә безгә Мәккәгә хаҗга йөрергә, астаналарга хаҗ кылуны оештырырга кирәк», – дип шаккатырды форумда катнашучыларны. Имамнар, бертавыштан «гү» килеп, мөнбәрдән кудылар үзен. «Себер Исламы» дип сөйләүчеләр бер Нәсия Уразова гына түгел. Өлкә Диния нәзарәте каршында рухани-мәгърифәти «Хикмәт» газетасын чыгарганда Исламның берлеге, һәр төбәк өчен аерым Ислам була алмаулыгы, фәкать дини гореф-гадәтләргә төбәккә хас гореф-гадәтләр кереп уралганлыгын аңлатуга аеруча игътибар итә идек, әмма Нәсияләр ишеләргә барып җитми иде Бохара мәдрәсәсендә гыйлемле укытучылардан белем алган элекке мөфтиебез Галимҗан хәзрәт Бикмуллинның вәгазьләре. Нәсиянең Себердә Ислам динен тараткан бохарлы шәехләрнең каберләренә табынган хәлендә Идел буе татарларының Себердәге мәгърифәти хезмәтләрен ят йогынты итеп күрүе сәер дә, аңлаешсыз да. Борынгы заманнардан бирле Казаннан дин әһелләре чакырылып китерелгән Себергә, алар арасыннан данлыклы Манҗел мәдрәсәсендә дә укытучылар булган, алар да монда динне, рухи кыйммәтләрне ныгыту белән бергә телгә йогынты ясаганнар, аларда бе-

лем алган имамнар аша халыкка килеп җиткән уртак татар теле, мәдрәсә шәкертләре Казаннан кайтарылган китапларны укыганнар. Авыл муллаларының мәчеттә алып барылган метрика дәфтәрләрендә гомумтатар телендә язып калдырганнары шуңа ачык дәлил. Себер татарлары арасыннан Троицки мәдрәсәсендә белем алып кайткан имамнар шактый булган, алар да гомумтөрки тел нигезендәге иске татар-әдәби телдә укыганнар, себер татар теленә алар да йогынты ясаган. Беренче совет мәктәпләрендә, алар өчен укытучылар әзерли торган курсларда Манҗел мәдрәсәсен тәмамлаганнар белән бергә Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургта «Рәсүлия», Уфада «Галия» мәдрәсәләрендә белем алган дин әһелләре килеп укытканнар, алардан да булган себер татарлары теленә йогынты. Ярата-сыңмы, юкмы казан татарын, тарихи чынбарлыкны танымый булдыра алмыйсың, хәзер Татарстан йогынтысын өзеп кенә тарихны кире кайтара алмыйсың.

Себер татарлары өчен тел мәсьәләләрен аерым галимнәр генә хәл итә алмый, гомумән, татарның бердәмлеге мәсьәләләрен. Дистәләгән буын себер татарлары мәктәпләрдә әдәби телдә белем алды, әдәби тел фән буларак әлегә кадәр укытыла. Татар мәктәпләрендә белем алган буыннарга үз ана телләре дә газиз,әдәби тел дә бик кадерле, себерле-казанлы катнаш никахлар күбәйгәннән-күбәя бара, яшьләр этник төркемнәргә аерылмыйлар, татар дип кавышалар бер-берләре белән милли гаилә корасы килгән татар яшьләре.

Мин соңгы елларда этномәдәни компонентлы итеп кенә калдырылган татар мәктәпләрендә дә күп булдым, укучыларга провокацион сорау да бирә идем: «Бәлки сезгә әдәби телне өйрәнеп азапланырга кирәкмидер, мәктәптә себер теле генә укытылса җиңелрәк булмас идеме?» Һәр мәктәптә дә укучыларның җавабы бердәй булды: «Юк! Без үз ана телебезне беркайчан да онытмабыз, мәктәптә безгә әдәби телне өйрәнергә кирәк, татар дөньясыннан төшеп калмас өчен кирәк безгә әдәби тел».

Пенсиягә мин Төмәннән 20 чакрым гына ераклыктагы Индрәй авылында мәктәп директоры булып эшләгәннән соң чыктым. Барлык фәннәр рус телендә укытылса да, татар теле белән әдәбиятка атнасына 5 сәгать бирелә иде ул заманда, сыйныфтан тыш тәрбия эшләрен саф әдәби татар телендә алып бардык, җирле шивә дә читкә кагылмады, теләгән кеше үз телендә сөйләште, ата-аналар да бик канәгать иде мәктәп эшеннән. Мин анда эшләгәндә укытучылар һәм гади генә авыл кешеләре катнашы белән бер Казан драматургы әсәре нигезендә спектакль әзерләп күрсәткән идем. Авыл клубы тамашачылар белән шыгрым тулы булды. Рольләрне башкаручыларның кайберләре сәхнәдә күчтеләр дә киттеләр авыл теленә, кайберләре – әдәби телдә калды. Тамашачыларның алкыш-

ларыннан клуб диварлары тетрәгәндәй булды, үземә дә гаҗәеп шатлыклы манзара булып үтте спектакль. Менә шулай ике телнең гармоник рәвештә бергә уралып яшәве табигый да, бәрәкәтле дә безнең төбәк өчен.

Үзгәртеп кору елларында бу мәктәпнең әле бер директоры, әле икенчесе, үзләре татар булсалар да, татар телен факультативка калдырдылар, ана теленең дәрәҗәсе тәмам түбән төште. Алардан соң миндә рус телен укыган, югары белемле рус теле укытучысы белгечлегенә ия булган Индрәй кызы Рәүфә Алееваны куйдылар директор итеп. Ул татар теле мәҗбүри укытыла торган уку планына күчерде мәктәпне. Соңгы елларда рус гаиләләре дә килеп урнаштылар Индрәйгә, алар гына түгел, кайбер татар ата-аналары да татар телен укыту мәҗбүри булуга ризасызлык белдереп, факультативка (аңа теләгән балалар гына йөри) кайтуны таләп итеп, ябырылып килгәннәр яңа билгеләнгән мәктәп мөдиренә. Рәүфә әйткән аларга: «Бу татар этномәдәни компонентлы мәктәп, уку планында күрсәтелгәнчә, татар телен укыту – мәҗбүри, әгәр дә балаларыгызның татар телен өйрәнүен теләмисез икән, Боровой ерак түгел, андагы рус мәктәбенә бирегез аларны, – дип, катгый белдергән. Беркем дә Боровойга илтеп бирмәгән баласын, рус балалары да теләп йөри танылган татар теле укытучысы Рузилә Исмәгыйлова алып барган татар теле дәресләренә хәзер бу мәктәптә, без килеп керүгә алар да, «Исәнмесез!» – дип, каршыбызга чыктылар, йөзләре шатлык яктысы белән балкый иде: сыйныфташ дусларының ана телен өйрәнеп, шул телдә аралаша алулары рус балалары өчен зур бәхет, аның уңай нәтиҗәләрен ата-аналары да аңлады. Ана теле торгызылу нәтиҗәсендә мәктәп гөрләтеп, уңышлы, һәр ата-ана канәгать булырлык итеп алып бара эшен. Бу мәктәп тәҗрибәсен туплап башка мәктәпләргә дә җиткерергә иде, әмма андый орган я оешма юк өлкәбездә. Өлкә Мәгариф департаментында да, Төбәк мәгарифен үстерү институтында да татар телен белгән, гомумән, милли мәгариф мәсьәләләрен багучы штат берәмлекләре юк ителде.

Анда булган очрашулар истән чыкмый. Алдан хәбәрләшеп, киттем Индрәй мәктәбенә, Рәүфә мине автобус тукталышында каршы алды. Мин эшләгәндә аның әнисе Рауза Тилимбаева башлангыч сыйныфларны укытты, мәктәп фатирына ремонт ясалганда ике айлап мин аларда яшәп, туганлашкандай булып калдык. Мәктәпкә таба сөйләшә-сөйләшә атлыйбыз, мине Рәүфәнең саф әдәби телдә сөйләшүе гаҗәпләндерде. Сорамый булдыра алмадым: «Рәүфә, син үзең рус телен укытасың, ә Казаннан әле генә килеп төшкән Казан татарыдай сөйләшәсең, кайчан өйрәнеп алдың әдәби телдә шулай оста сөйләшергә?» «Мин укыганда мәктәптә укытылды бит татар теле, сездән дә өйрәнеп калдык бит инде, апа. Безне Казан семинарларга чакырып тора, анда барып төшсәм, казанчага җиңел генә

күчәм дә китәм, кызыклы идеяләр белән рухланып кайтам, Себергә әйләнеп кайтсам, тагын үз дөньябызга чумам...», – диде ул. Шулай, әдәби тел, татар дөньясы, Казан ят түгел күпчелек себер татарына. Казан татарлары да «Себер белән куркытмагыз, Себер үзебезнеке» дип, җырларда җырлаганнар.

Себердә яшәүче татарлар өчен әдәби тел, себер шивәсе – уртак байлыгыбыз, себер татары белән казан татары өчен тел тоткарлыгы чынлыкта юк, аны уйлап чыгаручылар гына бар. Мин 50 нче елларда татар педагогия училищесын тәмамлап, Төмәннән ерак себер татарлары авылында башлангыч сыйныфны татар телендә укыттым, татар мәктәпләрендә барлык фәннәр татар әдәби телендә укытылган заман иде. Шагыйрь Булат Сөләйманов авылы – Сопра иде ул (элекке Дубровное, хәзер Вагай районы). Себер татар балалары минем телемне аңлыймы икән, дигән уй да килми иде башка, искиткеч сәләтле укучыларым йотлыгып укыдылар әдәби телдә. Авыл халкы өчен минем телем, минем өчен алар теле ят булмады, авыл халкы мине яратты, мин аларны яраттым. Миндә белем алган шул сыйныф балаларының берсе генә башка һөнәргә ия булды, калганнары барысы да – укытучылар, кайсы татар мәктәбендә, кайсы рус мәктәбендә эшләде, мактаулы исемнәргә лаек булдылар, элемтәдә торучылары әле дә әдәби телдә сөйләшәләр минем белән, тел аеручыларга карата ризасызлык белдерәләр, ә бит мин аларны барлыгы бер ел гына укытып калдым, институтка укырга киттем. Аларның югары үсешендә минем өлеш бер тамчы кебек кенә – элекке татар мәктәпләрендә укып чыккан буыннарның вәкилләре әдәби телне дә беләләр, үз авыллары телләрен дә онытмыйлар. Себер татар балалары әдәби телне аңламый, әдәби тел балаларның фикерләү сәләтен үстерүгә тоткарлык ясый, ана телебезне оныттыра, дигән сүзләр – ялган. Моңа бәйле бер гыйбрәтле истәлек саклана күңелемдә.

Күп йөргән, күпне күргән була. Ташкент шәһәрендә бер мәҗлестә рус мәктәбендә үзбәк телен алып барган укытучы Мәрьәм ханым белән танышырга насыйп булды миңа. Сугыштан соңгы елларда яшь укытучы – Башкортстан кызы Мәрьям Үзбәкстанга чыгып китә, Ташкентка килеп төшкәч, аны бер үзбәк кышлагына 4 нче сыйныфны укытырга җибәрәләр. Ул елларда 4 нче сыйныф имтихан тапшыра иде. Бер ел үтә, бер имтиханны карап китәргә дип, район мәгариф бүлегеннән инспектор килеп төшә, имтиханнар тәмамланганчы китми. Укытучыларны киңәшмәгә җыя. «Сез беләсезме арагызда нинди гаҗәеп талантлы укытучы барлыгын? Мәрьям төпле белем биреп кенә калмаган балаларга, аларны бер ел эчендә татар теленә дә бик әйбәт өйрәткән, укучылары камил татар телендә тапшырдылар имтиханнарны, – дип, гаҗәпләнүен, соклануын

белдерә. Шуңа да, кызыксынып, имтиханнар тәгәлләнгәнче китмәгән икән шул кышлактан. Мәрьям укучыларын татар теленә махсус өйрәтмәгән, үзбәк телен белмәгәнгә үз телендә укыта биргән, балалар аңлаганнар аны, аңа ияреп, татар телен табигый рәвештә үзләштергәннәр, чөнки татар һәм үзбәк телләре үзара якын төрки телләр. Ата-аналар да, инспектор да, балаларыбызны татар телендә сөйләтеп, үзбәк телен оныттырасыз, димәгәннәр. Шунысы да әһәмиятле: һөнәри әзерлекле сәләтле укытучылар гына телгә мәхәббәт тәрбияли ала. Безнең төп бәлабез тел тирәсендә үзара тарткалашуда гына түгел: тел укытучылары әзерләү эше күптән туктатылды, әзерлекле укытучыларыбыз пенсия яшенә якынлашып бара. Алар лаеклы ялга киткәч, татар телен укыту бөтенләй дә туктап калуы мөмкин. Менә нәрсә борчырга тиеш татар җәмәгатьчелеген, милләт лидерларын!

Шулай, Нәсияләр коткысына бирелгәннәр дә бар, әмма себер татарларының күпчелеге татарныербөтен милләт итеп күрә, себер татарларының рухи-мәдәни мирасы татар мәдәниятенең кадерле бер өлешен тәшкил итүен, бердәм булганда гына сакланып калырга, үсешкә ирешергә мөмкин икәнлеген аңлап, татар дөньясында каласы килә, милләтебезнең төрле төркемнәргә аерым халыклар булып таркалып юкка чыгуын теләми. Тик төбәк татарларын бер учка туплап, дәүләт органнары каршысына халкыбызның конституцион хокукларын гамәлгә ашыру таләбен куючы оешма, лидерлар юк.

Бүгенге вәзгыятьтә татар үзенең милли йөзен, туган телен, мәдәниятен, рухи-мәдәни мирасын таркау кече халык булып түгел, бөек, бердәм халык булып, тел, мәдәният өлкәләре өчен белгечләр әзерләү, милли мәгариф системасын торгызу мәсьәләләрен хәл итә алса гына саклый алачак.

Бабайлар да «Бердәмлектә – көч», – дип, ташка уеп калдырганнар.

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

## ИЗВЕСТНЫЕ ЛИЧНОСТИ

### КҮҢЕЛЕ КИҢ, ЙӨРӘГЕ ОЛЫ ИДЕ АНЫҢ



Без һәркөнне могҗиза көттек. Менә таң атыр да, Резидәбез сәламәтләнеп аякка басар да, күңел түрендә йөрткән планнарын тормышка ашыра башлар дип көттек. Ә хыяллары бик күп иде аның. Иң элек авыр чакта ярдәм кулы сузган һәркемгә рәхмәт әйтү, үзе өчен яши башлау, бер генә атнага булса да ялга бару, иҗат багажында җыелган яңа җырларын халыкка җиткерү, матур сәхнә костюмнары тектерү, туган авылы клубы сәхнәсеннән авылдашлары өчен концерт кую, юбилее чараларына әзерләнә башлау һәм башкалар, һәм башкалар. Ләкин... аяусыз үлем аны 2025 елның 19 июль кичендә безнең арадан алып китте. Юк, моңа һич кенә дә ышанасым килми. Соңгы сулышын алганчы Резидә үзе дә «яшим» дип яшәде. Сабыр булды ул. Бик авыр вакытларында да зарланмады, сыкранмады, түзде. Соңгы көненә кадәр биш вакыт намазын укып бакыйлыкка күчте.

Татарстанның халык артисткасы Резидә Шәрәфиева чын мәгънәсендә татар эстрадасы сәхнәсендә үз урынын, үз стилен тапкан, беркемне дә кабатламый торган үзенчәлекле башкару манерасын, үз репертуарын, сәх-

нәдә европача киенү стилен булдырган затлы, зәвыклы, зыялы җырчыбыз иде. Аллаһ аңа зифа буйны, чибәрлекне, акылны, талантны өеп биргән. Әбиләр әйтмешли, аның «сөйкемле сөяге» дә бар иде. Җырчының тамашачысы да үзе кебек тыйнак һәм затлы булды. Резидә һәр чыгышын бәйрәмгә әйләндерә белде. Аның бәрхет альт тавышы күңел түрләренә үтеп кереп тамашачыны балачак иленә алып кайта, мәхәббәт диңгезендә йөздерә, туган як болыннарында хисләндерә алды.

Сәхнәдә Резидә бөтенләй башка кеше. Җаны, тәне белән җыр эченә чума иде ул. Җырчы өчен бу вакытта бары тик бөек сәхнә һәм яраткан тамашачысы гына кала. Тормыш мәшәкатьләре, дөнья ваклыклары онытыла. Ул бөтен барлыгы, йөзендәге мимикасы, сәхнәдәге хәрәкәтләре белән аерым яссылыкта, көй һәм сүз дулкынында яши һәм үз артыннан тамашачысын да ияртә алды. Гомумән, җыр дәвамында һәркем Резидә белән бергәләп илаһи дөньяда яшәде.

Укытучы, рәссам-бизәүче белгечлеге дигән дипломнары булса да, Минзәлә районының Нарат Кичү авылында туып-үскән кызны язмышы көтмәгәндә җыр дөньясына алып килә. 1987 елда Чаллы каласында үзешчәннәр арасында узган бәйгедә Хәмдүнә Тимергалиева репертуарындагы «Чияле тау» җырын башкарып, Резидә Шәрәфиева беренче урынны ала һәм бу кызның тормышында кискен борылыш ясый. Ул җыр дөньясының ишекләрен киң итеп ачып түргә атлый... Үзенчәлекле тавышлы яшь җырчыны «Сердәш» ансамбле җитәкчесе Ринат Гобәйдуллин күреп ала һәм эшкә чакыра.

«Синсез яшәү яшәү түгел ул», «Торналар» – бу җырлар вакытында Резидәнең визит карточкасына әйләнә. Тормыш алга атлый: Чаллыда иҗат иткән җырчыга казанлылар да битараф булмый. Аны Казан милли-мәдәният үзәгенә эшкә чакыралар. Икеләнеп кенә чакыруны кабул итә Резидә. Чаллыны ярата ул. 4 ел ике арада йөреп эшләгәннән соң, башкалада мөмкинлекләр күбрәк икәнен аңлагач, 2001 елда Казанга күченә. Бу Резидәнең тормышындагы яңа этапка нигез салуы була.

Баксаң, инде ул көннән соң да шактый еллар аккан. «Мәк чәчәге», «Җырлама син», «Ярат кына», «Китмә, сөйгән яр», «Бергә булыйк», «Сагыш», «Мәхәббәт җыры», «Рәхмәт сиңа», «Якынымның туган көне», «Гомер чишмәм», «Тормыш көймәсе», «Әнкәй янына кайттым», «Җанга яр табалмадым», «Уртак итмәде», «Бер тутырып карадым», «Ялгыз йорт», «Тәгәрәп лә китте йомгагым», «Өзмә өметем», «Сириннәр», «Синсез» кебек татар җыр сәнгатендә урыннары түрдә булган җырлар иҗат ителгән. 17 аудиоальбом һәм 10 видеоклип тамашачы хозурына тапшырылган. Репертуары Ринат Гобәйдуллин, Фирзәр Мортазин, Зөфәр Хәйретдинов, Илшат Харисов, Ринас Әхмәтов, Риваль Хисмәтуллин Айдар

Тимербаев, Ринат Мөслимов, Айдар Минһаҗев, Айгөл Вәлиуллина кебек авторларның җырлары белән баеган. Үземнеке дип әйтерлек ул яраткан, аны яраткан тамашачысы барлыкка килгән. Татарстанның халык артисты дигән мактаулы, лаеклы исемгә ия булган.

Ә тормышта Резида Шәрәфиева, сәхнәдәге образыннан аермалы буларак, бөтенләй башка кеше иде. Көндәлек тормышта умырып эшләүче, кирәксә – печән чабучы, кирәксә – телеңне йотарлык бәлеш пешерүче, утын яручы, баз казучы, матур күлмәкләр тегүче, каз-үрдәкләр караучы, рәхәтләнеп машина йөртүче гап-гади хатын-кызга әйләнә дә кала иде. Башлаган һәр эшенең тәмен табып, җиренә җиткереп башкара да белде ул.

Бу дөньяда Резидәнең иң зур байлыгы – кызы Зөләйха булды. Әтисенең куанычы, әнисенең горурлыгы булган кыз быел 19 яшен тутырды. «Бу тормышта нинди генә һөнәр сайласа да, чын кеше булсын. Тыйнак булсын, тырыш булсын, кешеләрне яратсын», – дип тели иде ана кеше. Иманым камил, киләчәктә Зөләйха әнисенең исеменә тап төшерми, аның киңәшләрен истә тотып яшәр, безне үзенең иҗаты белән сөендерер әле.

Тагын бер матур сыйфаты бар иде Резидәнең. Ул туганны да, дусны да хөрмәтли белде. Рәйханә апа белән Дамир абый гаиләсендә үскән дүрт баланың олысы буларак, барлык туганнарын да ул күз угыннан югалтмый, алар өчен дип тә яшәде, дусларын да онытмады. Ул әнисенең, энеләренең, сеңлесенең таянычы булды. Күңеле киң, йөрәге олы иде аның. Гомере буе җырчының «югы – уртак, булганы – бергә» дигән шигаре – тормыш девизы булды.

Резидә беркайчан да иренми һәм тапканы, булдырганы белән бүлешә дә белә иде. Бер кечкенә генә мисал. Узган ел җиде чиләк нарат күркәсе җыеп, шуннан сироп ясап барлык туганнарына да таратты, дусларына да өлеш чыгарды. «Бу эшне яратып, күңелем кушканча эшлим», – ди ул чын күңелдән. Ә аның туган ягын ничек яратканын белсәгез?! Атнасына ике, хәтта өч тапкыр да кайтып килергә вакыт таба иде ул. Нарат Кичү авылында «кайттыңмы» дип көтеп торучы әнисе яши шул. «Авылымдагы таң ату да, кояш баешы да кадерле, якын миңа. Монда һава да башка», – дия иде Резидә. Кендек каны тамган изге җире, туган авылы зиратында җирләнде дә Резидә. Урыны оҗмахта булсын. Без туганнары, дуслары аны беркайчан да онытмабыз.

*Гөлназ ШӘЙХИ*

***Журналыбыз редакциясе бу олуг шәхес турындагы хатирәләргә кушыла, урыны оҗмахта булсын дигән теләкләр теләп кала.***

## ТАТАР РУХЫ

## ТАТАРСКИЙ ДУХ

*Мәгариф Раянов*

### БАЙКОНУР ХАТИРӘЛӘРЕ

*«Һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнәгать тугрыларында милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиешле».*

***Ризаэтдин бине Фәхретдин***

Без эшләгән «Прогресс» заводының бер бүлекчәсе ерак-ерактагы Казахстан далаларында төзелгән иде. Мул сулы, язгы ташкындай тиз һәм ургылып агышлы Сыр-Дарья елгасының бормаланып үтә торган бер искиткеч матур җиренә Ленинск дигән шәһәргә нигез салып, филиалда эшләүче завод хезмәткәрләре шунда яшиләр. Ленинск шәһәре халык телендә бик кулланыш тапмыйча, күбесенчә рәсми кәгазьләрдә генә булып, матур итеп Байконур дип йөртелә.

С.П. Королёв, М.К. Янгель, Ю.А. Гагарин кебек бөтен дөньяга билгеле шәхесләрнең һәйкәлләре, биек постамент өстенә менеп кунаклаган мәһабәт ракеталары, күркәм кыяфәтле мәдәният һәм спорт сарайлары, агач һәм бакчачыклары, мәйдан һәм мәйданчыклары булган шәһәр урамнарыннан йөрү күңелләргә ятыш булса да, мине читтәрәк җәйрәп яткан чиксез киң далалар ниндидер сихри көч белән үзенә чакыра...

Чакыра да, иртә яз башындагы төрле төстәге хуш исле лалә чәчәкләре, кечкенә дә болыт кисәге күренмәгән зәңгәр күктәге сайрар кошлары белән йөрәкләрне җилкендерә...

Әйе, Хәлим Сабит-Лабити үзенең «Алтайга тугры» әсәрендә язып калдырганча, борынгы төрки бабайларыбызның «...кечкенә гәүдәле, киң күкрәкле, озын төкле, калын аяклы чыдам атларының» тояк эзләрен инде күптән ком бураннары күмеп китсә дә, һаман да аларның кешнәгән тавышлары, бабайларыбызның көр һәм хуҗаларча нык авазлары ишетелә кебек... Менә-менә ерактагы офык артыннан ат, дөя, сарык һәм кәҗә көтүләре, тузан күтәреп, тыпыр-тыпыр дөпелдәп минем янымнан үтеп китәрләр кебек тоела...

Ә һаваның әйтеп бетергесез җиңеллеге, җылылыгы, канатларны кабартып, күккә өнди кебек. Ә күктә без кичә генә очырып җибәргән раке-

таның аксыл-сары төстәге салават күпередәй эзе таркала башлаган болытны хәтерләтә...

Филиалда, күбесенчә, Куйбышев һәм Казан авиация институтын тәмамлаган инженерлар эшли идек. Көнне – төнгә, төнне көнгә ялгап дигәндәй эшләгән чагында бик игътибар бирелмәгәндер, ә менә еллар ераклыгыннан, офык киңлегеннән искә төшерә башлагач, аңлашыла ки, иң җаваплы, иң катлаулы урыннарда – җыю цехы булмасын, сынау цехы булмасын, Советлар иленең иң ерак төбәкләреннән җибәрелгән приборларны беренчел тикшерү цехы булмасын – һәрберсендә татар инженерлары армый-талмый эшләгәннәр икән. Иншаллаһ!

Байконурдагы татар-башкорт милләттәшләребезнең инженер, эшче һәм хәрби хезмәттә булганнары да гаиләләре белән, хөкүмәт биргән уңай шартлы фатирларда яши иде.



*Октябрь бәйрәме демонстрациясендә Мәгариф һәм Розалина Раяновлар.*

Бәйрәмнәрне (Совет чорында бәйрәмнәребез бүгенгедәй күп санлы, түгел иде кеби) берничә гаилә бергә җыелышып, туган телебездә халкыбыз җырларын җырлап, баянчыларыбыз һәм курайчыларыбыз көй сыздырып, шагыйрьләребезнең шигырьләрен сөйләп, аннан соң тыпыр-тыпыр биеп, күңелле итеп үткәрә идек.

Без очырасы «Энергия-Буран» ракета комплексының космостан урап кайткан «Буран»ын җиргә урнаштыру өчен искиткеч осталык белән юл төзүче подполковникларыбыз (ул вакытта әле яшь майорлар) Харис Сәгыйтов тылсымлы кураенда башкорт халык моңнары белән күңелләребезне эретсә, Рим Гәскаров баянында татар халык көйләрен тибрәтеп, йөрәкләрне җилкендерә иде.

Ә инде Яңа ел бәйрәмнәрендә Байконурның үзәк мәйданында һәм «Новосел» кибете янындагы чыршы тирәсендә биеп, җырлап, башка милләттән булган кардәшләребезне дә түгәрәккә чакыра идек...

...Һәм, ниһаять, үзгәртеп коруның шифалы җилләре, Сыр-Дарья елгасының ярларына тамыр җәйгән Байконурга да килеп җитте.

Байконурда яшәүче татар һәм башкорт милләттәшләребез өчен безнең ничә еллар буе күңелләрдә пыскып кына ята биргән милли горурлык һәм милли хисләребез барлыгын наҗагай кебек кинәт яктыртып, сискәндереп җибәргән көч Гөлзадә Сафиуллинаның концерты булды.

Көннәрдән беркөнне минем башыма ул еллардагы сәясәт һәм мәдәният кысаларына сыя алмаслык фикер килмәсенме! Нишләп соң әле без – Байконурда илебезнең абруен күтәреп, даны бөтен кешелек дөньясына оран салырлык техникалар төзеп яшәгән күпсанлы татарлар – Казаныбыздан берәр мәшһүр җырчыбызны чакырып, мондагы мәдәният сарайларының берсендә милли моңнарыбызны яңгыратмыйбыз? Бу хыялый фикер чынбарлыкка тәңгәл килерлекме? Булмаса, һич югында мондый мөмкинлекләрнең барлыгын-юклыгын ачыклап, тормышка ашыру юлларын эзләп карыйсы иде...

Фикердәш татар һәм башкорт милләттәшләребез бу гадәти булмаган тәкъдимне кире какмадылар һәм шушы юнәлештә эшли башладык. Иң беренче нәүбәттә, ерак-ерактагы Казаныбыздан Байконур кебек Казахстан далаларында урнашкан җирлеккә килергә теләүче артистыбыз кирәк иде. Ә ул табылды, Иншаллаһ. Халкыбызның атказанган артисты (ул чагында әле халык артисты түгел иде...) Гөлзадә Сафиуллина ике дә уйлап тормыйча ризалык белдерде.

Ә безнең эш инде – ничек итеп «ябык» шәһәргә артистларыбызны кертү, ничек итеп төрле оешмалардан «мөһерле» кәгазьләр алу, филиал һәм шәһәр башлыклары белән сөйләшү, кунакханә һәм кайсы мәдәният сараенда үткәрү кебек проблемаларны хәл итү иде. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән барысын да җиңеп чыктык һәм көз көннәренең берсендә Гөлзадә Сафиуллина, Риф Гатауллин, Резеда Сафиуллина, Фәрит Бәшир һәм баянчы Фаил Исхаков Байконур янындагы Түрә-Там станциясенә килеп тә төштеләр. Шәһәребезнең «Төзүчеләр» исемендәге иң зур мәдәният сараеның концертлар залы шыгрым тулы иде.

Концертка татар һәм башкортлар гына түгел, казах кардәшләребез һәм башка милләт әһелләре дә килде. Ә алдагы рәтләрнең берсендә, махсус чакыру билетлары белән, предприятиебез җитәкчеләре утырды.

Концерт тәмамлангач, Гөлзадә Сафиуллинаның: «Залыгызда шундый яхшы акустика, иртәнгә чаклы җырлар идем», – дигән сүзләре әле дә колагымда чыңлый.

Икенче көнне артистларыбызны предприятие җитәкчесе Г.Я. Сонис биргән махсус автобус белән «Гагарин стартына» алып киттек. Анда фоторәсемнәргә дә төшәргә рөхсәт алган идек. Мондый «рөхсәтләр» алуны җиңелләштерүче режим буенча бүлек мөдире Р.Х. Нураевның үз татарыбыз булуы бик тә ярдәм итте, әлбәттә. Аңа да Аллаһның рәхмәтләре булса иде.

Аннан соң кунакларыбызга шәһәребезнең истәлекле урыннарын күрсәтеп, шулай ук, фоторәсемнәргә дә төшкәч, алар кайтыр юлларына җыена башладылар.

Поездга утырыр алдыннан Гөлзадә Сафиуллина матур гына итеп елмаеп карады да: «Мәгариф, Байконурда татарларыбыз бик күп икән, баш-

корт кардәшләребез дә бар, нишләп соң бүгенге көнгә кадәр татар-башкорт мәдәният үзәгегез юк?» – дип әйтеп куймасынмы! Мин эсселе-суыклы булып киттем дә, «уйлап карарбыз әле» кебегрәк сүзләрне кысып чыгардым. Ул, җылы саубуллашып, вагон баскычына күтәрелде. Артистларыбыз барысы да ачык ишек алдына басып, безгә кул болгыйлар, без дә, кузгалып киткән поезд артыннан атлый-атлый, кул болгыйбыз...

Менә шулай итеп, Татарстаныбыздан беренчеләрдән булып, Байконурда концерт куеп, артистлардан беренчеләрдән булып Ю. Гагарин стартына аяк баскан Гөлзадә Сафиуллина, Риф Гатауллин, Резеда Сафиуллина, Фәрит Бәшир һәм Фаил Исхаков Казаныбызга кайтып киттеләр. Хәерле юллар һәм яңа иҗат уңышлары насыйп булсын сезгә – олуг йөрәкле, милләтпәрвәр һәм мәрхәмәтле кардәшләребез. (Ә бүгенге көндә баянчыбыз Фаил Исхаков та, нәфис сүз остасы, филология фәннәре кандидаты Фәрит Бәшир дә фани дөнья белән саубуллашып бакыйлыкка күчтеләр. Аллаһы Тәгалә аларның икесенең дә белеп яки белми кылган гөнаһларын гафу кылып, Үзенең җәннәтләре белән бүләкләсә иде. Әмин).

Ә тормыш дәвам итә. Безгә яшәргә, көрәшергә, нинди генә шартларда да алга атларга кирәк! Югыйсә, «тормыш» дигән арбадан берәр борылышта төшеп калуыбыз да ихтимал...

«...Нигә мәдәният үзәгегез, юк? Чыннан да, нигә оештырмыйбыз? Әллә сталинизм һәм торгынлык чорында туган телебез, мәдәниятебез һәм тарихыбыз турында аз гына сүз кузгата башлау белән, милләтчелектә гаепләргә әзер торган кешеләрнең хәтта күз карашларыннан ук куркып һәм өркеп яшәргә өйрәнгәнлектән бөтенләй сүлпән затларга әйләндекме? Югыйсә, илебезне иңләп-буйлап үзенең мавыктыргыч нурларын сирпегән үзгәртеп кору таңнары безгә нинди мөмкинлекләр офыгын актырта, ә без һаман да «алма пеш, авызыма төш» – дип яши бирәбез. Кем аны пешерер дә, кем төшерер соң? Кемнәрдер «пешереп», кемнәрдер «төшергән» алмалардан әлегә кадәр авызларыбыз бәрелеп, шуны әле булса ача алмый интегәбез түгелме соң? Димәк, тик үзебезгә, тик үзебезнең беләкләргә, белемнәргә һәм изге теләкләребезгә генә таянып, җиңнәребезне сызганып, бүгеннән үк эшкә тотынырга кирәк! Бүген башламасак, иртәгә соң булачак!

Казан кунакларыбызны озатканнан соң беренче ял көнендә үк фатирыбызга җыелдык. Фикердәшләремнең тәкъдимнәре төрлечә булса да, берсе катгый иде: татар-башкорт мәдәният үзәген кичекмәстән оештырырга. Ничек һәм нәрсәдән башларга, нindirәк булырга тиеш ул мәдәният үзәгенең кануннары, ничек итеп аның Уставын төзергә? Арабызда күбесенчә техник һәм хәрби белемле якташларыбыз булып, юриспруденция белемен үзләштергәннәренең юклыгына көрсенеп тә куйдык...

Ә бит Куйбышевта «Туган тел» җәмгыятебез инде берничә еллар дәвамында уңышлы гына эшләп килә. Аларның юридик кануннарга нигезләнеп эшләнгән Уставы да бар. Беренче адымнарыбызны атларга юнәлеш алыр өчен, алар белән очрашырга кирәклеге ачыкланды. Җаен-җайга салып, рәтен-чиратка китереп дигәндәй, завод самолеты белән мин «Туган тел» рәисе Азат Надиров белән очрашырга Куйбышевка очтым. Авиация заводының ишеге алдында ул Уставны ничек язарга, ничек кабул итәргә, гомумән, Куйбышев татар иҗтимагый үзәге «Туган тел»нең филиалын Байконурда ничегрәк оештыру серләрен энәсеннән-җебенә кадәр аңлатып бирде. Ә инде, үрнәк өчен үзләренең Устав күчермәсен дә бүләк иткәч, мин канатланып, зәңгәр күк киңлеге буйлап, шул ук самолет белән Байконурга юнәлеш алдым.



*Устав кабул иткәннән соң.*
*Татар гимнын – «Туган тел»ебезне дә җырлау...*
*Фотообъективка эләккән өлешендә: Сәлимә Исламова, Иршат Гимазетдинов, Мәгариф Раянов, Харис Сагыйтов*

Үзебезнең предприятиедә, шәһәребездә булган татар һәм башкортларыбызны барлап чыгу, аларны оештыру һәм «Үзәгебезгә» туплау җиңел түгеллеген һәрберебез дә аңлап, эшебезне Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән башлап җибәрдек. 1989 нчы елның 17 нче декабрендә шәһәребезнең иң күркәм Ленин мәйданына урнашкан мәдәният сараенда безнең беренче оештыру җыелышы үткәрелде. Устав кабул иттек һәм җитәкчелек органнарын сайлап куйдык.

Ленинск шәһәре халык депутатлары Башкарма комитетының 1989 елның 28 декабрендә кабул ителгән 508 нче карары нигезендә безнең «Туган тел» мәдәният үзәге рәсми рәвештә расланды. Бу карарга Башкарма комитет рәисе В.А. Угрюмов кул куйды. Ул матур итеп кыскартып «ЛТБКЦ» (Ленинский Татарско-Башкирский Культурный Центр) «Туган тел» дип йөртелә башлады.

Шунысын әйтергә кирәк: казах, рус һәм башка милләт вәкилләреннән торган шәһәр башлыкларыбыз татар-башкорт мәдәният үзәген оештыру-

га каршылык күрсәтмәделәр, киресенчә, кулларыннан килгәнчә ярдәм иттеләр. Аллаһының рәхмәтләре булсын аларга.

Уставны язганда, «шомартканда», матур, әдәби телле иткәндә күп көчләрен куйган Гарәф абый Шәрәфетдинов (Татарстан китап нәшрияты директоры) һәм аның хәләл җефете Рәисә апа Шәрәфетдинованы (татар теле укытучысы) искә алып үтәсе килә. Аларның кызлары – Резеда, кияүләре – Совет Армиясе офицеры Даян Абдрахмановлар янына кунакка килгән чаклары иде. Рәисә апа да инде вафат булды. Аллаһы Тәгалә аңа Үзенең иң дәрәҗәле оҗмахларының берсен насыйп әйләсә иде...

Менә шулай итеп, XX гасыр азагында, Байконурда «Туган тел» татар-башкорт мәдәният үзәге үзенең барлыгы турында дөньяга беренче авазын салды. Нәкъ менә шушы урында «беренчеләрнең» һәм «беренчеләргә» ярдәмләшкәннәрнең, армый-талмый, милләтебез өчен көчләрен кызганмыйча, вакыт төшенчәсе белән исәп-хисап тотмыйча эшләгән кардәшләребезнең исемнәрен әйтеп китәсем килә. Әгәр дә берәрсенең исемен төшереп калдырсам, берүк, гафу генә итә күрегез. Чөнки 20 елдан артык вакыт үтеп киткән бит...

Менә ул исемнәр:

*Алибаева Динара Рәис кызы,*
*Абдрахманов Даян Габделсәлам улы,*
*Абдрахманова Резеда Гарафетдин кызы,*
*Вафина Зәмзәмия Якуп кызы,*
*Гарифҗанов Наил Гарифҗан улы,*
*Гарифуллина Рәзилә Вәкил кызы,*
*Гарифуллин Фоат,*
*Гатауллин Фәрит Харис улы,*
*Гатауллина Гөлнур Гавае кызы,*
*Зималиев Рәфкать,*
*Зималиева Наилә,*
*Казанбаева Сания Гали кызы,*
*Латыпов Ришат Хәмзә улы,*
*Латыпова Зәлия,*
*Миңнегалиев Рамус Мөхәммәтнур улы,*
*Нуриев Миргасим Миңнеәхмәт улы,*
*Нуриева Альбина,*
*Нураев Равил Хәниф улы,*
*Нураева Гөлсем Фәтыйх кызы,*
*Насыйров Равил Хәсән улы,*
*Насыйрова Рәшидә,*
*Попова Лилия Тәхәү кызы,*

*Раянов Мәгариф Шәйхмулла улы,*
*Раянова Розалина Габдрахман кызы,*
*Рысаев Азат Гаяз улы,*
*Рәшитова Хәтирә Ризаетдин кызы,*
*Сәгыйтов Харис Мөдәрис улы,*
*Сәгыйтова Лилия Әнвәр кызы,*
*Гарифҗанова Наилә*
*Шарапов Борис Хазинурович*
*Нуриев Фәрит*
*Нуриева Роза*
*Сунаргулов Нур Мөхтәр улы,*
*Сунаргулова Җәүһәрия,*
*Сәлихов Әхтәм Барый улы,*
*Сәлихова Рәмилә Якуп кызы,*
*Фаттахов Альберт,*
*Фәизова Мәрьям Вакыйф кызы,*
*Хөснетдинов Илдар Исхак улы,*
*Хөснетдинова Хәдичә,*
*Хәйруллин Ирек Фәсәх улы,*
*Хәйруллина Фәгыйлә,*
*Йонысов Рәфкать,*
*Йонысова Наилә Нуриман кызы,*
*Ямакова Хәлимә Гаяз кызы,*
*Гыймазетдинов Иршат,*
*Гыймазетдинова Мәрьям,*
*Исламова Сәлимә.*

Аларның олуг гамәлләренә этәргеч биргән милләттәшләребезнең дә исемнәрен әйтеп китмәсәм, хакыйкатькә хилафлык кылу кебек тоела. Менә алар:

*Гаскәров Рим Шагиәкбар улы,*
*Гаскәрова Гатия Лотфулла кызы,*
*Исламов Рәмил Мирсәет улы*
*Вагапов Рәшит*
*Вагапова Гөлнур*
*Латыпов Гали Бариевич*
*Латыпова Галия*
*Нафигин Әхмәт*
*Нафигина Дания*
*Насыров Равиль*
*Насырова Рәшидә*

*Хөсәенов Рауф*
*Хөсәенова Галия.*
*Кәлүчев Илгиз Исмәгыйль улы*
*Надиров Азат Камил улы*
*Баһаутдинов Шамил Салимутдин улы*
*Әһлиуллин Рәфкатъ Нәбиулла улы*



*Татар-Башкорт мәдәният үзәге «Туган тел» әгъзалары казах кардәшләребез белән.*

Башкарасы гамәлләребез һәм барачак юлларыбызга дөрес юнәлеш билгеләр өчен «Туган тел»ебезнең эш планын төзү зарурлыгы ачыкланды. Исемебез «мәдәният үзәге» булгач, әлбәттә, бер юнәлешебез – сәнгать, икенчесе инде мәгариф юнәлеше булып, бу якларда яшәгән татар-башкорт милләттәшләребезнең балаларына туган телебезне өйрәтү һәм укыту ысулларын эзләп табу иде.

174 нче һәм 1 нче шәһәр урта мәктәпләрендә директорлары Раиса Алексеевна Зиновьева һәм Галина Николаевна Полиевская катнашлыгында, татар теле түгәрәкләре оештыру нияте белән, ата-аналар җыелышын үткәрдек. Җыелышта утырырга урыннар җитмәде. Бу хәл безне бөтенләй канатландырып җибәрде. Шимбә саен ике мәктәптә татар укытучылары Рәзилә Вәкил кызы Гарифуллина һәм Сания Гали кызы Казанбаевалар ярдәмендә, балаларның да, ата-аналарның да күңелләрен эретерлек туган телебезнең кадерле авазлары яңгырый. Алар, чын мәгънәсендә, халык укытучылары: үзләренең хезмәтләре өчен бернәрсә дә таләп итмичә, бердәнбер бүләк, сабыйларның «И ту-

ган тел, и матур тел»... – дигән сүзләре өчен канатланып эшли торган кешеләр.

Өйрәнсеннәр алар Мәрҗәнине,
Укысыннар «Йосыф» кыйссасын,
Газиз Гобәйдуллин «Сәхифәсе»
Алар өчен бүген ачылсын.
Риза бине Фәхретдинне укып,
Чын фәлсәфи белем алсыннар.
Аның гакыл һәм гаделлек сүзе
Йөрәкләргә сеңеп калсыннар.
Бөек Тукай сүзе аңлашылсын,
Шигъри юлы аның эретсен.
Күңелләргә җылы хисләр өстәп,
Миһербанлык аңы керетсен.
Күңел кырларына сабыйларның
Җәлил-Такташ сүзе сибелсен.
Йөрәкләрдә шытып, тамыр җәеп
Милли бөеклеккә үрелсен! – дип өстәп тә куясы килә.

Февраль аенда шагыйребез, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең туган көненә багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрдек. Без аның тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләп, шигырьләрен укыдык, җырларын җырладык. Ике сәгатьтән артык барган кичәне туган телебезгә һәм моңнарыбызга сусаган тамашачылар бик җылы каршы алдылар.

«Җылы каршы алдылар» дигәннән, ничек итеп шәһәр буйлап, һәрбер татар, башкорт яшәгән фатирга кереп, Муса Җәлил яраткан «Гөлҗамал» җырын башкаручыны эзләп йөрүем әле дә хәтеремдә. «Тырышкан табар...» – дигәндәй, ул миннән ерак түгел генә яшәүче Совет Армиясе офицеры Фоат Гарифуллинның тормыш юлдашы, безнең булачак татар теле укытучыбыз Рәзилә ханым булып чыкты.

Менә шушыңа охшашрак ысуллар белән нәфис сүз осталары: Рәмилә Сәлихова, Зәлия Латыйпова; җырчыларыбыз: Зәмзәмия Вафина, Альбина Нуриева, Фәгыймә Хәйруллина, Наилә Зималиева, Наил Гарифҗанов, Азат Рысаев; баянчыларыбыз Нур Сунаргулов, Альберт Фәттахов; курайчы Харис Сәгыйтов; биючеләребез Ирек Хәйруллин, Сания Казанбаевалар эзләп табылып, безнең мәдәният үзәгенә нур булып бөркелделәр.

Бүгенге еллар биеклегеннән карап, үзешчән артистларыбызны күз алдыннан кичергәндә, Аллаһы Тәгалә аларның барчасына да талантларны шулкадәр мул рәвештә насыйп иткәнлегенә аптырап та, сокланып та, горурланып та куясың...

Хәтта без, Байконур тамашачысы алдында, Галиәсгар Камалның «Беренче театр» комедиясен кую дәрәҗәсенә ирештек!

Бу юлларым үзебезгә-үзебез бәя бирү кебегрәк яңгыраса да, 1 нче Май, 7 нче Ноябрь бәйрәмнәрендә «Туган тел» мәдәният үзәге, шәһәрдә татар-башкорт колоннасын оештырып, Ленин мәйданыннан үткәндә татар композиторларының маршы һәм көйләре яңгыравын рәсми хакимиятнең халкыбызны ихтирам итүе дип кабул итә идек.

Ә менә «Нәүрүз» бәйрәмнәрен, Түрә-Там базары янындагы олуг мәйданны тутырып, казах кардәшләребез белән бергә үткәрүебез әле дә күңелләрдә җылы хисләр уята. Безнең үзешчән артистларыбыз анда да сынатмыйча – казах, рус җырлары белән бергә татар һәм башкорт моңнарын тамашачыларга җиткереп, мул алкышлар белән бүләкләнә иделәр...

Ленинск шәһәре радио һәм телевидениесенең казах телендәге тапшыру бүлеге белән элемтәләребезгә аерым тукталып үтәсе килә. Күп миллионлы татар һәм башкорт халкыбызның монда бер мең чамасы вәкиле яши. Мәдәният үзәгебезнең җитәкчесе итеп, җирле татарлардан булган, телевидение режиссеры Илдар Хөснетдиновны сайлап куйдык. (Хәзер инде вафат. «Җаны җәннәттә генә булса иде» – дип, аның халкыбыз хакына кылган изге гамәлләре өчен, догада булыйк, хөрмәтле милләттәшләрем).



*Байконурда Нәүрүз бәйрәме Рәзилә Гарифуллина һәм Нур Сунаргулов*

Илдар Исхак улы тамырлары белән Оренбург далаларыннан булса да, тугандаш республикабыз Казахстанда тормыш корган. Һәм аның хәләл җефете Хәдичә Хөснетдинованың телевидениедә фотокорреспондент булып эшләве, шунда ук, милләттәшебез Гөлмирә Атабаеваның тавыш режиссеры булуы, «Туган тел»ебезне шәһәр күләмендә генә түгел, хәтта Кызыл-Орда вилаяте киңлегендә пропагандалау юлларын ачты.

Әле дә хәтеремдә, шәһәребезнең иң күркәм космонавтлар кунакханәсенең камил итеп җиһазланган зур залында үзешчән артистларыбызның сәгать ярымлык җыр программасын

телевидениегә төшерделәр. Ул программаны еш кына телевизордан күрсәтүләре безне бу өлкәдә тагын да тырышыбрак эшләргә канатландыра иде. Казах программасын алып баручы Чулпан туташ, мине дә телевидениегә чакырып, матур итеп әңгәмә оештырганын хәтерлим. Ул сорауларын казах телендә бирсә, мин татарча җаваплый идем. Телләребезнең тамырлары бер булуы безне, беренчедән, милләтләр буларак якынлаштырса, икенчедән – бер-беребезне аңларга ярдәм итә иде.

Мин телевизор экраннары аша, якташларыбызның кулыннан килсә, «Туган тел»ебезгә спонсорлык ярдәме кирәклеге турында да сөйләп киткән идем. Шул чыгыштан соңдыр дип уйлыйм, космодромның профсоюз оешмасы безгә еш кына матди ярдәм кулы сузуы истә калган. (Җитәкчесе: Икаев А.М.) Чөнки безгә, Ленин мәйданындагы мәдәният сараенда зур бүлмә бирелеп, шунда репетицияләр һәм төрле очрашулар үткәрә идек. Аның чыгымнарын түләү дә зарур булгандыр инде...

Белмим, нигәдер, нәкъ менә шушы урында хәтер дәфтәремне актарып, «Байконур камышлары» шигыренә тап булдым. Менә ул «Камышлар»:

Табигатьнең кырыс бер почмагы,
Дәрья суы – карлы киң елга.
Салкыннарга һичтә буйсынмыйча,
Ашкынасың алга агарга.
Минем күңел, сиңа охшап, елга,
Иярергә сиңа ашкына.
Бәлки сине куып җитә алмам
Тик син, елгам, алга ак кына.
Купшы чәчәкләрең кирәк түгел
Бөдрә камыш – букет җыйганда.
Зифа буйлы дәрья камышларың
Ап-ак кардан буен сузганда.
Андагыдай зифа, төз камышлар
Беркайда юк, шундый сөйкемле,
Такташ абый сагынып язган кебек,
Аның каеннары шикелле!

Менә, шулай итеп, үзебезнең милләтпәрвәр татар һәм башкорт якташларыбызның фидакарь хезмәтләренең җимеше булган «Туган тел»ебез, кунакчыл казах кардәшләребезнең куенына сыенып, уңдырышлы туфракка утыртылган гөл кебек, яфрак ярып, чәчәккә бөреләнә башлады. Иншаллаһ!

Әгәр дә туфрак изге һәм мәрхәмәтле булмаса, бернәрсә дә шытып та чыга, үсеп тә китә алмаган булыр иде. Шуңа күрә, игелекле, мул кул-

лы һәм ашъяулыклы казах кардәшләребез турында Сембер якларыннан булган әдибебез Хәлим Сабит-Лабитиның (1883–1946) «Алтайга тугры» дигән әсәреннән берничә юл китереп үтәсем килә. Ни өчен дисәң, минем фикерләвемчә, казах кардәшләребезнең үткәне турында аннан да матур, аннан да төгәл итеп беркем дә язмагандыр да, яза да алмастыр кебек.

«...Күчмә тормыш таләбе буенча, казахлар ыруг-кабилә булып яшәргә мәҗбүр. Кабилә – читләр җәбереннән саклануның бер чарасы. Кабиләне һәрнинди кыерсытылудан, бөтен гаилә бердәм якларга тиеш. Бу – кабиләнең төп бурычы. Һәрбер шәхесне үзеннән дә артыграк яклау-саклау, кабилә башлыклары – биләр (бикләр) бурычы санала. Җәбергә юлыккан кеше бурычы – җәберләүче белән бәрелешү, үзен яклау түгел, бәлки авылларына, ыругдашлары булган җирләргә «барып куәтле аваз белән «оран салу», ягъни җәберләүченең исемен кычкырудан гыйбарәт. Оран авазын ишеткәч тә, ярдәмгә ашыкмау – зур гөнаһ. Ыругдашыңны җәберләүләренә каршы күтәрелгән чарада катнашмау әхлаксызлык санала. һәр казахның тормышы, яшәеше, шул рәвешчә, ыруг-кабиләсе тормышы белән иң тыгыз бәйләнешкә куелган. Нәсел шәҗәрәсе ыруг-кабиләгә шулай нык бәйләнгән булганга, читләр алдында ыруг-кабиләсе данын-дәрәҗәсен күтәрү һәркемнең яшәү мәгънәсенә әйләнә. Шуның өчен казахлар арасында авыздан авызга, буыннан-буынга телдән тапшырыла торган нәсел белеме бөтен халык белеменә әйләндерелгән».

Иншалла. Безгә дә татар һәм башкорт кардәшләребез, казах кабиләдәшләреннән үрнәк алып, бер-беребезне якын итеп, кардәшлек хисләребезне ялкынлатып яшәргә насыйп булсын!

Ә менә бу рифмага салырга тырышып язылган фикерләрем, «Камышлар» белән бер үк вакыт кысаларында язылса да, минем хатирәләремне тәмамлар өчен иҗат ителгән кеби тоелды:

### ҮЗЕМ КИТСӘМ...

Үзем китсәм, эзем калыр әле,
Тирән булмаса да, танырлык.
Йөри иде җилфер-җилфер атлап,
Дип сагынып искә алырлык.
Үзем китсәм сүзем калыр әле,
Сөйләгәндә сүзгә кушарлык.
Очрашканда кайчак сагынышып,
Бер елмаеп искә алырлык.
Үзем китсәм, җырым калыр әле,
Моң килгәндә алып тыңларлык.
Минем сагыш сезнең йөрәкләрдә
Булыр бәлки урын алырлык...

Әзем, сүзем, җырым сезгә булсын
Сезгә булсын минем хыяллар.
Хыялланмый, дәртләнмичә генә
Үтмәсеннәр безнең бу еллар.
Башлаган эш изге, зурдан булгач –
Озын гомер булсын дәвамы.
Без бит монда, дуслар, онытмагыз,
Халкыбызның олы кавеме.
Татар моңы, башкорт моңы безне
Бер учакка җыйды тирәләп.
Ялкынын да бергә янар өчен
Йөрәк утын кушып бергәләп.
Сүндермикче, дуслар, бу учакны
Нинди генә җилләр иссә дә.
Төрлебезне төрле якка язмыш
Мәрхәмәтсез ерак сипсә дә!

## ТӨБӘК ТАРИХЫНА КАРАГАН ХЕЗМӘТЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ. РЕЦЕНЗИЯЛӘР

## ИНФОРМАЦИЯ О КРАЕВЕДЧЕСКИХ ТРУДАХ. РЕЦЕНЗИИ

### ЯҢА КИТАП




В Исполкоме Всемирного конгресса татар состоялась стол-конференция на тему «Презентация краеведческих книг, посвященных истории ВОВ, изданных учеными и краеведами Пермского края и Республики Татарстан». Ученые, историки, краеведы представили книги, посвященные подвигу татар на фронте и в тылу в годы Великой Отечественной войны.

Было представлено несколько изданий: «Пермские татары в боях за Родину на фронтах Великой Отечественной войны 1941–1945 гг.» Данира Закирова, «Дети. Война. Судьбы… Сугыш. Сабыйлар. Язмышлар…» – сборник воспоминаний детей войны, составленный Альмирой Шарифуллиной из Чистопльского района РТ.

Поэт Вазих Фатихов и учитель истории, руководитель Музея боевой славы Верхне-Тимерлековской средней образовательной школы Рыбно-Слободского района РТ Ильфар Габдрахманов представили свою книгу «Үлемсезлек» («Бессмертие»), рассказывающую об уроженце Рыбно-Слободского района Бари Шавалееве, который повторил подвиг Александра Матросова. Книга Зуфара Валиахметова – уроженца с. Аппаково Алькеевского района РТ «Они ковали Победу в тылу» посвящена его односельчанам – труженикам тыла. А в книге «Память сердца» собраны воспоминания потомков татарских князей о своих родственниках, участвовавших в Великой Отечественной войне, о том, как сложились их судьбы после войны. Книга подготовлена Меджлисом татарских мурз (Татарское Дворянское Собрание) Москвы и Московской области, которое объединяет потомков знатных татарских дворянских фамилий.

*Взято из:* https://kazved.ru/news/tatary-na-zashhite-rodiny-5881262

# ЮБИЛЯРЛАР ТУРЫНДА СҮЗ

# СЛОВО О ЮБИЛЯРАХ

*Гөлшат Галәмова*

## ПЕДАГОГ, ЖУРНАЛИСТ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ!
(*Бибинур ханымның 90 еллык юбилее уңаеннан*)



*Гөлбакча син хыял күгемдә,*
*Сөюем мәңгегә күңелемдә.*
*Үзеңә тартасың гел җаным,*
*И минем сөекле Казаным!*

*(Резеда Вәлиеваның*
*Бибинур Сабировага багышлаган шигыреннән)*

Төбәк мәгарифен үстерүгә зур көч куйган, Себердә татар журналистикасының иң кыю вәкиле, югары сәнгатьнең үз эчендә тирән мәгънә йөртүен, көчле хис-кичерешләр тудыручы һәм мәңгелек кыйммәтләр турында уйланырга мәҗбүр итүче әсәрләрнең югары осталык дәрәҗәсен

һәм эстетик кыйммәте белән аерылып торуын аңлаучы зыялыларның берсе – Бибинур апа Сабирова турында булыр сүзебез.

Педагогия хезмәте ветераны, журналист, җәмәгать эшлеклесе Бибинур Нигъмәтҗан кызы Сабировага (Тимерҗанова) 90 яшь тулып килә. Ул зур хезмәт һәм тормыш тәҗрибәсе туплаган шәхес.

Бибинур Нигъмәтҗан кызы Төмән өлкәсе, Түбән Тәүде районының (элекке Велижан районы) 1911 елда Столыпин аграр реформасы юлламасы белән Сембер губернасының Буа өязе, Танай-Турай, Чүри-Бураш авылларыннан күчеп килгәннәр нигез салган Икенче Казан (Вторая Казанка), авылында 1935 елның 3 августында ишле гаиләдә дөньяга килгән. 10 яшенә кадәр бу авылда үскән һәм башлангыч белемне алган.

Икенче Казан авылы урнашкан әйләнә-тирәдә узган гасыр башында Столыпин исемендәге аграр реформа нәтиҗәсендә Казан губернасыннан килгән татарлар төзегән авыллар үзләре бер дөнья хасил иткәннәр. Урманбаш, Икенче Казан (Вторая Казанка), Өченче Казан (Третья Казанка), Яңа Казан (Новая Казанка), Уфим, Муллин, Камай, Камышин авылларында яшәүчеләр туган телне, гореф-гадәтләрне күз карасыдай саклаганнар, үзара тыгыз элемтәдә торганнар. Шуларның берсе бигрәк якын Бибинур апага. Чөнки, Өченче Казанда әнисенең әти-әниләре яшәгән, ә Хәсән Туфан эзләрен саклаган Урманбашта (1919–1920 елларда яшәгән) аларның гаиләсе Ватан сугышы башланыр алдындагы елларда яшәгән. Әтисе Нигъмәтҗан абый Урманбашка элемтә бүлеге мөдире итеп җибәрелгән булган.

1945 елда Тимерҗановларның гаиләсе Төмән шәһәренә күчеп төпләнгән. Бибинур апа шәһәрнең 7еллык татар мәктәбен, Тубыл татар педагогия училищесын тәмамлап, борынгы себер татарлары авылы Сопрада (шагыйрь Булат Сөләймановның туган авылы) педагогик хезмәт юлын башлап җибәрә. Аннары Алабуга педагогия институтының филология факультеты рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, юллама белән Татарстанда, саулыгы өчен климат алыштырырга кирәк булгач, кояшлы Ташкент якларында яшәп, төрле милләт балаларын укыта.

1970 елда туган якларга кайтып, мәгариф системасының иң җаваплы тармакларында эшли: Каскара мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы; Винзили мәктәп-интернатында директорның укыту эшләре буенча урынбасары; өлкә укытучылар белемен күтәрү институтының милли мәктәпләр кабинеты мөдире; Төмән районы Индрәй мәктәбе директоры.

Бу коры гына санап киткән эш урыннары исемнәре артында Бибинур апаның киеренке иҗади хезмәте, балаларга һәм укытучыларга биргән белеме, ялкынлы йөрәгенең җылысы калган, һәм билгеле, аның туган якларыбызда үткән педагогик хезмәт юллары эзсез калмаган.

1990 нчы елда лаеклы ялга чыкканнан бирле Бибинур апа милли үсеш хәрәкәтендә иң актив катнашучыларның берсе иде, өлкән яшьтә булуына карамастан, кулыннан бүген дә каләмен төшерми.

«*– Мин үзгәртеп кору чоры башлангач кына милли хәрәкәткә килеп кушылган кеше түгел, аның эченнән чыккан кеше, өлкә укытучылар белемен күтәрү институтында эшләгәндә татар мәктәпләрендә туган телне саклау, татар әдәбиятының абруен күтәрү өчен бер ялгызым көрәшкән елларымнан башлап, мин милли үсеш хәрәкәтендә*», – дип сөйли Бибинур апа.

Татар милли хәрәкәтенең үсеше, беренче чиратта, татар мәгълүмат кыры булдыруга барып тоташа. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә тиз арада милли эшне җанландыруның иң яхшы һәм ышанычлы ысулы – милли матбугат чараларын аякка бастыру икәнлеген ул төптән аңлап хәрәкәт итә.

Бибинур апаның дөньяга аек карашын, омтылышларын, сәләтен белеп, өлкә Диния нәзарәте каршында хакимиятнең финанс ярдәме белән газета ачу мөмкинлеге тугач, бу эшне аңа тапшыралар (1999–2000). Ике еллап кына чыгып калган «Хикмәт» дип аталган дини-мәгърифәти газета туган ягыбызда бик тиз танылып өлгерә. Губернаторлар алышынып, финанс ярдәме туктатылу сәбәпле, 10 ел чыкмый торганнан соң 2011 елда яңадан торгызылгач та, баш мөхәррирлек вазифасын өлкә җитәкчелеге янә аңа тапшыра. 2014 елда өлкә мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчесе алышынгач, аның элекке рәисе Галимҗан хәзрәт Бикмуллин белән бергә Бибинур апа да «Хикмәт»тән китә. Аның бу газетага багышлаган хезмәтенең асылы Төмән зыялыларының түбәндәге сүзләрендә ачык чагыла: «Бибинур Сабированың «Хикмәт»тән китүе милли мәгърифәтебез өчен зур югалту булды. Башта ул газетаны якташларыбыз бик үк аңлап та бетермәделәр... Ә инде югары интеллектуаль дәрәҗәдә, уйланырга мәҗбүр итә торган басманы халык аңлап, яратып өлгергәч, һәр санын түземсезлек белән көтеп ала башлагач, Бибинур апаның китүе югарыга күтәрелеп очып барган кошның атылып төшерелүенә тиң булды».

Газета ике телдә чыкты, диннең фән белән, мәдәният, туган тел белән бәйләнеше, диндә яшәү рәвеше, якташларыбызның социаль-икътисади хәле, әхлак-әдәп темасына, туган тел язмышы, авыл тормышы, нәниләр һәм яшүсмер балалар өчен вәгазьләр бүлекләре булуы, ике телдә – рус һәм татар телләрендә чыгуы, милләтебез өчен актуаль мәсьәләләрнең даими ачылышы «Хикмәт»не татарлар өчен генә түгел, рус телләләр өчен дә, төрле яшьтәгеләр өчен һәм идарә органнары җитәкчеләре өчен дә кызыклы итте.

## Гөлшат Галәмова. ПЕДАГОГ, ЖУРНАЛИСТ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ!

1994 елда «Ак калфак» бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасының һәм Россия хатын-кызлар Союзы Төмән өлкәсе бүлекчәсенең бер тармагы булып барлыкка килгән өлкә татар хатын-кызлар оешмасы да Бибинур апаның «баласы». Ул 22 ел дәвамында «Ак калфак» белән җитәкчелек итте.

Оешманың матбугат органы – «Ак калфак» газетасын булдырып, тора-бара аны иганәчеләр ярдәме белән шул ук исемдәге иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналга әверелдерде. Җәмәгатьчелек нигезендә газета-журнал чыгару гади, җиңел эш түгел икәнлеген белсә дә, Бибинур апа бу эшкә җиң сызганып тотынды. Чөнки, татар газета-журналларын, татар китабын даими рәвештә укып барган кеше генә дингә дә, сәнгатькә дә тартылуын, балаларына милли тәрбия бирүнең мөһимлеген аңлый ул.

Бибинур апа җитәкчеләребез, төрле урыннарда эшләүче түрәләр алдында туган телебезне, мәдәниятебезне үстерү өчен шартлар тудыру кирәклеген фәнни нигезләп күрсәтеп, бу проблемаларны бөтен тирәнлеге белән куя белде. Төмән өлкәсендә уздырылган фәнни-гамәли конференцияләрдәге чыгышлары, югары идарә органнарына «Ак калфак» оешмасы исеменнән юллаган мөрәҗәгатьләре шуңа дәлил. «Родной язык – основополагающая часть национальной культуры», «Состояние национального образования и культуры в Тюменской области», «Крепкая национальная семья – опора государства», «Проблемы сбережения региональных языков и развития государственного языка» дигән һәм башка темаларга язылган мәкаләләрендә һәм чыгышларында яңгыраган, матбугатта дөнья күргән аналитик материаллары югарыда әйтелгән проблемаларны күтәреп кенә калмый, төбәк татар журналистикасының саллы бер өлешен тәшкил итә. Ул ике телне дә камил белүче, рус һәм татар телләрендә язучы, азсанлы журналистларның берсе.

Аның публицистикасы җиңел укыла: гади, һәркемгә аңлаешлы һәм матур тел белән, темасы, төп идеясе тирән ачылып языла, шуңа да игътибарны үзенә җәлеп итә. Бибинур апага хас булганча көн кадагына туры китереп язу, дәртләнеп, хис-тойгыларга бирелеп, теләсә нинди аудитория каршында тартынмыйча чыгыш ясау, ачы булса да, дөреслекне күрсәтә белү сәләте һәм кыюлык һәркемгә дә бирелмәгән шул. Бу хакта Бибинур апа үзе болай ди:

*«– Бүгенге көндә акны да караны да ал нурларга гына манып язучыларга зур хөрмәт күрсәтелә, ә бит чын журналистиканың бурычы – укучыларга чынбарлыктагы дөреслекне бозмый җиткерү, мин менә шул принципка буйсынып эшлим, караны ак, пакь итеп күрсәтә алмыйм. Дөрес, җиңел түгел болай эшләү, ата-бабалардан калган сүз дә бар бит: «Туры әйткән – туганына ярамаган». Мин башкача булдыра алмыйм, ахирәт*

*дустым Флораның Бакый ага Урманченың хәләл җефете васыяте дә кыйбламнан читкә китәргә ирек бирми. Мин әле мәгарифтә эшләгән елларымда әйткән иде ул: «Яз, син язарга тиеш. Себер татарлары тормышы турында яз, Себергә китеп яшәгән якташларым турында яз, ничек яшиләр икән алар анда, нинди язмышларга дучар булдылар икән, тик чынбарлыкны бозмыйча, ничек бар – шулай яз, тарихка ялган кереп калырга тиеш түгел».*

Бибинур апаның мәкаләләре, очерклары, күренекле шәхесләр белән үткәргән әңгәмәләре: төбәк газеталарында – «Яңарыш», «Тюменский комсомолец», «Тюменские известия», «Тюменская область сегодня»; фәнни-гамәли конференцияләрнең докладлар җыентыкларында; Мәскәүдә «Татарские новости», «Карьера», «Ислам мөнбәре» газеталарында; Казанда «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Юлдаш» һәм башка газеталарда; «Сөембикә», «Татарстан» журналларында; Уфада «Тулпар» журналында дөнья күрде. Аның туган як турындагы хәбәрләре һәм мәкаләләре «Татарстан Яңа гасыр» телеканалында, Татарстан Радиосында еш яңгырады, башка өлкәләрнең газеталарында да күренде. Шулай ук «Татар-информ» агентлыгы каршында чыккан «Татар иле» – «Татарские края» газеталарында даими чыгып торды. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы сайты аша хәбәрләрне бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татарларга барып җитә иде. 1998–2013 елларда Бибинур апа «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының Төмән өлкәсе буенча үз хәбәрчесе булып хезмәт итте.

Төмән җирендә нәшер иткән «Ак калфак» журналы турында аерым әйтәсе килә. Нигезенә зыялы, гыйлемле халык тәрбияләү идеясе салынган журнал якташларыбыз тарафыннан әһәмиятле вакыйга буларак җылы кабул ителде. Журналның тирән эчтәлеген «Гаилә учагы», «Әниләрнең җылы кочагы», «Әбиләр һәм бәбиләр», «Гаилә учагының терәге – ата», «Авыл тормышы», «Туган тел», «Замана һәм шәхес», «Иман чишмәсе» «Заман каһарманы», «Гыйбрәтле язмышлар», «Юбилярларыбыз», «Юрист баганасы» рубрикалары тәшкил итте. Анда милли гаиләнең асылы, мәдәни тормышыбыз, үсеш проблемалары, әһәмиятле яңалыклар, күренекле шәхесләребезнең тормышы һәм эшчәнлеге чагылдыралды, якташларыбызның әдәби иҗатына да урын бирелде.

Бай һәм кызыклы эчтәлекле журналны эзләп табып укучылар, яздырып алып торырга теләүчеләр дә күп булды. Ул фәкать иганәчеләр ярдәмендә чыга иде, берничә саны өлкә татарлары Конгрессының матди ярдәме белән дөнья күреп калды. 1998 елда Бибинур апа Татарстан Журналистлар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

Җәмәгатьчелек нигезендә үз фатирында, үз компьютерында гына иҗат ителгән «Ак калфак» журналын киләчәктә профессиональ югары-

лыкка күтәрү, иҗади һәм гамәли штатын булдыру, журналның өзелми чыгып торуын тәэмин итү Бибинур апа Сабированың иң якты самими хыялларының берсе иде... Журналны иганәчеләр ярдәмендә нәшер итү кыенлашкач, ул аны 2011 елда электрон вариантка күчерде (ak-kalfak.ru) һәм үзе ике телдә алып барды.

Бөтендөнья татар хатын-кызлар җәмгыяте һәм Татарстан Республикасының «Сөембикә» журналы иҗтимагый хатын-кызлар хәрәкәтен үстерүгә керткән өлеше, «Ак калфак» журналын чыгарудагы фидакарь хезмәте, туган телне, татар гаиләсен, гаилә гореф-гадәтләрен саклауда концептуаль проектлары, конкурслары өчен Сабирова Бибинур Нигъмәтҗан кызын хатын-кызлар өчен иң абруйлы бүләк – «Сөембикә» билгесе белән бүләкләде. Бибинур апаның иҗтимагый һәм журналистик эшчәнлеге Татарстан, Казан белән тыгыз элемтәдә бара, дөньяга чыгарган хәбәрләрендә, публицистикасында Төмән өлкәсе татар милли хәрәкәтенең Татарстан белән мәдәни бәйләнешләре тирән ачыла.

2013 елда Бибинур апа ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Рәхмәт сүзе, 2014 елда үткәрелгән IV Бөтенрусия журналистлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары бәйгесендә «Татар халкының тормышын һәм көнкүрешен яктырту» номинациясендә җиңүче булып, махсус Диплом белән, Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнде. ТР Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы, Төмән өлкәсе Думасының, идарә органнарының татар бердәмлеген, халыкара дуслыкны ныгытуга керткән хезмәтләре өчен Мактау грамоталары исәпсез. Бибинур апа «Лучшие люди России» энциклопедиясенә дә кертелгән күркәм шәхес. Бибинур апа ТР Президенты Рөстәм Миңнехановка зур бүләге – сәламәтлеген ныгытуга ярдәм иткәне – «Ижминводы» санаториена бүләк юлламасы өчен олы рәхмәт хисен күңел түрендә саклый.

БТК ның берничә корылтаена, шул исәптән соңгы – юбилей корылтаена да, шәрәфле кунак итеп чакырылды Бибинур апа.

«*– 2005 елдан 2020 елга кадәр Төмән шәһәренең казан татарлары милли-мәдәни мохтарияте рәисе булып җитәкчелек итәргә туры килде. Төмәндә татар милли үсеш хәрәкәте себерлеләр-казанлылар мәсьәләләре куертылып торылуы сәбәпле шактый каршылыклы булды, шуның мәгънәсез авырлыгын миңа тулысынча, бөтен тирәнлеге белән кичерергә туры килде.*

*Ә чынында иҗтимагый һәм журналистик эшчәнлегемнең төп идеясе, төп юнәлеше татар бердәмлеген, милләт бөтенлеген саклау һәм ныгытуга бәйле иде, ә аны һәркем үзенчә аңлады. Күңел тирән тетрәнгән*

*чакларда җанымны милли хәрәкәттән китү уе биләп алса, мине Казан биргән көч һәм дәрт тотып кала иде»*, – дип искә ала Бибинур апа.

Бибинур апаның соңгы елларда себер татарлары рухи-мәдәни байлыгын торгызуга керткән өлеше дә аеруча әһәмияткә лаек. Ул танылган галим, себер татарлары тарихын, телен, фольклорын өйрәнүгә гомеренең 60 елын багышлаган тюрколог, филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Фәрит Йосыф улы Йосыповның себер татарларын дөньяга таныткан «Себер татарлары рухи мәдәни җәүһәрләре. Себер татарлары фольклоры антологиясе» дип аталган 5 томлык хезмәтен басмага әзерләүдә катнашты – автор белән бергә себер татарлары фольклор әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итте.

«*– 7–8 елга сузылган дәвердә мин зыялы олпат галим Фәрит Йосыф улы җитәкчелегендә иҗади эштә катнашу мөмкинлегенә ия булуым белән бәхетле, себер татарларының бай рухи мәдәни хәзинәләренең борынгы байлыкларын йөрәгем, җаным аша үткәрү ләззәтен кичердем, ул чорда себер татарларының борынгыдан гасырлар аша бүгенге көннәргә килеп җиткән рухи-мәдәни мирасы илаһи нурлар белән яктыртылган дөнья булып гәүдәләнеп торды күз алдымда»*, – дип, җылы хисләре белән уртаклашты Бибинур апа. Ул себер татарлары телен гомумтатар әдәби телдән аерып карамый, алар элек-электән килгән традиция нигезендә бергә уралып сакланган, алга таба да шулай үсеш алган хәлдә генә Себердә татар теле сакланып калыр, дигән фикерендә нык торуын дәвам итә.

«*– Дөньялар үзгәреп тора, дәүләтнең милли сәясәте дә зур үзгәрешләргә, борылышларга дучар булды, татар милли үсеш хәрәкәтенең дә йөзе үзгәрде. Соңгы елларда милли хәрәкәт сүнде, дип әйтү дөрес үк булмас, милли чаралар, бәйрәмнәр, концертлар, юбилейлар үткәрелә, яңа китаплар чыга... Хәрәкәт бар, тик ул тыныч һәм шома бара, фикер алышу, бәхәсләшүләр юкка чыкты, актуаль мәсьәләләр күтәрелми, хакимияткә бернинди таләп куелмый, галимнәр тарафыннан себер татарлары теле аерым халык теле, гомумтатар әдәби тел белән бернинди уртаклыгы булмаган тел кебек куелып өйрәнелә, конференцияләр, җыен-җыелышлар рус телендә генә үткәрелә, Төмән татар мәдәният үзәге урыслаша, милли йөзен югалтып бара, 90 нчы елларда ирешелгән казанышларның күбесе берәм-берәм юкка чыкты. Нәтиҗәдә, Себердә татар теленең хәлсезләнә баруы күзгә бәрелеп тора. Узган елларда ирешелгән казанышлардан нәрсә юкка чыкты, ни калды – татар җәмәгатьчелеген бу мәсьәләләр кызыксындырамы, юкмы – билгеле түгел, һәрхәлдә тормышта чагылмый, сизелми ул.*

*Татар гимназиясенең булмый калуы йөрәгемдә беркайчан төзәлмәслек ачык яра булып калды... Бирелгән форсаттан файдаланмый калды Төмән татар җәмәгатьчелеге. Татар хәрәкәтенең төп идеясе ачыкланмаганлыктан милли үсешнең төп шарты булган милли мәгариф учреждениесен булдыруга тиешле әһәмият булмады; татар җәмгыятенең таркаулыгы нәтиҗәсендә, «Ак калфак» тырышлыгы белән татар гимназиясенә нигез салу өчен ачылган «Төмән татар балалары өчен өстәмә белем бирү учреждениесе» барлык милләт балалары өчен түгәрәкләр оештырган «Этнос» үзәгенә әвереләдерелде. Югалтуларыбызның берсе генә бу, әмма иң ачысы*», – дип, йомгак ясады Бибинур апа татар гимназиясенә бәйле мәсьәләгә.

Бибинур апа 1995 елда «Ак калфак» оешмасы каршында барлыкка килгән «Сәфәр» театр коллективын да җитәкләгән. Алар 2 генә спектакль куеп өлгерәләр: Таһир Закиров комедиясе буенча «Яучылар» һәм Рәдиф Сәгъди мелодрамасы буенча «Сынган беләзек» спектакльләре. Икенчесенең авторы Рәдиф Сәгъди «Сәфәр»нең якын дустына әверелә, иҗат ярдәме күрсәтеп тора, спектакльнең Төмәндә үткән премьерасына махсус килә. Төмән мәдәният һәм сәнгать институтын читтән торып тәмамлаучы Рузилә Гыймранова, «Яучылар» комедиясенең режиссеры буларак, аның нигезендә диплом эшен «отлично»га яклый.

«Сынган беләзек» спектакленең режиссеры Казан мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлаган, өлкә татар мәдәният үзәгенең сәнгать җитәкчесе булып эшләгән Зөлфия Гыйнитуллина була, алар икесе дә спектакльләрдә төп рольләрне югары осталык белән башкаралар. 1997 елда өлкә татар мәдәнияте Үзәге ябылгач, «Сәфәр» репетицияләрен өлкә фәнни китапханә каршындагы милли китаплар бүлегендә үткәрә башлый, ул бүлек тә ябылу сәбәпле «Сәфәр»гә теркәлерлек урын калмый.

«*– Кызганыч, туган телне, әдәбиятны, театр сәнгатен сөюче талантлы, чын милләт энтузиастларын туплаган бу коллектив таркалырга мәҗбүр булды. Җәмәгатьчелек нигезендә генә хәрәкәт итсә дә, яхшы гына тернәкләнеп килә иде «Сәфәр», профессиональ милли театрга нигез салырлык ялкынлы театр коллективын югалтты төбәгебез. Рузилә мәктәптә калды, Зөлфия Казанга кайтып китте, – бу да җанымның бер ярасы*», – дип сыкрануын белдерде Бибинур апа.

